
# ШУРА

№ 46
2024



ДИНИ АЛЬМАНАХ
1908 елдан бирле нәшер ителә

# ЭЧТӘЛЕК


Җомга хотбәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 4
Җомга хотбәсенең тәрҗемәсе . . . . . . . . . . . . . . 9

ВӘГАЗЬЛӘР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
Әл-Кудс һәм әл-Әкъса мәчетенең әһәмияте . . . . . . . . 14
Дәҗҗал фетнәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
Гаилә — ике дөньяда да бәхеткә юл . . . . . . . . . . . 27
Бердәмлектә — көч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
Риба гөнаһыннан сакланыйк . . . . . . . . . . . . . . . 40
«Йәсин» сүрәсе — Коръәннең калебе . . . . . . . . . . . 47
Аллаһы Тәгаләнең «Әл-Мөҗиб» күркәм исеме . . . . . . . . 52
«Бурычлы үлмәс, әмма көн дә күрмәс» . . . . . . . . . . 59
Кыш — мөэминнең язы . . . . . . . . . . . . . . . . . . 65
Өлешеңә тигән көмешең… . . . . . . . . . . . . . . . . 77
Сәламәтлегеңне сакла . . . . . . . . . . . . . . . . . 83
Иң хәерле көн . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 87
Рәгаиб кичәсе. Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең гаилә
әһелләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 93

«НӘРСӘ? КАЙДА? КАЙЧАН?» . . . . . . . . . . . . . . . . 101
ИЮНЬ-СЕНТЯБРЬ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 102

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:**

Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте
420021, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38 нче йорт

Бушлай таратыла.
2013 елның июленнән чыга.
Басма кварталга бер тапкыр чыга.

**БАШ РЕДАКТОР:**
Хамматов Л. Г.

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Хәмидуллин Р. Ә.
Мөбарәков Б. Р.
Фәизов И. Ә.

**ҖАВАПЛЫ СӘРКАТИП**
Телефон: +7 (843) 598-09-42

**МӨХӘРРИР:**
Маннанова Р. Р.

**ДИЗАЙНЕР:**
Хәйретдинов И. И.

**БИТКӘ САЛУЧЫ:**
Гарифуллин И. Ф.

**ТЫШЛЫКТАГЫ РӘСЕМ:**
Тышлыкның 1 нче битендә фотода Куббәт әс-Сахра (Кыя гөмбәзе) мәчете.
Рәсемнең авторы: meunierd / shutterstock.com/ru/image-photo/panoramic-view-alaqsa-mosque-jerusalem-old-1086874223

**«ШУРА» дини альманах, № 46** **12+**

октябрь–декабрь 2024
рабигыль-ахыр–раҗәб 1446

Альманах Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан республикасы буенча идарәсендә 2013 елның 17 нче июлендә ПИ № ТУ16-01077 номеры белән теркәлде.

**РЕДАКЦИЯ**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
«Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты» шәхси оешмасы
420111, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 нче йорт
Тел.: +7 (843) 598-09-42
Электрон почта: izdat@huzur.ru
Сайт: huzur.ru

*Типографиянең адресы:*
*«Карти» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте типографиясендә бирелгән электрон-макетның тулы сыйфатына тәңгәлләштереп бастырылды.*
*Адрес: 420095, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Восстания урамы, 100 нче йорт, 209 нчы корпус, 22 нче бина.*

Тираж – 2000 данә
Басарга кул куелды: 19.09.2024
Чыгу көне: 07.10.2024


*Редакциягә килгән язмалар кире кайтарылмый.*

*Журналда тәрҗемә итеп бастырылган материалларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.*

*Журнал битләрендә Коръәни Кәримдәге аять-сүрәләр урын алганлыктан, басмага игътибарлы булуыгыз сорала.*


**«СОВЕТ»**

Ежеквартальное печатное издание
на татарском языке

## Җомга хотбәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый.

اَلْحَمْدُ لِلَّهِ اَلْحَمْدُ لِلَّهِ اَلْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِي هَدَانَا لِهَذَا وَمَا كُنَّا لِنَهْتَدِيَ لَوْ لَا أَنْ هَدَانَا اللهُ. وَمَا تَوْفِيقِي وَاعْتِصَامِي إِلَّا بِاللَّهِ۞ فَسُبْحَانَ الَّذِي قَالَ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللهِ: وَمَا تَشَاؤُونَ إِلَّا أَنْ يَشَاءَ اللهُ۞ نَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ۞ شَهَادَةً مُنْجِيَةً مِنْ عَذَابِ اللهِ۞ وَنَشْهَدُ أَنَّ سَيِّدَنَا مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ۞ دَاعِينَا إِلَى اللهِ۞ صَلَّى اللهُ تَعَالَى عَلَيْهِ وَعَلَى أَوْلَادِهِ وَأَزْوَاجِهِ وَعَلَى خُلَفَائِهِ الرَّاشِدِينَ الْمُرْشِدِينَ الْمَهْدِيِّينَ مِنْ بَعْدِهِ۞ وَوُزَرَائِهِ الْكَامِلِينَ فِي عَهْدِهِ۞ خُصُوصًا مِنْهُمْ عَلَى الْأَئِمَّةِ بِالْحَقِّ أُمَرَاءِ الْمُؤْمِنِينَ أَبِي بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَعُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ۞ وَعَلَى بَقِيَّةِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ۞ رِضْوَانُ اللهِ تَعَالَى عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ أَمَّا بَعْدُ فَيَا عِبَادَ اللهِ! ۞ اِتَّقُوا اللهَ وَ أَطِيعُوهُ۞ إِنَّ اللهَ مَعَ الَّذِينَ اتَّقَوْا وَالَّذِينَ هُمْ مُحْسِنُونَ۞

Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:

قَالَ اللهُ عَزَّ وَ جَلَّ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللهِ:

________________________ ۞

Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:

وَ قَالَ النَّبِيُّ صَلَّي اللهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمْ:

________________________ ۞

Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:

أَلَا إِنَّ أَحْسَنَ الْكَلَامِ وَأَبْلَغَ النِّظَامِ۞ كَلَامُ اللهِ الْمَلِكِ الْعَزِيزِ الْعَلَّامِ كَمَا قَالَ اللهُ تَبَارَكَ وَ تَعَالَى فِي الْكَلَامِ: وَإِذَا قُرِئَ الْقُرْآنُ فَاسْتَمِعُوا لَهُ وَ أَنْصِتُوا لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ۞ أَسْتَعِيذُ بِاللهِ: إِنَّ الدِّينَ عِنْدَ اللهِ الْإِسلَامُ۞

Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.

Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.

بَارَكَ اللهُ لَنَا وَ لَكُمْ۞ وَ لِسَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَ الْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَ الْمُسْلِمَاتِ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَ الْأَمْوَاتِ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ۞

Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:

اَلْحَمدُ لِلّٰه حَمْدَ الْكَامِلِيْنَ وَالصَّلَوةُ وَ السَّلَامُ عَلَى سَيِّدِ الْأَوَّلِيْنَ وَ الْآخِرِينَ۞ مُحَمَّدٍ وَآلِهِ وَ صَحْبِهِ أَجْمَعِينَ۞ تَعْظِيماً لِنَبِيِّهِ وَتَكْرِيماً لِفَخَامَةِ شَانِ شَرَفِ صَفِيِّهِ۞ فَقَالَ عَزَّ وَجَلَّ مِنْ قَائِلٍ مُخْبِراً وَآمِراً:

إِنَّ اللهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيماً۞ اَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا صَلَّيْتَ عَلَى إِبْراهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْراهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞ اَللَّهُمَّ بَارِكْ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا بَارَكْتَ عَلَى إِبْراهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْراهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞

اَللّٰهُمَّ وَارْضَ عَنِ الْخُلَفَاءِ الْأَرْبَعَةِ ذَوِى الْقَدْرِ الْجَلِيِّ وَالشَّرَفِ الْعَلِيِّ ۞ سَيِّدِنَا أَبِى بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَ عُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُمْ ۞ وَعَنِ السِّتَّةِ الْبَاقِيَةِ مِنَ الْعَشَرَةِ الْمُبَشَّرَةِ ۞ وَعَنِ الْعَمَّيْنِ الْمُكَرَّمَيْنِ عِنْدَ اللّٰهِ اَلْمُحْتَرَمَيْنِ عِنْدَ النَّاسِ ۞ سَيِّدِنَا الْحَمْزَةَ وَالْعَبَّاسِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما ۞ وَ عَنِ السِّبْطَيْنِ الْجَلِيلَيْنِ السَّعِيدَيْنِ الشَّهِيدَيْنِ ۞ سَيِّدِنَا الْحَسَنِ وَ سَيِّدِنَا الْحُسَيْنِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما ۞ وَعَنْ سَائِرِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ رِضْوَانُ اللهِ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ ۞ وَ عَنْ سَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْأَمْوَاتِ ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ ۞

اَللّٰهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللّٰهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللّٰهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ[1] ۞ وَاخْذُلْ مَنْ خَذَلَ الْمُسْلِمِينَ ۞ وَاكْتُبِ الصِّحَّةَ وَالسَّلَامَةَ عَلَيْنَا وَعَلَى الْحُجَّاجِ وَالْغُزَاةِ وَالْمُسَافِرِينَ وَالْمُقِيمِينَ وَالْحَاضِرِينَ وَالْغَائِبِينَ ۞ فِي بَرِّكَ وَبَحْرِكَ وهَوَائِكَ مِنْ أُمَّةِ مُحَمَّدٍ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلّٰهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ ۞

Иң соңыннан «Әгуузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:

إِنَّ اللهَ يَأْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْإِحْسَانِ وَ إِيتَاءِ ذِي الْقُرْبَى وَيَنْهَى عَنِ الْفَحْشَاءِ وَ الْمُنْكَرِ وَالْبَغْيِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ ۞ وَلَذِكْرُ اللهِ أَكْبَرُ وَاللهِ يَعْلَمُ مَا تَصْنَعُونَ ۞

**Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:**

---

1 Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әәмин» дип әйтә.

Әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһил-ләҙии һәдәәнә лиһәәҙәә вә мәә күннәә линәһтәдийә ләү ләә ән һәдәәнәллаһ. Вә мәә тәүфиикый вәгътисаамий илләә билләәһ. Фә сүбхәәнәл-ләҙии каалә фии китәәбиһил-кәриими әстәгыйҙү билләәһи: «Вә мәә тәшәә-үүнә илләә ән йәшәә-әллаһ». Нәшһәдү ән ләә иләәһә илләллаһу. Вәхдәһү ләә шәриикә ләһү. Шәһәәдәтән мүнҗийәтән мин газәбилләһи. Вә нәшһәдү әннә сәййидәнә Мүхәммәдән габдүһү вә расүүлүһү. Дәәгыыйнәә иләл-лаһи. Салләллаһу тәгаалә галәйһи вә галәә әүләәдиһи вә әзвәәҗиһи вә галәә хуләфәә-иһир-раашидиинәл мүршидиинәл мәһдиййинә мин бәгъдиһи. Вә үзәраа-иһил кәәмилиинә фии гаһдиһи. Хусуусан минһүм галәәл ә-иммәти бил-хәккый үмәраа-ил мү'миниинә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гусмәәнә вә Галиййин. Вә галәә бәкыййәтис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәнин иләә йәүмид-дини. Ридъвәәнуллаһи тәгаалә галәйһим әҗмәгыйнә.

Әмма бәгъде: фә йәә гыйбәдәллаһ! Иттәкуллаһә вә әтыыйгууһу. Иннәллаһә мәгал-ләҙиинәт-тәкау, вәл-ләҙиинә һүм мухсинүүн.

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Каалә-ллаһу газзә вә җәллә фии китәәбиһил кәриими әстәгыыйҙү билләһи: ______________________________

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Вә каалән нәбиййү салләллаһу галәйһи вә сәлләм: ______________

**Вәгазьнең темасына багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәгеләрне укый:**

Әләә иннә әхсәнәл кәләәми вә әбләган низаами. Кәләәмүллаһил мәликил газиизил галләәми, кәмәә кааләллаһу тәбәәракә вә тәгаалә фил-кәләәми. Вә иҙәә куриәл-куръәәну фәстәмигуу ләһү вә әңсыйтү ләгалләкүм түрхәмүүнә. Әстәгыыйҙү билләһи: «Иннәд-диинә гыйңдәллаһил Исләәм».

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта Ахирәт өчен һәртөрле дога кылына ала.**

Бәәракәллаһу ләнәә вә ләкүм. Вә лисәә-ирил мү’миниинә вәл мү’минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиинә. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә, вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмин.

**Соңыннан, басып, икенче хотбә буларак, киләсе сүзләрне укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, хәмдәл кәәмилиинә вәссаләәтү вәссәләәмү галәә сәййидил әүвәлиинә вәл әхыйринә Мүхәммәдин вә әәлиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн. Тәгъзыймән линәбиййиһи вә тәкриимән лифәхаамәти шәәни шәрафи сафиййиһи. Фәкаалә газзә вә җәллә мин каа-илин мүхбиран вә әәмиран:

«Иннәллаһә вә мәләә-икәтәһү йүсаллүнә галән нәбиййи. Йәә әййүһәл-ләẓиинә әәмәнүү саллүү галәйһи вә сәллимүү тәслиимән». Аллаһуммә салли галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә салләйтә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһиимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид. Аллаһуммә бәәрик галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә бәәрактә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһиимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид.

Аллаһуммә вәрда ганил хуләфәә-ил әрбәгати ẓәвил кадрил җәлиййи вәш-шәрафил галиййи сәййидинәә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гуҫмәәнә вә Галиййин радыяллаһу ганһүм. Вә ганис-ситтәтил бәәкыйәти минәл гашәратил мүбәшшәрати. Вә ганил гаммәйнил мүкәррамәйни гыйндәллаһи әл-мүхтәрамәйни гыйндән-нәәси сәййидинәл Хәмзәтә вәл Габбәәси радыяллаһу ганһүмәә. Вә ганис сибтайнил җәлииләйнис сәгыыйдәйни әш-шәһиидәйни сәййидинәл Хәсәни вә сәййидинәл Хүсәйни радыяллаһу ганһүмәә. Вә ган сәә-ирис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәни иләә йәүмид-диин. Ридъвәәнуллаһи галәйһим әҗмәгыйн. Вә ган сәә-ирил мү’миниинә вәл мү’минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл

әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр раахимин.

Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин[1]. Вәхҙүл мән хәҙәләл мүслимиин. Вәктүбис-сыйххәтә вәс-сәләәмәтә галәйнәә вә галәәл хүҗҗәәҗи вәл гузәәти вәл мүсәәфириинә вәл мүкыйммиинә вәл хәәдыйриинә вәл гаа-ибиинә. Фии бәррикә вә бәхрикә вә һәвәә-икә мин үммәти Мүхәммәдин галәйһим әҗмәгыйн. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә. Вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин.

**Иң соңыннан «Әгууҙү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

«Иннәллаһә йә'мүру бил гадли вәл ихсәәни вә иитәә-и ҙил курбәә вә йәнһәә ганил фәхшәә-и вәл мүнкәри вәл бәгъ-ии, йәгыйзукүм ләгалләкүм тәҙәккәрүүн. Вәләҙикруллаһи әкбәр, вәллааһи йәгъләмү мәә тәсънәгуун».

## Җомга хотбәсенең тәрҗемәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:

Безне туры юлга күндергән Аллаһыга мактау булсын.[2] Аннан башка безне берәү дә (туры юлга) күндерә алмый.

Коръәни Кәримдә: **«Әмма Аллаһы теләми торып, сез тели алмассыз. Һичшиксез, Аллаһы – Белүче, Хикмәт иясе»**, – дип әйтүче Аллаһы – барлык кимчелекләрдән дә Пакь.

Без бердәнбер булган Аллаһыдан башка илаһның юклыгына һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Аның Расүле һәм колы булуына шаһитлык итәбез. Без Пәйгамбәребез, аның балалары, хатыннары,

---

[1] Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әәмин» дип әйтә.

[2] 3 тапкыр әйтелә.

элек яшәп киткән изгеләребез һәм һидаять юлында булган һәркем өчен, Аллаһының рәхмәтен сорыйбыз.

Һәм аның турыдан-туры хәлифәләре – мөэминнәрнең хакимнәренә: Әбү Бәкер, Гомәр бине Хаттаб, Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһүмәдән Аллаһы риза булсын. Кыямәт көнендә барлык пәйгамбәрләргә һәм табигыйннәргә Аллаһының ризалыгы һәм рәхмәте булсын.

Моннан соң Аллаһыга гыйбадәт кылучылар Аңа итагать итсен.

> **«Һичшиксез, Аллаһы –** [гөнаһлардан] **курыккан һәм** [Раббыларының ризалыгын гына өмет итеп] **игелекле гамәлләр кылган кешеләр белән».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:128

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә: ____________________

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: ______________________________________________________________

**Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:**

Дөреслектә, иң дөрес һәм төзек сөйләм – ул Аллаһының Сөйләме. Коръәндә Аллаһы Тәгалә әйтүенчә:

> **«Коръән укылган чакта, аны тыңлагыз һәм дәшми торыгыз, – бәлки, сез** [Аллаһы тарафыннан] **рәхмәт ителерсез»;**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:204

> **«Һичшиксез, Аллаһы хозурында** [хакыйкый һәм кабул ителгән] **дин – Ислам** [дине генә]**».**

«Әлү Гыйmран / Гыймран гаиләсе», 3:19

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.**

Без Аллаһыдан барыбыз өчен дә рәхмәтен иңдерүен сорыйбыз. Мөэмин-мөселманнар өчен ярдәм ике дөньяда да булачак. Син – Ишетүче, Якын һәм догаларыбызга җавап бирәсең. Синең рәхмәтең белән, йә, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы. Пәйгамбәрләргә сәламнәр һәм Аллаһының рәхмәте булсын. Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһыга мактаулар булсын.

**Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:**

Аллаһыга мактаулар, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның гаиләсенә, сәхабәләренә һәм аңа ияручеләргә сәламнәребез һәм Аллаһының рәхмәте булсын.

Аллаһы Тәгалә Изге Китабыбызда әйткәнчә:

**«Һичшиксез, Аллаһы һәм фәрештәләре Нәби салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтәләр. Ий иман китерүчеләр! Сез аңа салават әйтегез һәм** [«Ий, Нәби, сиңа сәлам булсын», – дип] **сәламләү белән сәлам бирегез».**

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:56

Йә, Аллаһы, тугры хәлифәләр: Әбү Бәкер, Гомәр бине Хаттаб, Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһүмәгә һәм җәннәт белән шатландырылган алты сәхабәгә, Расүлебезнең югары дәрәҗәдә булган абыйлары – Хәмзә бине Габделмотталиб һәм Габбас бине Габделмотталибка, шәһит булып киткән сөекле оныклары Хәсән белән Хөсәенгә рәхмәтеңне иңдер. Сәхабәләр һәм табигыйннәр өчен Кыямәт көнендә Аллаһының рәхмәтен, ризалыгын ирештер.

Мөэмин-мөселманнар өчен ярдәмең ике дөньяда да булачак. Дөреслектә, Син – догаларыбызны Ишетүче һәм догаларыбызга җавап бирәсең. Синең рәхмәтең белән, йә, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы!

Йә, Аллаһы, динебез Исламга ярдәм итүчеләргә Син дә ярдәм ит (өч тапкыр әйтелә). Мөэминнәрне җәберләүчеләрне көчсезләндер. Безгә, галимнәргә, юлчыларга, исәннәргә һәм үлеләргә – пәйгамбәребез

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең өммәтенә тынычлык һәм тәртип билгелә.

**Иң соңыннан, «Әгууҙү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

> **«Һичшиксез, Аллаһы** [һәрнәрсәне аңлатыр өчен, индергән китабында] **гадел булырга, изгелек кылырга һәм** [бигрәк тә] **якын туганнарга** [мохтаҗ булган нәрсәләрен] **бирергә** [һәм туганлык җепләрен ныгытуны] **әмер итә.** [Зина кебек] **Фәхешлектән,** [көферлек, ширек һәм шуның кебек дин кабул итмәгән] **тыелганнан һәм** [кешеләргә] **җәбер-золым кылудан тыя. Сез акылга килерсез дип, сезне үгетли».**
>
> «Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:90

Аллаһыны зикер итегез. Хакыйкатьтә, Ул сезнең ни кылганнарыгызны белә.

# Вәгазьләр

*11 нче октябрь вәгазе,*

*рабигыль-ахыр аеның 8 нче көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Әл-Кудс һәм әл-Әкъса мәчетенең әһәмияте

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Газиз дин кардәшләрем, бүгенге вәгазебездә изге Әл-Кудс (Кодыс Шәриф) һәм әл-Әкъса мәчетенең әһәмияте турында исегезгә төшерергә телим. Җирнең төрле почмагында яшәүче, төрле телләрдә сөйләшүче, төрле милләттән булучы һәр мөселман өчен өч мөкатдәс, изге урын бар. Бу, әлбәттә, Мәккә һәм Мәдинә җирләре, ә өченчесе — Әл-Кудс шәһәре (русча әйткәндә — Иерусалим). Хәтта динебезне начар белгән кешеләр дә мөселманнар өчен Мәккә белән Мәдинәнең изге булуын аңлый. Әмма, кызганыч, бик күп еллар мәчетләргә йөрүче, намаз укучы кайбер дин кардәшләребез дә Әл-Кудс турында берни белми диярлек. Бераз шушы урын, шәрәфле әл-Әкъса мәчете турында сөйләп, алар турындагы хәдисләрне искә алыйк.

Мөселман кардәшләрем, Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай ди:

سُبْحَانَ الَّذِي أَسْرَىٰ بِعَبْدِهِ لَيْلًا مِّنَ الْمَسْجِدِ الْحَرَامِ إِلَى الْمَسْجِدِ الْأَقْصَى
الَّذِي بَارَكْنَا حَوْلَهُ لِنُرِيَهُ مِنْ آيَاتِنَا ۚ إِنَّهُ هُوَ السَّمِيعُ الْبَصِيرُ ﴿١﴾

«[Бер айлык юлны бер төн эчендә үтү, Бәйтел Мәкъдисне зиярәт кылу, бөтен пәйгамбәрләрне тере килеш күрү, җиде кат күктә аларның урыннарында булу һәм Җәмалыбызны күрү кебек] **Аятьләребездән**

**кайберләрен күрсәтик дип, бер төнне** [бик кыска бер вакытта Мөхәммәд (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) колын Харам мәчетеннән [алып] **Без тирә-ягын бәрәкәтле иткән Әкъса мәчетенә күчерүче** [булган Аллаһы ниндидер бер урында булудан һәм бөек Затына килешми торган төрле түбән сыйфатлардан ерак һәм бөтен] **кимчелекләрдән пакь. Һичшиксез, Ул —** [һәрнәрсәне] **Ишетүче, Күрүче».**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:1

Инде күрәбез, кардәшләрем, галәмнәрнең Раббысы Үзе мәсҗид әл-Әкъсаны искә ала. Башка бер аятьтә, «Әл-Маидә» сүрәсенең 21 нче аятендә, Аллаһы Тәгалә Әл-Кудс шәһәрен искә ала һәм аны «мөкатдәс җир» дип атый.

Кемдер хәзер бәлки гомумән бу нинди урын икән, кайда урнашкан, нинди мәчет турында сүз бара, дип уйлыйдыр. Кардәшләрем, Әл-Кудс шәһәре Шам җирләренә караган Фәләстыйнда (Палестина) урнашкан. Бүгенге көндә аны кемдер Израильнең «башкаласы» дип санаса да, бар мөселманнар аны Фәләстыйнга карый, дип саный. Шушы мөкатдәс Әл-Кудс шәһәренең «Иске шәһәр» дип аталган урыны бар, анда Әл-Харам Әш-Шәриф дип аталган калкулык урнашкан. Әлеге калкулык мөселманнар өчен дә, насара вә яһүдиләр өчен дә изге урын санала, чөнки ул күпсанлы пәйгамбәрләр тарихына бәйле. Нәкъ шушы калкулыкта Мәсҗид әл-Әкъса урнашкан да.

Кардәшләрем, без, әл-Әкъса дигәндә, бер ниндидер бина, кешеләр төзеп куйган гыйбадәтханәне генә күз алдына китерергә тиеш түгел. Галимнәребез әйтүенчә, әл-Әкъса ул — билгеле бер урын, бүгенге көндә ул борынгы дивар белән уратып алынган һәм анда берничә корылма бар. Шушы корылмалар арасында иң мәшһүрләре: әл-Әкъса җәмигы, Куббәт әс-Сахра мәчете (Кыя гөмбәзе мәчете), әл-Мәрвани мусалләсе (намаз уку урыны), коелар, мәдрәсәләр һ.б.

Безнең өчен әл-Әкъсаның кыйммәте бик зур.

Беренчедән, әл-Әкъса — җир йөзендә икенче булып төзелгән гыйбадәтханә. Бу хакта без хәдисләрдән беләбез. Хәзрәти Әбү Зәрр

радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән: «Ий Расүлуллаһ, җир йөзендә кайсы мәчет (гыйбадәтханә) беренче төзелгән булган?» — дип сораган. Ул: «Әл-Харам мәчете», — дип җавап биргән. Сәхабә: «Ә соңыннан?» — дип сораган. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Соңыннан әл-Әкъса мәчете», — дигән. Әбү Зарр: «Ә алар арасында күпме вакыт узган?» — дип кызыксынган. Расүлуллаһ: «Кырык ел...» — дип әйткән.

Әүвәл әл-Әкъсаның кем тарафыннан төзелүе билгеле түгел. Кайбер галимнәребез аны Адәм галәйһиссәлам төзегән дип фаразласа, кайберләре ул фәрештәләр тарафыннан төзелгән, дип тә әйткән. Шулай ук хәдисләрдән һәм тарихи риваятьләрдән соңрак шушы урында Давыд пәйгамбәрнең гыйбадәтханә булдыруы, ә аннан соң аның улы Сөләйман галәйһиссәламнең мәчетне төзекләндерүе билгеле. Күрәбез, Аллаһының рәхмәте белән, бу урынның тарихы нинди бөек пәйгамбәрләргә бәйле.

Инде шундый борынгы чордан безгә якынрак көннәргә күчсәк, һиҗри 15 елда (милади буенча 636 ел), хәзрәти Гомәр бине әл-Хаттаб хәлифә булган вакытта, мөселманнар Әл-Кудс шәһәрен ала. Һәм хәзрәти Гомәр радыяллаһу ганһе ул чорда ташландык хәлдә булган әл-Әкъса урынын табып, монда мәчет төзетә. Менә шул бинаны да «әл-Әкъса җәмигы» дип атый башлыйлар. Монда шуны да әйтергә кирәк, дин кардәшләрем, мөселманнар шәһәрне сугышсыз, бер кан коешсыз ала, тарихта мондый очракта «шәһәрне ача» дип тә әйтәләр. Чөнки ул чорда Әл-Кудста яшәүче насаралар хәзрәти Гомәр радыяллаһу ганһе кебек сыйфатларга ия булган хәлифә киләчәген, аның бик гадел булачагын белгән. Тарихчылар моны шулай аңлата. Һәм, чыннан да, Гомәр радыяллаһу ганһе хәлифә насараларга дин иреге вәгъдә итеп, аларның чиркәүләрен, гыйбадәтханәләрен саклый.

Икенчедән, әл-Әкъса — ул мөселманнарның беренче кыйбласы. Тарихтан без беләбез, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам һәм сәхабәләр намазларын әүвәл әл-Әкъсага юнәлеп кылган. Һәм һиҗрәттән соң, якынча бер елдан артык вакыт узгач, Аллаһының әмере буенча, кыйбла тарафы үзгәргән. Шул

вакыттан башлап без Мәккәдәге Кәгъбәтуллаһка юнәлеп намаз укыйбыз. СөбханАллаһ, бу да әлеге урынның нинди дәрәҗәле булуын күрсәтә.

Өченчедән, дин кардәшләрем, әл-Әкъсада укылган намазларның кыйммәте бик зур. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Әл-Харам мәчетендә кылынган намаз (савабы буенча) 100 мең намазга тиң; минем мәчеттә кылынган намаз (савабы буенча) 1 мең намазга тиң; Бәйт әл-Мәкъдистә (ягъни әл-Әкъсада) кылынган намаз (савабы буенча) 500 гади намазга тиң», — дип әйткән. Бу мәшһүр хәдисне күпләребез Мәккә-Мәдинәләргә бәйле рәвештә белә. Әмма анда «Бәйт әл-Мәкъдис»нең искә алынуын да онытмыйк. Гомумән, бик күп хәдисләрдә әл-Әкъса шулай «Изге Йорт» дип атала.

Дүртенчедән, сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әл-Исра (төнге күчеш вакыйгасы) вакытында әл-Әкъсага күчерелә. Бу хакта Коръәни Кәримдә китерелгән аятьне вәгазебезнең башында укыган идек, бу күп кенә хәдисләрдә дә искә алына. Мәсәлән, хәзрәти Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһе тапшырган хәдистә Пәйгамбәребез галәйһиссәлам болай ди: «Миңа Буракны китерделәр... Аңа атланып мин Бәйт әл-Мәкъдискә күчтем. Анда мәчеткә кереп, ике рәкәгать намаз кылдым...»

Безгә Әл-Исра һәм Әл-Мигъраҗ вакыйгалары яхшы билгеле. Һәр мөселман Расүлебезнең Аллаһының рәхмәте белән кыска гына арада Мәккәдән Әл-Кудс шәһәренә, әл-Әкъсага күчерелүенә һәм күккә ашуына ышанырга тиеш. Газиз дин кардәшләрем, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм шушы вакыйга турында Мәккәдә сөйләгәч, бик күп кешеләр, хәтта кайбер мөселманнар да моңа ышанмаган. Чөнки бу бер могҗизага тиң күренеш. Кешеләр бер төн эчендә Мәккәдән Әл-Кудска җитеп, аннан кире әйләнеп кайту мөмкин түгел, анда бит әллә ничә көн барырга кирәк, дип гаҗәпләнгән. Һәм бары хәзрәти Әбү Бәкер әс-Сиддыйк радыяллаһу ганһе, хәбәрне ишеткәч үк: «Әгәр Расүлуллаһ шулай дисә, димәк, бу хак», — дигән.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, әл-Әкъсада бүгенге көнгә кадәр гарәп телендә «әс-Сахра әл-Мүшәррафә» дип аталган Шәрәфле Кыя сакланган. Әл-Мигъраҗ вакытында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм нәкъ шушы Шәрәфле Кыядан Күкләргә ашкан, дип санала. Бу кыя бик зур түгел, биеклеге дә 2 метр тирәсе, хәзерге вакытта ул алтын түбәле мәшһүр Куббәт әс-Сахра (ягъни Кыя гөмбәзе) дип аталган мәчет эчендә калган.

Әл-Әкъсаның әһәмияте турында тагын бик күп сөйләп була. Әмма без тагын бер генә билгесен искә алыйк, кардәшләрем. Бишенчедән, әл-Әкъсаны зиярәт итү бик саваплы. Бу хакта берничә хәдис бар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Бәйт әл-Мәкъдискә барыгыз һәм анда намаз кылыгыз... Әгәр дә аны зиярәт итә алмасагыз, кәндилләре өчен бераз май җибәрегез». Ягъни мөмкинлекләре булган мөселманнар, юллар имин булса, әл-Әкъсага барырга, анда намазлар, игътикяфләр кылырга омтылырга тиеш. Моның әҗер-савабы бик зур, без хәдисләрнең бик аз өлешен генә укып киттек.

Әмма, хөрмәтле дин кардәшләрем, бүген ишетеп, интернеттан күреп торабыз, безнең өчен изге булган әл-Әкъсада да, гомумән Фәләстыйнда төрле золым кылынып тора. Кайвакыт әл-Әкъсага җәмәгать намазларына яшьләргә һәм урта яшьтә булучыларга керергә рөхсәт бирмиләр яки намазга килүче кардәшләребезне кулга алалар, дигән хәбәрләр күрә алабыз. Күрәбез, Фәләстыйнда, Газзә җирләрендә бүген мөселман кардәшләребез зур золым күрә, алар бомбалар астында яшәргә мәҗбүр, башкача моны атап та булмый. Һәм бу инде ким дигәндә бер ел дәвам итә. Әмма дөресрәк әйтсәк, бу бик күптән сузылган бер низаг. Ни кызганыч, бүген зур-зур бай мөселман дәүләтләре шушы кардәшләребезгә ярдәм итә, аларны яклый алмый, үзләрен дөнья лидерлары диючеләр дә килешә алмый.

Газиз дин кардәшләрем, шушы хәдисләр аша аз булса да әл-Әкъсаның әһәмиятен аңлый алсак иде, калебләребездә аңа мәхәббәт уянса иде. Карагыз, Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисендә: «Әгәр дә аны зиярәт итә

алмасагыз, кәндилләре өчен бераз май җибәрегез», — диде бит. Аңлыйбыз, безнең күпләребез, яше яки матди хәле аркасында, бу изге урынны беркайчан да зиярәт кыла алмаячак. Әмма, Аллаһының рәхмәте, бүген без Фәләстыйн халкына, Әл-Кудс, Газзә мөселманнарына матди ярдәм җибәрә алабыз. Диния нәзарәтебез берничә тапкыр шулай анда гуманитар ярдәм җибәрде инде. Без дә «Зәкят» хәйрия фонды аша белешеп, тагын кайчан ярдәм җыячакларын белеп, үзебезнең өлешне кертә алабыз. Ә икенчедән, әлбәттә, мөселман кардәшләребезне догаларыбыздан калдырмыйк, һәр намазыбыздан соң, төнге намазлардан соң Фәләстыйнда һәм башка җирләрдә золым күргән бар кардәшләребез өчен дога кылыйк, җәмәгать.

Раббыбыз ошбу вәгазьләребезне файдалы кылып, барчабызга изге Мәккә вә Мәдинә җирләрен, мөкатдәс әл-Әкъсаны зиярәт кылырга насыйп әйләсен. Аллаһы Тәгалә Фәләстыйндагы дин кардәшләребезгә җиңеллек, ныклык биреп,  залимнәрдән азат итсен! Әмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә Рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*«Хозур» нәшрият бүлеге*

*18 нче октябрь вәгазе,*

*рабигыль-ахыр аеның 15 нче көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Дәҗҗал фетнәсе

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барчаларыбызга да Аллаһының сәламе, рәхмәте һәм бәрәкәте насыйп булсын! Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә шушы җомга көннәребезне һәркайсыбызга хәерле, мөбарәк һәм бәрәкәтле итеп кылса иде. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә шушы җомга көннәребездә укылган намазларыбызның, кылган догаларыбызның әҗер-савапларын Кыямәт көнендә күреп сөенергә насыйп әйләсә иде.

Мәсих Дәҗҗал темасы Ислам динендә зур урын алып тора. Гомумән алганда, ул безнең Аллаһы Тәгаләгә ышануыбыз, гакыйдәбез белән бәйле. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Дәҗҗал хакында сәхабәләргә бик тәфсилләп сөйләгән, аның фетнәсе хакында кисәткән. Аллаһының рәхмәте белән, әлеге хәдисләр бүгенге көнгә кадәр сакланып килгән.

Кем соң ул Дәҗҗал? Аның турында без хәдисләрдән шуларны беләбез: беренчедән, ул — кеше, ягъни җен яки башка зат түгел. Икенчедән, аның кыяфәте болай тасвирлана: ул бер күзле, ягъни аның бер күзе күрмәс, батып торыр, ә икенчесе акайган; йөзе кызыл булыр; чәчләре бөдрә; ул зур бәдәнле булыр. Иң зур билгеләренең берсе — аның маңгаенда, күзләре арасында «кяфер» дип язылган булыр, һәм бу сүзне иманлы кешеләр генә күрә алыр, диелә. Бу язу ни рәвешле, нинди телдә булачагы билгесез, әмма мөселманнар аны һичшиксез укый алачак. Дәҗҗал искиткеч зур байлыкка, ризыкка ия

булачак, кешеләргә төрле могҗизалар күрсәтә алачак, мәсәлән, үлгән кешене терелтеп күрсәтәчәк. Әмма бу могҗизалар хакыйкый булмас, гади генә әйткәндә, алар иллюзия сыман кешене алдау гына булачак. Иң куркынычы шул — динсез кешеләр, иманнары зәгыйфь булганнар — барчасы Дәҗҗалга ияреп, аны илаһ дип танып, бу куркыныч фетнәгә каршы тора алмаячак.

Кайбер кеше: «Миңа бу мәгълүмат нәрсәгә кирәк? Дәҗҗал килер вакытка әллә мин исән булырмын, әллә юк?» — дияргә мөмкин. Болай дип фикер йөртү — чын ялгышу. Икенче төрле әйткәндә, ул хакыйкатькә туры килми, чөнки Дәҗҗалның чыгуы — Кыямәт көне билгеләреннән. Һәм сәхабәләр Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне тыңлаганнан соң, Дәҗҗалны бик тиз, менә бүген-иртәгә килеп чыгар, дип уйлаганнар.

Имам Мөслимнең хәдисләр җыентыгында шундый хәдис бар, аны хәзрәти Нәвәс бине Сәмган исемле сәхабә радыяллаһу ганһе җиткерә. Ул болай ди: «Көннәрнең берендә Расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм иртә белән безгә Дәҗҗал турында сөйләде. Сөйләм барышында аның тавышы йә күтәрелә, йә төшә барды. Ул бу хакта шулкадәр җитди сөйләде ки, әйтерсең лә Дәҗҗал яныбыздагы агач артында гына яшеренеп тора иде».

Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең үзенчәлекле итеп сөйләвендә дә зур хикмәт ята. Тавышын күтәреп мөрәҗәгать иткәндә, Расүлебез бу теманың никадәр җитди, җаваплы, һәрберебез өчен мөһим икәнлеген күрсәткән. Ә тавышын акрынайтып, тынычрак итеп сөйләве Дәҗҗалның түбән дәрәҗәсе хакында хәбәр итә. Хәдис болай итеп дәвам итә: «Кич белән Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм безнең белән кабат очрашкач, безнең йөзебездәге куркуны күрде. Без аңа иртәнге аралашуның безнең күңелләрдә борчу уятканын, кинәт Дәҗҗал килеп чыкса, без аңа каршы тора алырбызмы-юкмы дип курыкканыбызны сөйләдек. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Дәҗҗал хәзер килеп чыкса, мин сезнең өчен курыкмыйм. Әгәр шулай насыйп булса, сезнең өчен мин үзем сөйләшәчәкмен (ягъни сезне яклый алачакмын). Әмма мин үзем булмаган вакытта яшәгән мөселманнар

өчен кайгырам. Алар Дәҗҗал белән үзләре өчен шәхсән үзләре сөйләшергә тиеш булачаклар», — диде». Хәдис шулай дип тәмамлана.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, әлеге хәдис тә, Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әйткән сүзләре дә безне уйландырырга тиеш. Беренчедән, Дәҗҗалдан куркучы кешеләр — сәхабәләр бит. Аларның дәрәҗәләре, кылган игелекле гамәлләре хакында укысаң, сокланырлык. Алар Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламгә һәрвакыт бик күп ярдәм иткәннәр, алар дөньяда Ислам диненең таралуына сәбәпче булганнар. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Коръәни Кәримдә сәхабәләрдән разый булуын һәм аларны җәннәт белән сөендерәчәге хакында хәбәр итә. Иман көче, тәкъвалыгы ягыннан искиткеч көчле булган бу кешеләр дә Дәҗҗал фетнәсеннән курыккач, бу безгә ишарә булып торырга тиеш, ләбаса.

Икенчедән, без Мөхәммәд галәйһиссәлам кисәткән чорда, янәшәдә Расүл булмаган вакытта яшибез. Димәк, минем өчен дә, синең өчен дә, аның өчен дә Дәҗҗалга каршы торучы кеше, яклаучы юк. Аңа каршы без үзебез өчен үзебез торырга тиеш булачакбыз.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләнең Дәҗҗалны төгәл кайчан чыгарачагы мәгълүм булмаса да, бу хәлнең кайчандыр барыбер булачагы тәгаен билгеле. Бу хәл бер көннәнме, бер елданмы яки берничә гасырдан соң булачакмы — анысын Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Үзе генә белүче. Ә безнең төп бурычыбыз — бу вакыйгага әзер булу. Шулай ук Расүлебез Мөхәммәд галәйһиссәлам өстәп әйтә: «Мин булмаганда мине Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә алыштырачак». Ягъни, бу сүзләр шуны аңлата: Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бакыйлыкка күчкәч, мөселман кардәшләрен Дәҗҗалдан яклый алмый, әмма Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә барча мөэмин-мөселман бәндәләрен Үз яклавы, саклавы астына алачак. Чынлыкта, Дәҗҗалның фетнәсе Аллаһы Тәгаләдән ерак булганнар өчен авыр булачак. Иман көче, тәкъвалыклары ягыннан зәгыйфь булганнар өчен бу котычкыч зур фетнәгә әвереләчәк. Аллаһы юлында булып, кушканнарын үтәп, тыелганнарыннан

тыелган мөэминнәр, иншәАллаһ, әлеге сынауны да җиңеллек белән үтә алырлар.

Дөньялыкта нинди генә имтихан тапшырсак та, без аңа алдан әзерләнәбез. Әгәр дә бар тырышлыгыңны, сабырлыгыңны куеп, һәр билетны, һәр биремне тиешенчә өйрәнәсең икән, әзерлекле кеше өчен бер генә имтихан да башкарып чыга алмаслык катлаулы булмый. Шулай ук Дәҗҗал фетнәсенә каршы тору да — бөек имтихан. Расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм исә безгә Дәҗҗалга, аның мәкеренә ничек итеп каршы торырга кирәклеген өйрәтеп, аңлатып калдырган.

Газиз дин кардәшләрем, димәк, Дәҗҗал турында белүнең һәр мөселман өчен бик әһәмиятле икәнен аңладык. Ә Дәҗҗалның кайчан килүе турында нәрсә билгеле?

Әйткәнемчә, Дәҗҗалның чыгуы — Кыямәт көненең зур билгеләренең берсе. Хәдисләрдә хәбәр ителгәнчә, Дәҗҗал килер алдыннан, озакламый аның чыгасын ишарәләп, бер-бер артлы төрледән-төрле галәмәтләр булып узарга тиеш. Шуларның берсе — Гарәп ярымутравының гөлбакчага әверелүе, анда елгалар-күлләр саны артуы. Соңгы елларда интернет битләреннән күренгәнчә, иң эссе җәйге көннәрдән кала башка вакытта Мәккә, Мәдинә шәһәрләренең тау битләре яшеллеккә күмелеп утыра, СөбханАллаһ. Күп еллар элек Мөхәммәд галәйһиссәлам мөселманнарны бу хакта инде кисәткән иде бит.

Икенче бер галәмәт — Фөрат (ягъни Евфрат) елгасының төбе ачылуы. Елга төбеннән алтыннар, төрле файдалы казылмалар, кыйммәтле ташлар чыгачак. Менә шул зур байлык өчен елга ярында зур сугышлар көтелә, диелгән.

Өченче галәмәт — имам Мәһдинең килүе. Боларга өстәп, олуг Дәҗҗал фетнәсе чыгар алдыннан, әле тагын берничә шундый зур галәмәт булачагы хакында сөйләнелә. Боларның барысы да үтәлсен өчен, әлбәттә, күпмедер вакыт кирәк. Ләкин шуны онытмыйк: кайчандыр һәрберебез өчен Кыямәт көне барыбер җитәчәк. Расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең

бер хәдисендә: «Дисбе өзелеп, төймәләре бер-бер артлы ничек тиз тәгәрәп төшсә, Кыямәт көненең зур билгеләре дә шул тизлектә берсе артыннан берсе киләчәк», — диелгән. Кыямәт көненең зур билгеләре чынга ашкан вакытлар бик зур сынаулар, авырлыклар чоры булачак, шуңа күрә һәр мөселман алар турында белеп торырга, өйрәнергә тиеш.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә өчен бар җир йөзен юк итәр өчен бер мизгел җитә. Димәк, адәм баласының гасырдан-гасырга килгән табышы, җыйган мөлкәте, булдырган әйберләре күз ачып йомганчы юк булырга мөмкин. Без цивилизацияле чорда яшибез, дисәк тә, әлеге яңарыштан иртәгә нәрсә калачагын беребез дә белми. Бүген бер төймәгә басу белән ничә эшебез башкарылса, бу әле иртәгә дә шулай булыр дигән сүз түгел. Җир шарында барган туктаусыз сугышлар, тәртипсезлек уйга калдыра. Алар Кыямәт көне галәмәтләренә сәбәпме яисә безне алда тагын нинди сынаулар көтә — болар әлегә безгә сер булып тора. Мәсих Дәҗҗал ачып керәсе ишекләр бәлки инде ачыктыр, дигән уйлар да күңелгә керми түгел…

Өстә атаган зур галәмәтләрдән соң адәм баласын алда 3 ел көтә. Бу хакта Ибне Нәҗем җыентыгында хәдис китерелә. Хәзрәти Ибне Хозәймә радыяллаһу ганһедән риваять ителә: «Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Дәҗҗал чыгар алдыннан өч авыр ел булачак. Беренче елда Аллаһы Тәгалә күккә яңгырның өчтән берен тотып торып, өчтән икесен яудырырга әмер бирер; ә җирдәге үсемлекләрнең өчтән икесе чыгар һәм өчтән бере чыкмас. Икенче елда яңгырның өчтән бере генә явар һәм үсемлекләрнең дә өчтән бере генә үсәр. Өченче елда ел дәвамында бер тамчы яңгыр яумас һәм бер үсемлек тә шытып чыкмас. Аллаһы калдырырга теләгәннәрдән тыш, барлык тояклы хайваннар да үлеп бетәр». Барлык тереклекне ачлык биләп алачак. Бу бик куркыныч. Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән мондый авыр вакытларда кешеләр ничек яшәр соң, дип сорагач, ул «Ләә иләһә илләллаһу», «Аллаһу Әкбәр», «СөбханАллаһ» дигән сүзләр ризык булачак, дип аңлата. Бу сүзләрне

әйтүчеләргә дә бик авыр булачак, шулай да, Аллаһы Тәгалә Үзенә бик ихластан гыйбадәт кылган колларын ач калдырмаячак.

Шундый куркыныч, авыр вакытлар килгәч, иманнары зәгыйфь кешеләр Дәҗҗалның тизрәк килүен көтә башлаячак. Бу хакта имам әт-Табарани җыентыгында хәдис китерелә. «Дәҗҗалның нинди олы фетнә булуын белә торып та, аның килүен көтәрләрме?» — дип гаҗәпләнеп сорый сәхабәләр. Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Алар авырлык артыннан тагын да зуррак авырлык татыячаклар», — дип җавап кайтара. Күз алдына китерергә дә куркыныч хәлләр бит! Эчәргә су, ашарга бер тәгам ризык юк. Әти-әнисенең газиз балалары күз алдында ачлыктан тилмерә, җәфа чигә. Әти кеше берничек тә ярдәм итә алмый. Көннән-көн хәлләр авырая. Менә шундый бик авыр хәлләргә түзә алмыйча, иманы зәгыйфьләр коткаруны Дәҗҗалдан өмет итә башлаячак. Бу һич кенә дә рәхәттән дә, кызык эзләүдән дә булмаячак.

Мисал өчен: Кыямәт көнендә дә кешеләр 70 ел дәвамында күләгәсез, өстән кояш кыздырып торган җирдә хисап көтеп торачак. Шулчакта да күпләр, түзмичә, «хисап тизрәк килсен иде», дип теләрләр. Алар шулкадәр арган булырлар ки, алар өчен җәһәннәм уты да моннан җиңелрәк булып тоелыр. Кемнәрдер өчен Мәсих Дәҗҗал килүе дә шулайрак булыр.

Газиз дин кардәшләрем! Уйланыйк: бер хәдистә Расүлебез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ике бармак — имән һәм урта бармаклар — арасы кебек, мин Кыямәт көненә бик якын җибәрелдем», — ди. Бүгенгесе көндә һиҗри исәп буенча 1446 ел. Расүлебезгә пәйгамбәрлек килүдән соң 1446 елдан артык вакыт узган дигән сүз бит бу. Кыямәт көненең кечкенә билгеләренең бик күбе инде булды. Алар артыннан олы билгеләр әлегә тиз генә булмас, дип кем ышандырып әйтә ала?

Шуңа күрә, һәр намаздан соң, һәрберебез Дәҗҗал фетнәсеннән яклау сорап Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә сыеныйк. Шулай ук Расүлебез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм «Әл-Кәһф / Мәгарә» сүрәсенең 10 аяте хакында искәртеп уза. Хәдисләрдә бу сүрәнең беренче 10 яки соңгы

10 аятен уку яки ятлау Дәҗҗал фетнәсенә каршы торырга ярдәм итәчәк, диелгән. Алар олы фетнәгә каршы безнең калканыбыз булып торачак. Хәтта дөрес юлдан атлаучы иң тәкъва мөселманнарга да Дәҗҗал белән көрәшү бик авыр булачак. Шуңа күрә, мөселман дин кардәшләрем, бу көннәр җиткәнче, үзебезнең холкыбызны камилләштерү өстендә көн саен гына түгел, адым саен тырышыйк. «Эш үткәч, үкенүдән файда юк», — ди халкыбыз.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә мәчет-мәхәлләләребезгә, район, Республикабызга, мөселман өммәтенә Үзенең ярдәмнәрен насыйп әйләсен!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә Рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Фәрит хәзрәт Шәрапов,*

*Биектауның «Ак мәчет» мәчете имам-хатыйбы*

*25 нче октябрь вәгазе,*

*рабигыль-ахыр аеның 22 нче көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Гаилә — ике дөньяда да бәхеткә юл

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барча галәмнәрне юктан бар кылучы, шул галәмнәрне тәрбия кылып һәм Үзенең төрле нигъмәтләре белән бүләкләп торучы Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгаләгә хәмде-сәналарыбыз, олуглауларыбыз булса иде. Безне хак юлга күндерүче, барчаларыбызга иң күркәм үрнәк булучы, сөекле нурлы Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның барлык сәхабәләренә күңелләребезнең түрләреннән чыккан сәламнәребез, салават-шәрифәләребез һәм һәртөрле изге догаларыбыз ирешсә иде!

Газиз дин кардәшләрем, милләттәшләрем, 2024 ел Россиядә Гаилә елы дип игълан ителде. Бу бик вакытлы карар, чөнки татар өммәтенең дә, гомумән бүгенге җәмгыятьнең дә бер чире ул — гаиләләр таркалу. Шагыйребез Һади Такташ язган бит әле:

*«Һәр заманның, үзенең чире була,*
*Һәрбер чирнең була докторы...»*

Гаилә проблемалары һәм аларның дәвалары турында искә алыйк әле. Коръәни Кәримдә болай дип әйтелә:

وَمِنْ آيَاتِهِ أَنْ خَلَقَ لَكُم مِّنْ أَنفُسِكُمْ أَزْوَاجًا لِّتَسْكُنُوا إِلَيْهَا وَجَعَلَ بَيْنَكُم
مَّوَدَّةً وَرَحْمَةً ۚ إِنَّ فِي ذَٰلِكَ لَآيَاتٍ لِّقَوْمٍ يَتَفَكَّرُونَ ﴿٢١﴾

> **«Бергә яшәвегез өчен үзләрегездән сезнең өчен хатыннар яратуы һәм арагызда сөю** [нәтиҗәсендә хасил булган бердәмлек] **белән бер шәфкать** [чарасы булган бала] **бирүе дә — Аның билгеләреннән. Һичшиксез, монда уйлаганнар өчен** [аңлатылып бетерә алмаслык дәрәҗәдә зур] **билгеләр бар».**
>
> «Әр-Рум / Румлылар», 30:21

Ягъни, ирләр тынычлык тапсыннар өчен, аларга хатыннар яратылган. Гаилә ул — кешегә күңел тынычлыгы бирә торган, рухи көч чыганагы булып торган, иң якын һәм кадерле кешеләрдән торган бер җәмәгать. Димәк, гаилә — Раббыбыздан бу фани дөньяда бирелгән иң бөек рәхмәтләренең берсе икән.

Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Сөннәтеннән дә без гаиләгә карата күркәм мөнәсәбәтне күрәбез. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хатыннарына һәм балаларына бик күп игътибар биргән. Хәтта хәзрәти Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһедән шундый бер риваять китерелә: «Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән: «Сиңа кайсы вакыт кыйммәтлерәк — гаиләң белән уздырганымы яки мәчеттә үткәргәнеме?» — дип сорадым. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип җавап бирде: «Минем өчен балаларым белән бер сәгать уздырган вакыт мәчеттән чыкмыйча утырган вакыттан да кыйммәтлерәк». Аннан янә сорадым: «Йә Расүлуллаһ, синең өчен нәрсәгә сарыф ителгән мал кыйммәтлерәк: гаиләң өченме яки Аллаһы юлындамы?» Расүл салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип җавап бирде: «Гаиләгә тотылган бер дирһәм минем өчен Аллаһы юлында сарыф ителгән мең дирһәмнән кыйммәтлерәк». Менә динебездә гаиләнең әһәмияте никадәр олы, җәмәгать!

Гаиләләр саклансын өчен, дәүләтебез тарафыннан күп эшләр эшләнә: материнский капитал да түлиләр, бушлай җир дә бирәләр, төрле льготалар да бар. Әмма гаиләләр барыбер таркала. Статистика безгә аерылышуларның күп сәбәпләрен күрсәтә. Иң киң таралганнары икәү: беренчесе — акча

җитмәү; икенчесе — холыклар (характерлар) туры килмәве. Шушы сәбәпләрне шәригатебез күзлегеннән карыйк әле.

## 1. Гаиләне тәэмин итү — ир бурычы.

Гаиләне акча белән тәэмин итү бурычын Аллаһы Тәгалә ирләргә йөкләде. Шуның өчен шәригатьтә ир хатыннан өстен:

الرِّجَالُ قَوَّامُونَ عَلَى النِّسَاءِ بِمَا فَضَّلَ اللَّهُ بَعْضَهُمْ عَلَىٰ بَعْضٍ وَبِمَا أَنفَقُوا مِنْ أَمْوَالِهِمْ ۚ

> «**Аллаһының** [тирән акыл, оста җитәкчелек, көч, ныклык кебек сыйфатлар белән] **бирәүләрне икенчеләрдән өстен кылганы өчен һәм малларыннан сарыф иткәннәре сәбәпле, ирләр** [гаилә эчендә әмер бирү һәм тыюлар мәсьәләсендә] **хатыннардан өстен торалар».**
>
> «Ән-Ниса / Хатыннар», 4:34

Бу аятьтән нәрсә аңлыйбыз? Өстенлек белән бергә ирләргә җаваплылык һәм бурычлар да йөкләнә. Менә алар: мәһәр түләү, нәфака (безнең сүзләр белән әйтсәк, алимент түләү), торак бирү, физик һәм рухи зыян китерүдән саклау һәм яклау, гадел булу һәм ирнең мирасыннан хатынга өлеш бирелү. Болар барысы да — хатынның хаклары. Ә хатынына карата ирнең хаклары икәү генә. Һәм алар икесе дә милек белән бәйле түгел. Болар: хатын иргә буйсынырга тиеш; ире хатынын тәрбияләргә хаклы.

Моннан нинди нәтиҗә ясыйбыз? Әгәр дә ир, хатынына сораганча мәһәр түләгән икән, аерым торак белән тәэмин иткән икән, хатынын һәм аның шәхси милкен төрле куркынычлардан саклый икән, димәк, хатын, ире кайда кушкан, шунда яшәргә тиеш, нәрсә куша — шуны эшләргә, аны тыңларга тиешле. Әгәр дә хатын иренең бу хакын бозса, буйсынмаса, аны тәрбияләргә мөмкин. Әүвәл — күркәм йомшак сүз белән; сүзнең файдасы булмаса — аралашуда битарафлык, салкынлык һәм игътибарсызлык күрсәтеп; болай

да тыңламаса — ачуланып һәм куркытып. Хатынны кыйнарга ярый, дип әйтәләр. Дөрес әйтмиләр! Әгәр дә кул күтәрү нәтиҗәсендә хатын имгәнсә, ул бу очракта казыйга мөрәҗәгать итәргә хаклы.

Әмма ир, хатынын тәрбиялим дигәндә, башта үзен дә белсен. Еш кына кире һәм үзсүзле хатыннар кемгә тия? Аллаһы Тәгаләгә шундый ук итагатьсезлек күрсәткән ирләргә! Раббыбыз болай дип әйтә:

الْخَبِيثَاتُ لِلْخَبِيثِينَ وَالْخَبِيثُونَ لِلْخَبِيثَاتِ ۖ وَالطَّيِّبَاتُ لِلطَّيِّبِينَ وَالطَّيِّبُونَ لِلطَّيِّبَاتِ ۚ

> «**Әшәке хатыннар** [һәм сүзләр] **— әшәке ирләргә, әшәке ирләр — әшәке хатыннарга. Пакь хатыннар — пакь ирләргә, пакь ирләр — пакь хатыннарга.** [Боларның бер-берләре белән өйләнешүе генә дөрес]**».**

«Ән-Нур», 24:26

Ничек аңларга моны? Һәр кеше үзенә тиң ярын рухи якынлык буенча сайлый: кемгә байлык мөһим булса, шул байлыкка омтыла; кем Аллаһының ризалыгына ирешергә тели, шул ахирәт кыйммәтләре белән яши. Галимнәр болай дип әйтә: ирләр хатыннарны дүрт сыйфатка карап сайлый: матурлыгына, байлыгына, нәсел-нәсәбенә һәм тәкъвалыгына. Кем нәрсә сайлый — шуңа ирешә. Кайсы хатын белән финанс авырлыкларны кичерергә җиңелрәк соң? Әлбәттә, намуслы һәм иманлы ир белән хатын үз гаиләсен шул сәбәпле генә таркатмас. Алар һәр авырлыкны Аллаһыдан сынау дип кенә кабул итәр һәм, күркәм сабырлык күрсәтеп, хәләленә ярдәм итәр. Аерылышуларның асыл сәбәбе менә нидә икән: акча җитмәүдән түгел, ә рухи кыйммәтләр җитмәүдән, ирләр хатыннарын ташлый, хатыннар ирләреннән китә.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, Ибраһим галәйһиссәламгә бәйле бер гыйбрәтле вакыйганы искә төшерик. Ибраһим пәйгамбәр хатыны Һаҗәрне һәм кечкенә баласы Исмәгыйльне, бер турсык су һәм берничә хөрмә җимеше

тоттырып, берүзләрен чүлдә калдырып китә. Һаҗәр нык курка, аларны ташламаска ялвара. Ибраһимның да йөрәге сыкрый, ләкин аның башка чарасы булмый — ул Аллаһы сүзеннән чыга алмый. «Син Аллаһы кушканга шулай эшлисеңме?» — дип сорагач, Ибраһим: «Әйе», — дип җавап кайтара. Һаҗәргә шушы бер сүз җитә! Ул Ибраһим галәйһиссәламгә ачуланмый да, аның белән талашмый да. Ул Аллаһыга тәвәккәл кылып, иренең сүзенә күнеп, баласын кочаклап чүлдә кала. Һәм бу тарихның ахырын без беләбез: Раббыбыз Һаҗәр һәм Исмәгыйльне Зәм-зәм чыганагы һәм Мәккә шәһәренең барлыкка килүенә сәбәпче итә. Менә Аллаһының чиксез рәхмәте!

Ир үзенең гаиләсе алдында бурычларын үтәсә, хатын аңа ярдәмче һәм фикердәшче булса, ә икесе бергә алар тәкъва кешеләр булса, шул чакта гаилә нык булыр.

Әмма хатын тәкъвалы дип, ир үзенең өстендә торган тәэмин итү бурычын онытырга тиеш түгел, әлбәттә. Хатыннарга бу хакны Аллаһы Тәгалә Үзе бирде. Бер хәдистә болай диелә: «Эшләгән акча дүрт төрле яхшы юнәлешләргә сарыф ителергә мөмкин: Аллаһы юлында, мохтаҗларга, колны азат итүдә, гаилә өчен. Гаиләңә тотылган акча өчен иң олы әҗергә лаеклы булачаксың». Ягъни кешенең Аллаһы алдында иң яхшы малы — гаиләгә тотылган малы икән.

Гаиләне тәэмин итү мәсьәләсендә тагын бер мөһим сорауга тукталасым килә: ул — бюджет. Ир кеше гаиләсен тәэмин итәргә тиешле булса да, динебездә гаилә бюджеты дигән төшенчә юк. Хатын эшләгән акча — аның үзенеке. Ничек тели, шулай сарыф итә һәм шуның өчен Аллаһы каршында үзе җавап тота. Бу бик җитди мәсьәлә, чөнки, мәсәлән, корбан чалу кебек фарыз гамәлләр башкарганда, һәр кеше үзе өчен генә җавап бирә. Кемнең нисабы бар, корбанны шул үз исеменнән чалдырырга тиеш. Хатынның нисаб кадәрле җыелган үз акчасы бармы — димәк, аның өстендә корбан чалу бурычы тора. Ирнеке дә шулай. Балигълыкка ирешкән балаларның да.

## 2. Гаиләдә тынычлыкны саклау — хатын бурычы.

Аерылышуларның икенче сәбәбе — холыкларның туры килмәве, дип күрсәтә статистика. Гаиләне тәэмин итү өчен ирләр җавап бирә, дидек, ә инде гаиләдәге тынычлык, үзара аңлашу һәм, киресенчә, тавыш чыгу — хатыннардан тора. Характерлар кайчан туры килми? Нәфес көчле булганда. Җәмәгать! Гаиләнең иминлеге хатын-кызның тыңлаучан булуыннан тора. Чынлыкта, ир хакы ата-ана хакыннан да артык. Ирне ачуландыруда бик зур куркынычлар бар, ә аны тыңлауда — бик зур саваплар. Галимнәр әйтүенчә, Кыямәт көнендә хатын-кыздан иң беренче чиратта намазы турында соралыр, икенче чиратта — ире алдында бурычларын үтәве турында. Ягез, уйлап карагыз әле, мөхтәрәм ханымнар, җавапны тота алырсызмы? Хатыннар ирләр тынычлык тапсыннар өчен яратылган, дигән идек. Ирләрегез өйдә тынычлык табамы? Ирен ачуландырган хатынның, ире аны гафу иткәнче, хәтта намазы да кабул булмас, диелә китапларда.

Чынлыкта, хөрмәтле мөслимәләр, барысы да бик гади бит: әгәр дә сезнең патшабикә буласыгыз килсә, ирегезне патша итеп күрегез. Әгәр дә ирегезне үзегезнең колыгыз итәсегез килсә, үзегез аның өчен кол булыгыз. Ирне ир иткән дә — хатын, юк иткән дә — хатын, диләр безнең халыкта. Уйлап карагыз әле: әгәр Хәдичә анабыз Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең берничәшәр көн өйгә кайтмыйча, мәгарәдә утырганы өчен ачуланса, ул хаклы булыр идеме? Ул чып-чын пәйгамбәр хатыны булган! Сез дә хәдисләрдә һәм риваятьләрдә тасвирланган иң күркәм хатын-кызларга охшарга тырышыгыз! Әз белән канәгать булыгыз, матурлыгыгызны саклагыз, ирегезгә ял итәргә мөмкинлек бирегез, тәмле ашлар пешерегез, балаларын һәм туганнарын яратыгыз, аның серләрен саклагыз, каршы сүз әйтмәгез.

## 3. Гаиләне ничек саклап калырга?

Күрәбез: гаилә ул — зур хезмәт. Әлеге вәгазьдән нинди нәтиҗәләр чыгарарыга була?

1. Беренчедән, ир — хатын алдында, хатын ире алдында бурыч һәм хакларны үтәргә тиеш! Хәзрәти Хәсән әл-Бәсридән мондый хәдис китерелә: «Хатыннарыгызга игелекләр кылыгыз, чөнки алар — сезнең ышанычлы ярдәмчеләрегез, һәм алар үз йөрәкләренә хуҗа түгел. Сез аларны әманәт итеп кенә алдыгыз».

Ә икенче бер хәдистә болай диелә: «Ир – синең өчен җәннәт тә, җәһәннәм дә». Ягъни аның ризалыгында булсаң, сиңа оҗмах капкалары ачык булыр, юк икән — җәһәннәм утлары көтә.

2. Икенче киңәш — мәһәрне күпсенмәгез.

Муса галәйһиссәлам нинди мәһәргә ризалашкан, беләсезме? Кызның атасы аңа шарт куя: әгәр дә 10 ел буе миңа бушка эшләсәң, кызымны бирәм, дигән. Бөтен кеше шакката: нинди кыз соң ул? Ә аның бик кыйммәтле бер сыйфаты булган икән: ул Муса галәйһиссәламгә тыйнаклыгы белән ошаган. Кыз тыйнак булганга күрә, ул 10 ел буе бушка эшләргә дә риза булган! Кызганыч, бүген мәһәр турында сүз чыкканда, бик күп егетләр кызларны гаепли: янәсе, алар бик кыйммәтле бүләкләр сорыйлар. Сорасыннар, аларның хакы ул. Мәһәрнең иң аз күләмен Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм билгеләгән, ләкин аның зурлыгын чикләмәгән. Түли алмыйсың икән, үзеңә тиң, тәкъвалырак кызны эзлә, ләкин гаепләргә хакың юк.

Чынлыкта мәһәр ул — гаиләне ныгыта торган бер чара. Мәһәр күбрәк булган саен, егетнең кызга карата җитди мөнәсәбәте дә яхшырак күренә. Мисал өчен, мәһәргә фатир бүләк иткән ир, бу кадәрле кыйммәткә төшкән хатыннан киткәнче, әле йөз тапкыр уйлар. Хатын да, үзе аерыласы килгән чакта, шундый зур мәһәрне иренә кире кайтарырга әзер булырмы икән? Шәригатьтә бик күп хикмәт яшеренгән!

3. Өченче киңәш — сабыр булыгыз һәм гафу итә белегез.

Бик күп гаиләләр, сабырсызлык сәбәпле талак әйтеп, харап була. Казыйлар янына барып, хатыннарын кайтарырга сорыйлар. Соң хатынны казый түгел, ир үзе генә аера ала бит! Сез ничек кенә үтенеп сорасагыз да, казый Аллаһы Сүзеннән чыга алмый. Өч тапкыр талак әйткәнсең икән — кызыпмы, шаярыпмы, йә башка сәбәп беләнме — бетте: син хатыныңны аердың һәм кайтара алмыйсың. Шуңа күрә онытыгыз ул «талак» сүзен! Бер риваятьтә әйтелә бит: «Әгәр дә берәү Аллаһының хакын хаклап, Аллаһы белән арасын төзек тотса, дөньяда ул дүрт төрле сөенечкә ирешер. Шул сөенечләрнең беренчесе: ир икән — хатыныннан, хатын икән — иреннән уңар». Бер-берсеннән зарланган ирләр һәм хатыннар бик күп. Бер-береңнән зарланганчы, Аллаһы белән араңны яхшырт. Бәхетле буласың килсә, рәхим ит: бәхетне Раббыбыз Ислам эченә яшергән, Ул кушканнарын үтә, Ул тыйганнардан тыел.

Газиз милләттәшләрем! Хәзрәти Ибне Габбас радыяллаһу ганһедән риваять ителә: Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Үпкәләшеп, бер-берегездән аерылмагыз, бер-берегезне өч көннән дә артык вакытка калдырмагыз. Әгәр дә ике мөселман ачуланышып, бер-берсен өч көннән артыкка ташлашсалар һәм үлеп китсәләр, җәннәттә күрешмәсләр».

Аллаһы Раббыбыз барчабызга да җәмәгатьләребез белән тату һәм күркәм итеп яшәрлек хикмәт бирсен, якын кешеләребезгә золым эшләүдән һәм авыр сүз әйтүдән сакласын. Мәрхәмәтле булыйк һәм бер-беребез өчен догада булыйк. Аллаһыдан ярдәм һәм яклау сорыйк. Гаиләләребездә тынычлык, иминлек һәм шатлыклы көннәр хөкем сөрсен. Әмин!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә

дә Рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Илфар хәзрәт Хәсәнов,*

*Казанның «Кол Шәриф» мәчетенең имам-хатыйбы*

*1 нче ноябрь вәгазе,*

*рабигыль-ахыр аеның 29 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Бердәмлектә — көч

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Аллаһы Тәгалә кешеләрне яратканда, аларны үзләренә туры килгән мохиттә яратты: без бер-беребез белән аралашып, гаилә корып, җәмгыять белән яши торган затлар. Адәм баласы башка кешеләргә, туганнарына, дусишләренә, таныш һәм гомумән таныш булмаган кешеләргә мохтаҗ. Кайбер хайваннар кебек без ялгыз гына тормыш алып бара алмыйбыз. Кешеләр бергә һәм бердәм булганда гына көчле була. Һәм моны барыбыз да аңлый: гаилә башлыгы балаларына, туганнарына бердәм булыйк, дип әйтә; оешма җитәкчесе хезмәткәрләрен бергә эшләргә чакыра; дәүләт җитәкчеләре халыкны дус-тату булырга өнди. Халкыбызның мәкаль-әйтемнәрендә дә бу чагылыш тапкан: «Бердәмлектә — көч», «Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар», «Кеше кешесез яшәми».

Аллаһы Раббыбыз Коръәни Кәримдә безгә болай дип әмер итә:

وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا ۚ

> «**Барыгыз бергә Аллаһының арканына** [Китабына һәм диненә] **нык-лап ябышыгыз һәм** [әһле китап кебек ихтилафка төшеп хакыйкатьтән һәм бер-берләрегездән] **аерылмагыз».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:103

Аллаһы Тәгалә безне бер өммәт итеп яратты. «Өммәт» сүзенең гомумән гарәп телендә һәм шулай ук Коръәни Кәримдә, хәдисләрдә белдергән мәгънәләре бик күп. Һәм аның төп мәгънәләреннән — халык, кешеләр төркеме, милләт. «Мөхәммәд өммәте» дигәндә, сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм алып килгән дин, шәригать берләштергән кешеләр төркемен атаганнар. Һәм Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм гомер буе, хәтта үлеме килгән мизгелләрдә дә, үз өммәте өчен кайгырып, үз өммәте өчен догада булып, «өммәтем, өммәтем» дип торды. Бүген дә без үзебезне «өммәт» яки «мөселман өммәте» дип атыйбыз. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай ди:

إِنَّ هَٰذِهِۦٓ أُمَّتُكُمْ أُمَّةً وَٰحِدَةً وَأَنَا۠ رَبُّكُمْ فَٱعْبُدُونِ ﴿٩٢﴾

«[Ий кешеләр!] **Һичшиксез, бу — бер генә өммәт буларак, сезнең өммәтегез** [динегез]**. Раббыгыз — Мин генә, шулай булгач, Миңа** [гына] **гыйбадәт кылыгыз».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:92

Газиз дин кардәшләрем, димәк, без сезнең белән Аллаһы Тәгаләгә ышануыбыз, Аңа гына гыйбадәт кылуыбыз, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә ияргүебез белән бер өммәт, бер гаилә булдык. Һәм мөселман өммәтеннән булу ул — Раббыбыз биргән иң зур нигъмәт.

Мөселманнарны, алар җирнең кайсы гына кыйтгасында, кайсы гына почмагында яшәмәсеннәр, бер үк дин нигезләре, бер үк кыйммәтләр берләштерә. Бүгенге көндә җир шарында якынча 2 миллиард мөселман яши, диләр. Ягъни бу бүгенге көндә яшәгән барлык халыкның якынча 35 % тәшкил итә. Безнең дин кардәшләребез Евразиядә дә, Африкада, Америкада, океандагы кечкенә генә утрауларда да яши. Безнең телләребез төрле-төрле, безнең тән төсебез төрле, кыяфәтләребез, мәдәниятебез, байлыгыбыз, холыкларыбыз төрле, әмма иң мөһиме — динебез — бер. Һәм бу Ислам динебезгә беренче көннәрдән үк хас иде. Исебезгә төшерик, сәхабәләр арасында коллар

күпме иде. Уйлап карасаң, кол бит ул — җәмгыятьнең иң түбән катламына караган кеше булган: хокуксыз, ирексез, ризыксыз. Ә күпме иде сәхабәләр арасында бай, дәрәҗәле кардәшләребез. Һәм шушы ике катлам бер-берсен кан кардәшедәй якын күрде, алар бер-берсе өчен малларын да, гомерләрен дә кызганмады. Аларның берсе дә, дәрәҗә, байлык ягыннан булсынмы, гыйлем һәм гыйбадәт ягыннан булсынмы, үзен башкалардан өстен, яхшырак санамады.

Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә мөселман кардәшләрне бер бинага тиңләгән, безнең һәрберебез — шушы бинаның бер өлеше, ташы, һәм берләшеп, без бер-беребезне тотып торабыз, ныгытабыз. Ә һәр таш аеры булса, бина да булмас иде, ул җимерелер иде.

Галимнәребез дин кардәшләре бер-берсенә карата шундый мөнәсәбәттә булырга тиеш ди:

— мөселман үз кардәшен Аллаһы ризалыгы өчен ярата;

— кардәш кардәшләре өчен хәерле догада була;

— алар бер-берсе турында фәкать яхшы фикер саклый, начар уйламый;

— алар бер-берсен гафу итә белә;

— кардәшләр бер-берсенең шатлыгын да, кайгысын да уртаклаша белә.

Раббыбыз безгә бердәм, нык өммәт булып, кардәшлек әдәпләрен үтәп яшәргә насыйп кылсын.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, шушы көннәрдә дәүләтебездә Халык бердәмлеге көне булачак. Дәүләтебездә төрле милләт вәкилләре, төрле дин әһелләре тату, дус яшәсен өчен, бик зур эш алып барыла, күп чаралар уздырылып тора. Әлхәмдүлилләһ, бүгенге көндә бу бик мөһим. Күреп торабыз, җир йөзендә милләтара бәхәсләр аркасында күпме сугышлар, конфликтлар бара, аларның кайберләре инде дистә елларга сузыла. Мондый низаглар барган җирдә бернинди дә алга китеш, үсү, гыйлем алу, фәнни ачышлар турында сүз бармый.

Бүгенге көндә Россиядә 190 төрле милләт вәкиле яши, дип килә статистикаларда, алар 300 якын тел һәм диалектта сөйләшә икән. Бу бит Аллаһының бер рәхмәте, дин кардәшләрем. Беләбез, һәр халыкның ниндидер күркәм сыйфаты бар, без дус һәм бердәм булып, бер-беребездән яхшы сыйфатларны алып кына яшәргә тиешбез.

Газиз дин кардәшләрем, без бик күп милләтләр һәм башка дин әһелләре арасында яшибез. Шушы җәмгыятебездә без күркәм үрнәк булырга омтылыйк, динебез, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә карата кешеләрдә бары иң матур фикерләр калдырырга тырышыйк. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Мөэмин ул — шулдыр, кешеләр аның теленнән дә, кулыннан да һичбер зыян күрмәс».

Аллаһы Тәгалә барчабыздан разый булып, бердәм күркәм өммәт булып яшәргә һәм Кыямәт көнендә дә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм өммәтеннән кубарылырга насыйп итсен! Туган җиребезгә бәрәкәт индерсен, ил-көннәребез тыныч булсын. Әмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә Рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Илмир хәзрәт Хәсәнов,*

*Буа районының имам-мөхтәсибе*

*8 нче ноябрь вәгазе,*

*җөмәдәл-әүвәл аеның 6 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Риба гөнаһыннан сакланыйк

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, сезгә барыбыз өчен дә бик мөһим һәм куркыныч булган хәдиснең бер өлешен сөйләп китәсем килә. Аны игътибар белән тыңлап, шундагы вакыйгаларны күз алдыгызга китерергә тырышыгыз. Бу хәдисне мәшһүр сәхабә хәзрәти Сәмүра бине Җөндәб радыяллаһу ганһе тапшырган.

Ул болай сөйләгән: «Иртәнге намазлардан соң Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм еш кына бездән: «Бүген төнлә кайсыгыз төш күрде?» — дип сорый иде. Һәм беребез төш күргән булса, ул аны сөйли иде, ә Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «МәшәАллаһ!» — дип әйтә иде.

Бер көнне ул янә безнең төшләребез турында сорады, әмма бер кеше дә төш күрмәгән иде. Һәм ул, Расүлебез, үзенең төшен сөйли башлады: «Бүген төшемдә минем янга ике кеше килде. Алар мине кулымнан тотып, бер җиргә алып килделәр. (...) Без бер елга ярына килеп җиттек, әмма су урынына елгада кан ага иде. Шушы канлы елга уртасында бер кеше басып тора, ә аның каршында ярда башка бер кеше тора иде. Елгадагы кеше ярга таба чыга башласа, ярдагы кеше аңа таш ыргыта иде. Һәм бу таш теге кешенең нәкъ авызына килеп тия иде дә, ул, елгадан чыга алмый, кире үз урынына кайта иде. Һәм бу кеше кан елгасыннан чыгарга тырышкан саен, икенчесе таш атып, аны үз урынына кайтара иде...»

Хәдиснең дәвамын соңрак сөйләп бетерермен, әлегә шушы урында туктап, фикерләп карыйк әле, дин кардәшләрем. Бу бит бик куркыныч төш булган, һәм ул төш кенә түгел, чөнки Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең төшләре гади кешенеке кебек булмаган. Бу төш тә хәдис буларак тапшырылган, ул имам әл-Бохари һәм Мөслим җыентыкларында китерелгән икән, димәк, безнең өчен бу бик җитди кисәтү булып тора.

Бу төштән аңлашылганча, канлы елгада басып торган кеше ниндидер бер рөхсәт ителмәгән эш, бер зур гөнаһ кылган. Нинди гөнаһ икән ул? Бәлки ул кеше үтерүчедер, шуңа кан елгасыннан чыга алмыйдыр? Юк. Бәлки ул бур, каратктыр? Юк. Ә бәлки ул алдакчы булгандыр? Юк. Хәдистә аның нинди гөнаһ кылуы әйтеләчәк. Аңа кадәр шундый статистика китерәсем килә: бүгенге көндә безнең илебездә бу гөнаһны 50 миллион кеше кыла икән. Ягъни 16 яшьтән өлкәнрәк булган халыкның якынча 40 % шушы гөнаһта. Алар арасында безнең танышларыбыз да, бәлки мөселман кардәшләребез дә бар әле.

Нинди гөнаһ икән соң бу? Хәдис дәвам итә: Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әлеге ике кешедән сораган: «Бүген төнлә күргән вакыйгалар турында сөйләгезче?» Алар: «Син канлы елгада күргән кеше — ул риба гөнаһын кылучы», — дип әйткәннәр. Ә бу ике кеше чынлыкта фәрештәләр булып чыккан, берсе — Җәбраил галәйһиссәлам, икенчесе Микаил галәйһиссәлам булган[1].

Риба турында бик күп аятьләр, хәдисләр иңдерелгән, Аллаһы Тәгалә һәм сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм безне бу хакта күп тапкыр кисәткән. Әмма, күрәбез, бүген бар дөньяда да, безнең илебездә дә кешеләр көннән-көн рибага керә, хәтта инде мөселманнар да аны зур гөнаһ дип күрми. Шайтан безгә аны бизәп, искиткеч матур итеп күрсәтә, шәһәр урамында булсынмы, телевизор, телефоннарда булсынмы, әйләнәтирәбез рибаның матур рекламасы белән тулган: «арзанлы кредит», «тиз акча», «бүген ал да, иртәгә түлә», «аена 20 мең түләп кенә фатир ал» һ.б. Ә бит

[1] Имам әл-Бохари, № 1386; имам Мөслим, № 2275.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кыямәт көне алдыннан риба таралачак»[1], — дип әйтеп калдырган. Бу бүгенге көн турында түгелме икән?

Рибаны гади генә аңлатканда, ул — бурычка акча биреп торганда, акчаны шәригатебездә рөхсәт ителмәгән рәвештә арттыру. Яки без аны шулай ук «процент» дип тә атыйбыз. Бу шәхси мисалларга да, шулай ук сату-алу, бизнес эшенә дә карый. Мәсәлән, бер кеше күршесенә 20 мең акча биреп торды да, аннан 22 мең итеп кайтарырга кушты. Мондый килешүне динебез тыйды. Яки, киресенчә, алучы кеше: «Дустым, бик кирәк иде, әйдә син 10 мең биреп тор да, мин сиңа арттырып кайтарырмын», — дип ала икән, артык кайтарган акча шул риба була да инде. Һәм шулай ук бүгенге көндә безнең барыбыз да банклар белән эш итә, кемдер акчасын сакларга һәм арттырырга дип, банкка процентка сала икән, моның да риба икәнен белсен.

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Рибаның 73 төре бар, һәм гөнаһлылыгы буенча аның иң җиңеле үз анаң белән якынлык кылуга тиң», — дип әйткән. СөбханАллаһ, бер генә сәламәт кеше дә үз әнисе белән якынлык кылу турында уйлый да алмый. Ә Пәйгамбәребез рибаны шушындый түбән, котычкыч гөнаһ белән чагыштыра. Һәм бу әле иң җиңеле, ди.

Дөреслектә, рибаның төрләре бик күп һәм бүгенге көндә банклар системасы бик алга киткән, алар төрледән-төрле килешүләр тәкъдим итеп тора, һәм гади кешегә аларны аңлап бетерү дә авыр. Әмма, Аллаһының рәхмәте белән, бүген безгә бу мәсьәләдә бер җиңеллек бирелде. Бүгенге көндә Республикабызда, һәм Татарстанда гына түгел, илебез күләмендә шәригатебезгә туры килгән, риба гөнаһыннан пакь булган финанс продуктлары барлыкка килә. Аларны галимнәребез тикшереп, гади мөселманнарга эшне бик җиңеләйтә.

Мәсәлән, Ак Барс кебек зур банк мөселманнар өчен аерым карталар тәкъдим итте. Мондый картаның башкалардан аермасы зур: хезмәт хакы, пенсиябез шул картага килеп, шунда җыелып тора икән, димәк,

[1] Имам әт-Табарани.

безнең акчабызны банк башкаларга харам ипотека, кредит бирүгә тотмый. Киләчәктә мондый карталарны башка банклар да булдырырга вәгъдә итә. Бу бар кеше өчен дә мөһим, кирәкле булганга мисалга китердем. Шулай ук банкларның, Ислам финанс оешмаларының бизнес алып баручылар, йорт-фатир алырга теләүчеләр өчен башка төрле тәкъдимнәре бар. Шундый ихтыяҗы бар икән, мөселман кешесе шундый рөхсәт ителгән юлларны эзләргә, өйрәнергә тиеш. Диния нәзарәтенең сайтында яңа барлыкка килгән һәм алар тарафыннан хупланган оешмалар, финанс продуктлары турында яңалыклар чыгып тора. Зур банкларыбызга мөрәҗәгать итәсез икән, без мөселманнар, безгә Ислам финансларына туры килгән тәкъдимнәрегез бармы, сездә хәләл ипотека бармы, дип кызыксыныгыз башта. Чөнки алар бар, һәм яңалары эшләнеп, булдырылып тора, киләчәктә дә артыр, иншәАллаһ.

Шуны да әйтәсем килә, бүген шундый мөселман кардәшләребез дә бар, алар: «Ислам финанслары кыйммәт. Миңа фәлән банкта отышлы ипотека/кредит тәкъдим иттеләр, бу арзанга чыга, Аллаһы гафу итәр әле», — дип, шуны алалар. Кеше үзенчә: «Фәлән хезмәт хакы алам, ай саен фәлән мең түләп бара алачакмын», — дип уйлый. Әмма риба гөнаһына кергәч, хәлләр үзгәрә шул, еш кына кеше йә эшсез кала, йә үзе, баласы авырый башлый, кыскасы, теге санап чыгарган акчасы җитми башлый аның. Ник? Ә чөнки ризыгының, акчасының бәрәкәте бетә. Аллаһы Тәгалә рибаны тыеп, Коръәндә болай ди:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ وَذَرُوا مَا بَقِيَ مِنَ الرِّبَا إِن كُنتُم مُّؤْمِنِينَ ﴿٢٧٨﴾ فَإِن لَّمْ تَفْعَلُوا فَأْذَنُوا بِحَرْبٍ مِّنَ اللَّهِ وَرَسُولِهِ ۖ وَإِن تُبْتُمْ فَلَكُمْ رُءُوسُ أَمْوَالِكُمْ لَا تَظْلِمُونَ وَلَا تُظْلَمُونَ ﴿٢٧٩﴾

**«Ий иман китерүчеләр! Әгәр** [чыннан да] **мөэминнәр икәнсез, Аллаһыдан куркыгыз һәм риба өлешен калдырыгыз. Әгәр алай итмәсәгез** [рибаны тыйган әмерне үтәмәсәгез], **Аллаһы һәм**

**Расүленнән булачак сугышны белегез. Әгәр** [рибачылыктан] **тәүбә итсәгез, малларыгызның нигезе** [булган төп өлеше] **— сезнеке.** [Бурычлылардан артык сорап] **Золым иткән һәм** [төп өлешегез киметелмичә] **золым күргән булмассыз».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:278–279

Риба гөнаһына керүчегә Аллаһы Тәгалә Үзе һәм Аның Расүле сугыш игълан итә икән, иманлы бәндә өчен моннан да куркыныч әйбер була аламы?! Шуңа күрә, динебез арзанлысын, отышлысын эзләргә кушмаган, ә рөхсәт ителгән, хәләл акча булганын гына кулланырга кушкан. Ә шушы «Аллаһы гафу итәр әле» дип рибага кергән кеше тәүбә итмичә үлеп китсә? Бу бик куркыныч хәл. Һәм ишетеп-күреп торабыз, ипотека-кредитлар алган кеше үлеп китсә, әле аның алган фатирын, машинасын яки башка малын алып кына китәләр. Беркем дә аның тол хатыны, балалары яки карт әти-әнисе бар икән, ул фәлән миллион түләгән инде, гафу гына итик аны, дип уйламый. Шуңа күрә, кадерле дин кардәшләрем, кемдер кайчандыр белмичә яки ялгышлык белән шушы гөнаһка кергән икән, беренчедән тәүбә итеп, Аллаһыдан ярдәм сорасын. Икенчедән, бар көчен шушы рөхсәт ителмәгән ипотека-кредитларын тизрәк каплауга куйсын. Башкача шушы гөнаһка кермәскә ихлас вәгъдә итсә, Аллаһы Тәгалә аны гафу итәр.

Шулай ук кемдер элек белмичә банкка яки башка оешмага акча салып, шуннан процентлар белән арттырып алган икән, бу акчаның да харам ризык булуын белсен. Галимнәребез мондый процент акчасын мохтаҗларга таратырга куша. Әмма бу очракта тараткан кеше садака бирү әҗер-савапларын алмый. Ул бары үз акчасын, керемен харамнан чистарта.

Бүгенге көндә риба бик нык таралса да, бу рибасыз, ипотека-кредитсыз яшәп булмый дигән сүз түгел. Риба ул элек-электән билгеле булган. Алдарак китергән аятьләр дә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм заманында ике гарәп кабиләсе арасында риба аркасында низаг килеп тугач, иңдерелгән. Гомумән мөселман халыклары, үзебезнең татар әби-бабаларыбыз да оста

сәүдәгәрләр булганнар. Алар эшләрен шәригатебезгә туры китереп алып бара белгән, шулай Аллаһыдан бәрәкәт тә килгән.

Инде рибасыз тормыш алып баруны авыр дип күргән кешеләргә шундый бер кыйсса китерәсем килә. Бервакыт Сөләйман пәйгамбәр бер бодай бөртеген күтәреп барган кечкенә генә кырмысканы очраткан. Сөләйман галәйһиссәлам хайваннар, бөҗәкләр телләрен белгән, шуңа ул кырмыскадан: «Әссәламү галәйкүм, кырмыска! Син бу бодай бөртеген күтәреп барасың, ул озакка җитәме соң?» — дип сораган. Кырмыска: «Вәгаләйкүм әссәлам, Сөләйман пәйгамбәр! Әйе, бер бодай бөртеген мин бер ел буе ашыйм», — дип җавап кайтарган. Пәйгамбәр гаҗәпләнгән һәм моны тикшереп карарга булган, кырмыска ризалашкан. Сөләйман галәйһиссәлам кырмысканы бодай бөртеге белән бер савытка салып каплаган һәм бер елдан соң ачарга вәгъдә иткән. Бер ел үткәч, савытны ачса, күрә: кырмыска бодай бөртегенең яртысын гына ашаган икән. Бу хакта сорагач, кырмыска бик мәгънәле җавап кайтарган. Ул болай дигән: «Әйе, елына мин бер бодай бөртеге ашыйм. Әмма ул ризыкны миңа Аллаһы Тәгалә бирә, ә мин Аның киң рәхмәтенә тәвәккәл кылам. Ә бу юлы исә минем ризыгым зәгыйфь адәм баласының кулында иде. Бәлки син мине бер елдан ачарга да онытыр идең. Шуңа мин ризыгымны кысып тоттым, бодайның яртысын гына ашадым, яртысын киләчәккә калдырдым», — дигән.

Газиз дин кардәшләрем, шушы кечкенә кырмыска Аллаһының рәхмәтенә тәвәккәл кыла белгән, ә дөньядагы иң бай, иң дәрәҗәле кеше булган Сөләйман пәйгамбәрнең зәгыйфь кол икәнен аңлаган, ризыгын дөрес тота белгән. Ә без, кешеләр, еш кына булганына шөкер итмичә, яңаракны, зурракны, заманчараракны алырга ашкынабыз, ахырын уйлап бетермибез. Без дә матур рекламаларга алданып, булган хәләл ризыгыбызны харамга алыштырмыйк, риба гөнаһыннан нык сакланыйк, үзебез, гаилә әһелләребезгә харам ашатмыйк. Әгәр Аллаһы Тәгалә безгә бүген ниндидер ризыкны, байлыкны бирми икән, булганына шөкер итеп, дөрес итеп тота белик, һавадагы торнага алданмыйк.

Раббыбыз барчабызга хәләл кәсеп вә ризыклар гына бирсен. Галимнәребез, эшмәкәрләребезгә җиңеллек вә тәүфикъ биреп, өммәтебез өчен кылган эшләренә хәерле әҗер-савапларын әйләсен, илебездә Ислам финансларын үстерергә насыйп кылсын! Әмин!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә Рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Шамил хәзрәт Әхмәтгалиев,*
*Арча районы Хәсәншәех авылы мәчетенең имам-хатыйбы*

*15 нче ноябрь вәгазе,*

*җөмәдәл-әүвәл аеның 13 нче көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# «Йәсин» сүрәсе — Коръәннең калебе

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барча галәмнәрне юктан бар кылып, тәрбияләп торучы Аллаһы Тәгаләгә мактауларыбыз булсын. Галәмнәргә рәхмәт итеп җибәрелгән, динне аңлаткан, өйрәткән, үрнәк булып яшәп күрсәткән пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән чыккан салават-шәрифләребез ирешсен. Аллаһы Тәгалә изге җомга көнендә мәчеткә килеп кылган гыйбадәтләребезне кабул кылсын. Атлап килгән һәрбер адымнарыбыз саен әҗер-савапларын насыйп итсен. Ниндидер бик җитди сәбәпләр, авыртулар килеп чыгу аркасында гына килеп җитә алмаган мөселман кардәшләребезгә күңелләрендәге булган ниятләренә, күңелләрендәге булган омтылышларына карап Аллаһы Тәгалә әҗер-савапларын насыйп кылсын. Вәгазьләнеп иман байлыгыбызны арттырырга, дөнья вә ахирәт өчен файдалы сүз, файдалы фикер аңларга һәрбарчабызга насыйп булсын.

Мөхтәрәм мөселманнар, Аллаһының безгә булган зур рәхмәте бүген дә җомга намазына килергә насыйп итте. Аллаһы Тәгалә безне иң хәерле көнне — җомга көнне, иң хәерле урынга — мәчеткә, иң хәерле гамәл кылырга — намаз укырга — җыйды. Бу изге гамәлләребезне дәвамлы итсен. Җитди сәбәпсез фарыз, мәҗбүри булган җомга намазын калдырудан Аллаһы сакласын.

Белгәнебезчә, Аллаһы Тәгалә җирне, күкләрне, кешеләрне, барча галәмне бар кылды, шушы җиргә кешеләрне сынау өчен җибәрде. Аларны

дөньяда үзләрен ялгыз гына калдырмады. Дөньяда яшәгәндә адашмасын, саташмасын өчен, илчеләрен, пәйгамбәрләрен җибәрде. Кешеләр җирдә дөрес, матур, бәхетле яшәсеннәр өчен, пәйгамбәрләрен җибәреп, Үзенең динен аңлатты. Безгә соңгы, ахырзаман пәйгамбәрен — Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне — җибәрде. Аңа Үзенең Китабы булган Коръәни Кәримне иңдерде.

Коръән — Аллаһы сүзе, Аллаһы кәламе, Кыямәт көненә кадәр үзгәрмичә сакланачак изге Китап. Коръәннең Аллаһыдан булуына бер дәлил — аны күпме генә укысаң да, ул туйдырмый. Гади генә мисал: намаз укыганда без һәр рәкәгатьтә «Фатиха» сүрәсен укыйбыз. Санасак, көненә фарыз, вәҗиб, сөннәт намазларда ул барлыгы 32 мәртәбә укыла, 1 елга 11 680 мәртәбә килеп чыга. Бер кеше дә «Фатиха» сүрәсен укый-укый туйдым дип әйтми. Чөнки ул — Аллаһы Тәгалә сүзе. Әгәр кеше сүзе булса, туйдырыр иде. Кеше сүзе булган китаплар, әсәрләр, шигырьләр, никадәр матур, камил булсалар да, күп укыгач, туйдыралар. Бер тапкыр укыган китапны еш кына хәтта икенче тапкыр да укыйсы килми. Ә Коръән китабының сүрәләрен күп мәртәбә укысаң да, тагын, тагын укыйсы килә.

Коръәни Кәримнең укыган һәр хәрефе өчен Аллаһы Раббыбыз 10 савап насыйп итте. Дөньяда башка мондый бер генә китап та юк. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм мөселманнарны сөендереп, бу хакта хәдисендә әйткән: «Коръәннән бер хәреф укыган өчен бер яхшы гамәл языла, ә һәрбер яхшы гамәл өчен ун әҗер бирелә. Һәм мин: «Әлиф, Ләм, Мим ул — бер хәреф», — дип әйтмим, юк. Әлиф — хәреф, Ләм — хәреф һәм Мим — хәреф». Бу хәдистән аңлашылганча, Коръәннең һәр хәрефе өчен кешегә ун әҗер языла. Башка дини әдәбият укысак та, хәтта сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисләрен укысак та, андый савапка ирешә алмыйбыз. Дөрес аңларга кирәк, башка китаплар укымаска дигән сүз түгел, аларны да укырга кирәк, аларда да күп хикмәтләр, файдалар була. Монда Коръәннәң башка китаплардан никадәр өстен булуын күрәбез, аңлыйбыз.

Газиз дин кардәшләрем! Коръәни Кәрим аны укучы кешене Кыямәт көнендә яклаячак, аның өчен шәфәгать кылачак. Хәзрәти Әбү Үмәмә радыяллаһу ганһедән мондый хәдис риваять ителә: «Мин Аллаһының Илчесе галәйһиссәламнең: «Коръәнне укыгыз, чөнки, дөреслектә, Кыямәт көнендә ул укыганнар өчен шәфәгатьче булып киләчәк», — дип әйткәнен ишеттем». Куркыныч Кыямәт көнендә Коръән безгә якын, безне яклаучы була ала икән. Кайчан шулай булачак? Хәзер, бу дөньяда без Коръәнне яратып, якын итеп, аны гел укырга тырышсак. Ләкин Коръәнне без бүген шулай якын күрәбезме, күп итеп укыйбызмы?

Коръәнне ятлау, яттан уку, кабатлау мөселманның дөнья һәм ахирәт дәрәҗәләренә күтәрелүенә сәбәп булачак. Беләбез, бу дөньяда җәмгыятебездә төрле дәрәҗәләр бар. Мөселман кешесе дөньяда да дәрәҗәле булырга, матур, яхшы итеп яшәргә тырышыр һәм башкаларга хәерле үрнәк булырга омтылыр. Шулай ук җәннәттә дә дәрәҗәләр, баскычлар булуы билгеле. Җәннәттә югарырак дәрәҗәдә булган саен, җәннәт нигъмәтләре дә күбрәк, яхшырак булачак. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм шулай дигән: «Коръәнне яттан белгән кешегә: «Укы һәм күтәрел, дөньяда укыган кебек ачык итеп укы, җәннәттәге урының, дәрәҗәң синең соңгы укыган аятькә туры килер». Моннан аңлашыла ки, кеше Аллаһы ризалыгы өчен Коръән аятьләрен никадәр күбрәк ятласа, Коръән кушканча яшәргә тырышса, җәннәттә дәрәҗәсе шуның кадәр югарырак булачак. Мәңгелек булган җәннәт сигездер, һәрберсендә 100 баскыч, 100 дәрәҗә бар. Бер баскыч белән икенче баскыч арасы — йөз еллык юл, диелә Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең хәдисендә. Иң түбән дәрәҗәдәге җәннәттәге нигъмәтләр ун җир шары кадәр булачак. Өстәрәк булган җәннәт нигъмәтләрен күзаллап та булмый.

Мөхтәрәм кардәшләр, һәркем үзенә максатлар куйсын. Кем әле Коръәнне укый белмәсә, гарәп хәрефләрен, тәҗвид кагыйдәләрен өйрәнсен. Кемдер инде Коръән укый белсә, күбрәк сүрәләр ятларга тырышсын. Кемдер ятлаган сүрәләренең тәрҗемәсен, мәгънәләрен аңлап укуга ирешсен. Бүгенге

көндә Коръәнне укырга өйрәнергә бөтен мөмкинлекләр бар, шуның кадерен белик. Мәчетләрдә, мәдрәсәләрдә укулар оештырылган. Әле истә, 1990 елларда әтием Кукмарадан Казанга кадәр поезд белән барып, бер бабайда, аның фатирында тәҗвид дәресләре алганы. Шул бабай берничә тәҗвид кагыйдәсен өйрәтә, әтием икенче атнада Казанга барып, өй эшен тапшыра, яңа дәрес ала. Шулай Коръән укырга өйрәнде. Шулай итеп безнең әти-әниләребез, әбибабайларыбыз тырышып Коръәнне укырга өйрәнгәннәр, укыганнар. Без дә Коръән укучылар булып, балаларыбыз, оныкларыбыз да Коръән укучылар, динебезне дәвам итүчеләр булсын, дип тырышыйк, җәмәгать.

Аллаһыга шөкер, Ислам динен тотып яшибез. Намазлар укыйбыз, мәчетләргә йөрибез, Коръән мәҗлесләрендә катнашабыз. Коръән мәҗлесләрендә Коръән аятьләре, сүрәләр укып дога кылына. Мәҗлесләрдә «Йәсин» сүрәсе еш укыла. Хәдисләрдә «Йәсин» сүрәсенең фазыйләтләре, өстенлекләре турында аерып әйтелә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кем Аллаһының рәхмәтен өмет итеп «Йәсин» сүрәсен укыса, аның элекеге гөнаһлары кичерелер. Аны үлгәннәргә укыгыз», — дип әйткән. Башка бер хәдистә Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Үлгәннәргә (яки үлем түшәгендә ятучыларга) «Йәсин» сүрәсен укыгыз», — ди. Бу хәдискә нигезләнеп, кайбер галимнәр тормышта нинди генә авыр хәл вакытында «Йәсин» сүрәсе укылса, шул хәл җиңеләер, үзгәрер, диләр. Шулай ук бу сүрә үлем түшәгендә ятучы янында укылса, Аллаһының рәхмәте, бәрәкәте төшүгә сәбәп булып, җан чыгуын җиңеләйтер, диләр. Яки Аллаһы Тәгаләдән җиңеллек килүгә, шифа килүгә, сәламәтләнеп китүгә сәбәп булыр, иншәАллаһ.

Шулай ук бер хәдистә Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Һәр нәрсәнең калебе, йөрәге (ягъни мөһим өлеше) бар, ә Коръәннең калебе ул — «Йәсин» сүрәсе. Мин бу сүрәнең минем өммәтемдәге һәр кешенең күңелендә булуын (ятлауларын, еш укуларын) бик телим».

Олуг галим имам әл-Куртуби, «Йәсин» сүрәсенең кыйммәтен, өстенлеген ассызыклап, мондый хәдисләр китерә:

1. «Берәү каберстанга кереп, «Йәсин» сүрәсен укыса, Аллаһы аларның (кабердә ятучыларның) хәлләрен җиңеләйтер».

2. «Кем әти-әнисенең яки берсенең каберенә барып, алар янында «Йәсин» укыса, аларның гөнаһлары кичерелер».

Хөрмәтле дин кардәшләрем, бу сүрәне үзебез өчен дә, әрвахларыбыз рухына багышлап та ешрак укырга тырышыйк, аның фазыйләте бик зур.

Аллаһы Тәгалә безне Коръәнне яратучылардан, Коръәнне укучылардан, Коръән белән гамәл кылып яшәүчеләрдән кылсын! Аллаһы Тәгалә кылган изгелекләребезне кабул кылып, изгелекләребезнең файдаларын дөньяда һәм ахирәттә күреп сөенергә насыйп итсен. Җәннәтләрдә күрешергә, бер-беребезне күреп сөенергә, шатланырга барчабызга насыйп кылсын.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә Рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рифат хәзрәт Ибраһимов,*
*Кукмара районы Зур Сәрдек авылы имам-хатыйбы,*
*Кукмара мәдрәсәсе мөгаллиме*

*22 нче ноябрь вәгазе,*

*җөмәдәл-әүвәл аеның 20 нче көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Аллаһы Тәгаләнең «Әл-Мөҗиб» күркәм исеме

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Бар галәмнәрне юктан бар кылып, безләрне тәрбияләп һәм нигъмәтләндереп торучы бердәнбер Раббыбыз, Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгаләгә барча мактауларыбыз, рәхмәт һәм шөкерләребез булсын. Шәһадәт китерәмен: Аллаһыдан башка илаһ юк, һәм шәһадәт китерәм: Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм — Аллаһының хак илчесе, тугры пәйгамбәре һәм Аның яраткан колы.

Иң элек үземне, аннан соң сезне тәкъвалыкка чакырам. Коръәни Кәримдә Аллаһы Тәгалә әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ حَقَّ تُقَاتِهِ وَلَا تَمُوتُنَّ إِلَّا وَأَنتُم مُّسْلِمُونَ ﴿١٠٢﴾

**«Ий иман китерүчеләр!** [Әмерләрен тотып, тыйганнарыннан тыелып] **Аллаһыдан тиешенчә куркыгыз һәм мөселманнар булып кына үлегез!»**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:102

Хөрмәтле җәмәгать! Мөселман кешесе Раббысы белән булган элемтәне ныгытуга омтылырга тиеш. Син Аллаһы Тәгалә турында нинди фикердә булсаң, Ул сиңа карата шундый булыр.

Хәзрәти Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе риваять иткән кодси хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтә: «Аллаһы Тәгалә әйтте: «Минем колым Минем хакта ничек уйласа, шулай булырмын».

Аллаһы Тәгаләнең исемнәрен белү, аларны өйрәнү адәм баласын Раббысына якынайта, аның нәфесен тәрбияли, Аллаһы Тәгалә белән булган элемтәне ныгыта. Без Аллаһыны күбрәк таныган саен, Аның турында күбрәк белгән саен, үзебезнең Аңа мохтаҗ булганыбызны аңлыйбыз. Аллаһы Раббыбыз Үзенең Китабында «Әл-Әгъраф» сүрәсендә болай дип әйтә:

وَلِلَّهِ الْأَسْمَاءُ الْحُسْنَىٰ فَادْعُوهُ بِهَا ۖ

**«Аллаһыда —** [иң матур һәм иң шәрәфле мәгънәләрне белдергән] **күркәм исемнәр. Аңа шулар белән ялварыгыз...»**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:180

Аллаһы Тәгаләнең исемнәрен өйрәнүнең әһәмиятен күрсәтеп, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтә: «Хакыйкатьтә, Аллаһының 99 исеме бар, бердән кала йөз. Һәм кем аларны әйтеп чыкса (өйрәнсә), шул җәннәткә керер»[1].

Бүгенге вәгазьдә Аллаһы Тәгаләнең المجيب — Әл-Мөҗиб дигән күркәм исеме турында сөйләшеп китәсе килә. Әл-Мөҗиб ул — җавап Бирүче, без сораган догаларга җавап Кайтаручы.

Коръәни Кәримдә Аллаһы Тәгаләнең ошбу исеме «Һуд» сүрәсендә килә. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

فَاسْتَغْفِرُوهُ ثُمَّ تُوبُوا إِلَيْهِ ۚ إِنَّ رَبِّي قَرِيبٌ مُّجِيبٌ ﴿٦١﴾

**«... Сез Аңардан ярлыкау сорагыз, шуннан Аңа тәүбә кылыгыз. Һичшиксез, минем Раббым — бик якын,** [Үзенә дога кылучыларның теләкләренә] **җавап бирүче».**

«Һуд», 11:61

[1] Имам әл-Бохари, № 2736.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә безгә Аңа дога кылуны, Аннан гына сорау-ялваруны әмер итте. Һәм Ул догаларыбызга җавап бирәчәге хакында вәгъдә итте. Дога — ул Аллаһыга итагать кылу һәм Аның кушканнарын үтәү. Чөнки Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә изге Коръәни Кәримдә безгә болай ди:

وَقَالَ رَبُّكُمُ ادْعُونِي أَسْتَجِبْ لَكُمْ ۚ

«[Ий кешеләр!] **Раббыгыз әйтте: «**[Бертуктаусыз ялварсагыз да, сезгә бер генә җавап та бирмәячәк потлардан ярдәм өмет итүне туктатыгыз да] **Миңа дога** [һәм гыйбадәт] **кылыгыз,** [сораганнарыгызны үтәп] **сезгә җавап** [һәм савап] **бирим...»**

«Гафир / Гафу итүче», 40:60

Шулай ук Раббыбыз безнең догаларыбызга җавап бирүе хакында «Әл-Бәкара» сүрәсендә хәбәр итә:

وَإِذَا سَأَلَكَ عِبَادِي عَنِّي فَإِنِّي قَرِيبٌ ۖ أُجِيبُ دَعْوَةَ الدَّاعِ إِذَا دَعَانِ ۖ
فَلْيَسْتَجِيبُوا لِي وَلْيُؤْمِنُوا بِي لَعَلَّهُمْ يَرْشُدُونَ ﴿١٨٦﴾

«[Расүлем!] **Колларым синнән Минем турында сорасалар, һичшиксез, Мин** [урынга карата якынлык һәм ераклыктан пакьмен, ләкин аларның бөтен хәлләрен белү һәм догаларын кабул итү ягыннан аларга] **бик якын. Дога кылучының догасын Миңа ялварган чагында ук кабул итәм. Миннән кабул итүне сорасыннар һәм Миңа иман китерсеннәр. Бәлки, алар** [дини һәм дөньяви мәнфәгатьләренә ирешеп] **туры юлдан барырлар».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:186

Һәм башка сүрәдә янә болай дип әйтә:

ادْعُوا رَبَّكُمْ تَضَرُّعًا وَخُفْيَةً ۚ إِنَّهُ لَا يُحِبُّ الْمُعْتَدِينَ ﴿٥٥﴾

**«Раббыгызга тыйнаклык белән яшерен дога кылыгыз. Һичшиксез, Ул** [пәйгамбәр булырга теләү һәм күкләргә күтәрүне таләп итү кебек мәгънәсез догалар кылып һәм дога кылганда бик каты кычкырып] **чиктән ашканнарны сөйми».**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:55

Газиз дин кардәшләрем, белегез! Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Үзенең рәхмәте белән Аннан сорауны, дога кылуны гыйбадәт иткән. Бу хакта Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең хәдисендә әйтә. Хәзрәти Ногъман бине Бәшир радыяллаһу гәнһедән риваять ителә, Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай ди: «Дога — ул гыйбадәт». Һәм аннан соң түбәндәге аятьне укый: «Раббыгыз әйтте: Миңа дога [һәм гыйбадәт] кылыгыз, [сораганнарыгызны үтәп] сезгә җавап [һәм савап] бирим»[1]. Бу хәдистән без доганың гыйбадәт булуын аңлыйбыз.

Әй Аллаһының коллары, Раббыгыздан сорагыз, Аңа ялварыгыз, Ул — Әл-Мөҗиб, сез кылган догаларга, сораган әйберләргә җавап Бирүче.

Әй Аллаһының коллары, Раббыгызның газабыннан, ачуыннан саклана-сыгыз килә икән, Аңа дога кылыгыз, Аңа мөрәҗәгать итегез. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә болай диде: «Кем Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә дога кылмый икән, Аннан сорамый икән, Ул шуңа ачулана». Бу хәдис Ибне Мәҗә җыентыгында китерелә.

Мөхтәрәм җәмәгать! Аллаһы Тәгаләнең Әл-Мөҗиб — җавап Бирүче — икәнен гел истә тотып, ниндидер сораулар барлыкка килгәндә, сайлау алдында торсак, авырлыклар яки сынаулар килсә, иң элек Аңа мөрәҗәгать итеп сорарга, дога кылырга тиешбез.

أَمَّن يُجِيبُ الْمُضْطَرَّ إِذَا دَعَاهُ وَيَكْشِفُ السُّوءَ وَيَجْعَلُكُمْ خُلَفَاءَ الْأَرْضِ ۗ
أَإِلَٰهٌ مَّعَ اللَّهِ ۚ قَلِيلًا مَّا تَذَكَّرُونَ ﴿٦٢﴾

[1] Имам әт-Тирмизи, № 2969; Әбү Давыд, № 1479.

**«**[Үзләренә дога кылучыларны белә дә алмаган потлар яхшыракмы] **Әллә Үзенә дога кылган чакта кыенлыкта калучыга җавап биргән, начарлыкны бетергән һәм сезне** [элекке өммәтләр артыннан] **җирнең** [идарә ителүенә вәкаләтле] **хәлифәләр кылган Затмы? Аллаһы белән бергә-бер илаһ бармы? Бик аз үгетләнәсез шул!»**

«Ән-Нәмл / Кырмыскалар», 27:62

Әл-Мөҗиб — ул сораучыларның ялваруларына һәм догаларына җавап Бирүче.

Әл-Мөҗиб — ул авырлыкка эләккән, сынаулар килгән кешегә ярдәм Итүче, чишелеш юлларын Ачучы.

Әл-Мөҗиб — ул хаҗәтләре булганнарның хаҗәтләрен Үтәүче.

Әл-Мөҗиб — ул безгә гел ярдәм Итүче.

Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтә: «Чынлыкта, сезнең Раббыгыз Оялчан, Юмарт. Әгәр дә колы дога кылып, Аңа кулларын күтәрсә, Ул аларны җавапсыз кайтарырга ояла»[1].

Әмма, җәмәгать, кайбер вакытта шундый куркыныч сүзләр ишетергә туры килә, кайберәүләр әйтә: «Мин дога кылам, сорыйм, ләкин Аллаһы Тәгалә миңа җавап бирми». Яки кеше Аллаһы Тәгаләнең доганы кабул итүендә шикләнә, яки ашыктыра. Аллаһы Тәгалә — Әл-Мөҗиб, җавап Бирүче, һәм моңарда шикләнергә ярамый! Ләкин ни өчен кайбер вакытта без догаларыбызга җавапны күрмибез? Кайбер вакытта кеше бик күп дога кыла, әмма Аллаһы Тәгалә аларны кабул итми. Бу доганың кабул булуына комачаулый торган сәбәпләргә бәйле булырга мөмкин. Бу сәбәпләрнең кайберләре мондый:

— гөнаһлар кылу;

— харам ризык ашау (һәм монда сүз хәләл ит турында гына түгел, ә гомумән ризыкны нинди юл белән табылган, килгән акчага сатып алуда да);

[1] Имам әт-Тирмизи, № 3556.

— Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылудан баш тарту;

— Аллаһының сиңа җавап бирүендә шикләнү;

— җавапны ашыктыру.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтә: «Җавап бирелүенә чын күңелдән инанган хәлдә Аллаһыга дога кылыгыз. Һәм белегез: Аллаһы Тәгалә гафил йөрәкле, күңеле Аннан башка нәрсәгә бәйле кешенең догасын кабул итми»[1].

Шулай ук монда Имам әл-Бохари китергән хәдисне искә аласы килә. Ул хәзрәти Әбү Сәгыйть әл-Ходридән риваять ителгән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Әгәр дә берәр мөселман гөнаһ яки туганлык җепләрен өзү белән бәйле булмаган нәрсәне сораса, Аллаһы аңа өч нәрсәнең берсен бирер: яки ул аңа сораган нәрсәсен тизләтер, яки сораганын бирми, аны ахирәткә савап буларак калдырыр, яки аны берәр зарардан саклар». Моны ишеткәч, хәзрәти Әбү Сәгыйть әл-Ходри радыяллаһу ганһе: «Алайса без күп итеп дога кылачакбыз», — дип әйткән. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм исә аңа: «Аллаһы догаларны күбрәк кабул итә», — дигән[2].

Раббыбыз — Әл-Мөҗиб, җавап Бирүче! Ул безнең Аңа мөрәҗәгать итүебезне көтә. Моны онытмаска тиешбез. Һәрдаим Аллаһы Раббыбызны истә тотып, Аңа ялварып, Аңа рәхмәтле булып, шөкер итүче бәндәләрдән булырга тиешлебез. Әгәр без Аннан сорасак, Аңа дога кылсак, Ул безгә чишелеш юлларын бирер, җиңеләйтер, безгә Үзенең ярдәмен күрсәтер.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә

[1] Имам Хәким, «Мөстәдрак».

[2] Имам әл-Бохари, № 710.

дә Рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Хәлил хәзрәт Хайбрахманов,*
*Түбән Кама шәһәренең Тәхфиз мәркәзе җитәкчесе,*
*БИА магистранты*

*29 нчы ноябрь вәгазе,*

*җөмәдәл-әүвәл аеның 27 нче көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# «Бурычлы үлмәс, әмма көн дә күрмәс»

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Галәмнәрне юктан бар итүче, яратучы Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә барча хәмед-сәналәребез, мактауларыбыз булса иде. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән шытып чыккан барча салават-шәрифләребез булса иде.

Мөхтәрәм дин кардәшләрем, Аллаһының колы булып яшәү — чиксез бәхет. Ләкин адәми затның бер колы булып яшәү — иң авыр, иң түбән нәрсәләрнең берседер. Хәзер, әлбәттә, коллык заманасы түгел, ләкин бурыч дигән бер афәт бар. Һәм бурычлы булу — шул коллыкка тиң бер халәт инде ул, җәмәгать.

Әйе, тормышта төрле хәлләр күзәтелә. Адәм баласының ризыкка, саулыкка мохтаҗлык кичергән чаклары да була. Кесәдән шунда ук алып түләргә акча таба алмаганда, күршебез йә туганыбыздан, дусларыбыздан әҗәткә алырга туры килә. Бүген син аласың бурычка, иртәгә мин алырга мөмкинмен. Бер-беребезгә ярдәм итешеп, тормышны шулай алып барабыз. Бу бүген генә барлыкка килмәгән, электән үк шулай килә. Тик шушы әҗәт дигән нәрсә аркасында күпме золымлык кылына? Күпме туганлык, дуслык, кардәшлек җепләре өзелә? Күпме кеше бурычлы килеш үлеп китеп, үзен генә түгел, гаиләсен, туганнарын авырлыкка төшерә?

Динебез безгә бурычка, әҗәткә алырга рөхсәт итә. Әмма бер-беребез белән мөнәсәбәтләр бозылмасын, бер-беребезнең хакларын бозмас өчен, гөнаһка кермәс өчен, бу эшнең билгеле тәртипләре, әдәпләре дә билгеләнгән. Тарихтан без беләбез, хәтта иң яхшы мөселманнар — сәхабәләр дә, алай гына түгел, хәтта сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә авыр вакытта бурычка кергән. Һәм ул үзенең мисалында бу эштә безгә күркәм үрнәк күрсәткән.

Беренчедән, адәм баласы бурычка бик мәҗбүр ителгән хәлдә генә сораса, хәерлерәк. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисендә әйткән: «Кешегә әйбер сорап бару ул үзеңнең битеңне тырнау белән бер», — дигән. Шуның өчен, әлбәттә, сорамау — яхшырак. Шулай ук хәдисләрнең берсендә: «Бурычтан сакланыгыз! Дөрестән дә, бурыч ул — төннәрен кайгыру, көндезен исә кимсенү сәбәбедер», — диде Расүли Әкрам.

Икенчедән, нәрсәнедер әҗәткә алганда, шул әҗәтне вакытында кайтаруны ныклап ниятләргә кирәк. Бу бик мөһим, чөнки мөбарәк хәдисләрдән билгеле булганча, әҗәтне кире кайтару нияте белән алучыга Аллаһы Тәгалә Үзе ярдәм итә. Һәм, киресенчә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әҗәтен кайтарырга да ниятләми бурычка алучы кеше Раббысы хозурына бур, карак хәлендә кайтыр», — дигән.

Әҗәтле булуын онытмыйча, моңа җаваплы карап борчылган кешегә Аллаһы Тәгалә хәтта махсус сакчылар куя: саклаучы фәрештәләр бу кешене бәла-казалардан саклый, имин булуын кайгырта... Бәлки шуңа күрә дә халыкта «әҗәтле үлмәс» дигән әйтем дә йөридер.

Өченчедән, әгәр кеше бурычка кергән икән, ул хәтта садака бирергә, хаҗ кылырга һәм чыгымнар таләп иткән башка изгелекләр эшләргә дә хаклы түгел. Әҗәтле кеше әҗәтен кайтаруны үзенең иң беренчел максаты итеп куярга тиеш. Галимнәребез билгеләп үткәнчә, ул хәтта ашауда да артыклык күрсәтмәскә, әйтик, җиләк-җимешләрдән, башка кыйммәтле ризыклардан баш тартырга тиеш.

Шушы хәдисләрдән күренгәнчә, бурычка керү бик җитди адым, ул зур җаваплылыкны таләп итә.

Шәригатебез буенча мохтаҗлыкка, авыр хәлгә тарыган кешегә әҗәткә акча биреп, аның хәлен җиңеләйтү, булдыра алганча ярдәм итү саваплы гамәлләрдән санала. Әйе, ишетеп-белеп торабыз, кеше башына көтелмәгәндә кайгы килергә мөмкин. Мәсәлән, кемгәдер баласын дәвалауга фәлән миллион акча кирәк, дип әйтәләр. Әлбәттә, мондый очракта кеше рөхсәт ителгән юллар белән акча эзләргә тиеш: ул бурычка да керә, хәйрия фондларына да барып сорый. Бу дин кардәшләребезгә без дә берләшеп ярдәм итәргә тиеш.

Әмма акча сорап килгән кешенең мохтаҗлык дәрәҗәсен белү, шул акчаны ул нинди максатларга тотарга ниятләгәнен ачыклау да мөһим булып тора. Чөнки, мәсәлән, әгәр кеше чыннан да ярдәмгә мохтаҗ икән, аңа әҗәткә бирү — сөннәт, ягъни саваплы гамәлдер. Һәм, киресенчә, әҗәткә сорап килүче акчаны аракыга, отышлы уенга һәм башка шундый гөнаһлы эшләргә сорарга мөмкин. Бу очракта аңа акча бирү тыелган. Әгәр без сораучының төгәл исерткеч эчемлекләр эчүен яки отышлы уеннар уйнавын белсәк, аңа акча бирмичә, башка төрле ярдәм тәкъдим итәргә тиешбез. Мәсәлән, аңа кибеттән ризык алып бирергә була.

Әйе, бүген шактый кешене «кайда гына әҗәткә алыйм икән» дигән мәсьәлә борчый, ләкин «алынган акчаны ничек кайтарырмын?» дигән уй башына килми торганнар бик күп. Шунысы да бар: кайберәүләр әҗәтләрен чыннан да кайтара алмаганга кайтармый. Әмма кайбер кешеләр, мөмкинлекләре була торып та, кеше акчасын кайтаруны мөһим эшкә санамый. Шундыйлар, әҗәтләре булуга карамастан, яңадан-яңа кием ала, машиналарын яңарта, фатирларында ремонт ясый, ягъни үзенә кирәклегә акча таба, ә әҗәтне кайтарырга — юк. Исләренә төшерә башласаң, шундыйлар әрсезләнеп, аралашудан баш тарта, шалтыратсаң, телефонны сүндерә, килсәң, ишекне ачмый. Бу, әлбәттә, бернинди әдәп кысаларына сыймый. Шулай аралар бозыла, кайвакыт хәтта туганнар арасында да дуслык бетә.

Пәйгамбәребез гәләйһиссәламнең бер хәдисендә бу хакта болай диелә: «Әгәр әҗәтен кайтарырга мөмкинлеге була торып та, әҗәтле кеше моны эшләмәсә, ул башкаларны кыерсытучы залим кебек булыр һәм аңа бу гөнаһка тиң җәза бирелер». Башкаларны шулай борчып, әҗәтен кайтармыйча йөргән кешегә Аллаһы ачу күзе белән карар һәм ул тормышындагы бәрәкәтен югалтуы ихтимал.

Мәгълүм мәкальдә «әҗәтле үлмәс» дип әйтелсә дә, чынлыкта, беркем дә бу дөньяда мәңгегә калмый. Хәдисләрдән беләбез, кеше әҗәтләрен кайтармыйча үлеп китсә, аның киләчәк тормышта хәле бик мөшкел булыр! Аллаһы Тәгалә Үзе сакласын. Шуңа күрә җеназа алдыннан да кешенең бурычлары турында сорала. Мондый очракта, әлбәттә, бу йөк кешенең гаиләсенә, туганнарына күчә яки бурычка биреп торган кеше аны гафу итәргә мөмкин.

Газиз дин кардәшләрем, менә монда төрле аңлашылмаучанлыклар да килеп туарга мөмкин, чөнки бу мал, байлык мәсьәләсе. Әә Аллаһы Раббыбыз безгә мондый бәхәсләрнең чишелеш юлын күрсәткән. Коръәни Кәримнең иң озын аяте — бу «Әл-Бәкара»ның 282 нче аяте — бурычка бирүгә багышланган һәм ул бик мөһим кагыйдәне өйрәтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا إِذَا تَدَايَنتُم بِدَيْنٍ إِلَىٰ أَجَلٍ مُّسَمًّى فَاكْتُبُوهُ ۚ وَلْيَكْتُب بَّيْنَكُمْ كَاتِبٌ بِالْعَدْلِ ۚ وَلَا يَأْبَ كَاتِبٌ أَن يَكْتُبَ كَمَا عَلَّمَهُ اللَّهُ ۚ فَلْيَكْتُبْ وَلْيُمْلِلِ الَّذِي عَلَيْهِ الْحَقُّ وَلْيَتَّقِ اللَّهَ رَبَّهُ وَلَا يَبْخَسْ مِنْهُ شَيْئًا ۚ

«**Ий иман китерүчеләр! Билгеләнгән бервакытка кадәр берберегезгә бурыч бирсәгез,** [бәхәс-тартышуларга юл ачмас өчен] **аны** [теркәп] **языгыз.** [Ышанычлы] **Язучы арагызда** [аерма ясамыйча] **гаделлек белән язсын. Яза белгән беркем дә Аллаһы** [язу сәнгатенә] **өйрәткәнчә** [дөрес итеп] **язудан баш тартмасын, язсын. Өстендә** [үтәләсе] **хак булган** [бурычлы] **кеше исә** [бурычын дөрес итеп] **яздырсын,** [кайтарырга тиешле хакны яшерүдән] **Раббысы**

**Аллаһыдан курыксын һәм аннан** [бурычтан] **бернәрсәне дә киметмәсен...»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:282

Димәк, бурычка биргәндә һәм алганда, Раббыбызның әмерләрен үтәп, без акчаның күләмен һәм кайтарылачак вакытын язып теркәп куярга тиешбез. Әдәп ягыннан, моны беренче булып бурычка сораучы тәкъдим итсә, яхшырак була. Әмма ул әлеге кагыйдәне белмәсә яки онытса, бурычка бирүче кеше: «Кардәшем, Раббыбызның әмерен үтәп, язуда теркәп куйсак (расписка ясасак), бик күркәм булыр», — дип әйтергә кыенсынмасын. Шушы «расписка» ул ике якны да яклый, һәм берсе үлеп киткән очракта да, варисларга эшне җиңеләйтә.

Хөрмәтле мөслеманнар, әҗәткә алыргамы, әҗәткә бирергәме — шәхси эшебез. Тик шушы әҗәт аркасында золымлык, нәфрәт, дошманлык тумасын өчен, бурычка алып торучы аны кайтару нияте белән алсын һәм вакытында кайтарсын. Ә әҗәткә биреп торучы исә, биргәндә — кайтармасалар да риза булырлык итеп, яисә, вакытында кайтармасалар, кичектерергә риза булып бирсен.

Халкыбызда «бурычка баткан» дигән гыйбарә бар. Чыннан да, кайбер кеше бер мәртәбә бурычка алса, аннан соң кабат-кабат ала, бурычларыннан котыла алмый, әйтерсең лә бер сазлыкта бата ул. Бурычлардан котылу өчен күп кенә догалар да билгеле. Мәсәлән:

اللَّهمَّ اكْفِني بِحَلالِكَ عَن حَرَامِكَ، وَاغْنِني بِفَضْلِكَ عَمَّن سِوَاكَ

Аллаһүммә-кфинии бихәләәликә ган хәраамикә вә әгънинии бифәдъликә гаммәң сивәәк.

«Аллаһым! Миңа, харамнан сакланып, хәләл белән генә канәгатьләнергә насыйп әйлә. Раббым, Синең мәрхәмәтеңнән кала, башкасына мохтаҗ әйләмә».

Аллаһы Тәгалә барчабызны да бурыч афәтеннән сакласын, мохтаҗлыктан сакласын, бурычлыларга котылу насыйп итсен, әҗәткә биреп торганнарга тиешле әҗер-савапларын насыйп итсен. Әмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә Рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Динар хәзрәт Зыятдинов,*
*Казанның «Борнай» мәчете имам-хатыйбы*

*6 нчы декабрь вәгазе,*

*җөмәдәл-ахыр аеның 5 нче көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Кыш — мөэминнең язы

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, менә без яңа ел фасылына, кышка да аяк бастык. Һәм елның бу фасылы турында хәдисләр, галимнәребезнең бик хикмәтле сүзләре билгеле. Шуларның мәгънәсе турында сөйләшик.

Хәзрәти Әбү Сәгыйть әл-Ходри радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мондый хәдисен тапшырган: «Кыш — мөэминнәр өчен яз»[1].

Хәзрәти Ибне Мәсгүд радыяллаһу ганһедән мондый хәдис тапшырылган: «Рәхим ит, кыш! Кышын бәрәкәт иңә: кышкы озын төннәр — төнге намазлар [уку] өчен [җайлы], ә кышкы кыска көннәр — ураза [тоту] өчен [уңайлы]».

Икенче тугры хәлифә Гомәр бине әл-Хаттаб радыяллаһу ганһе кыш турында болай дигән: «Кыш — гыйбадәт кылучылар өчен [шәп] табыш».

Имам әт-Тирмизи хәдисләр җыентыгында хәзрәти Гамир бине Мәсгүдтән тапшырылган мондый хәдис китерелә: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Җиңел казаныш яки табыш ул — кыш көне ураза тоту», — дип әйткән[2].

Әлеге хәдисләрдән күренгәнчә, мөселман өчен кыш айлары аеруча гыйбадәттә үткәрелә торган ел фасылы булырга тиеш. Шуңа күрә тагын бер

[1] Имам Әхмәд, № 11734.

[2] Имам әт-Тирмизи, № 797; Имам Әхмәд, № 18979.

кат гыйбадәт төшенчәсен искә төшереп китик. Динебездә гыйбадәт нәрсәне аңлата соң?

Бер сүз белән генә аңлатсак, гыйбадәтнең мәгънәсе — «коллык». Әгәр дә киңрәк әйтсәк: «Гыйбадәт ул — кешенең Аллаһы Тәгалә сөйгән һәм разый булган гамәлләрне кылуы».

«Ә ничек соң без кайсыдыр гамәлнең гыйбадәт икәнлеген белдек?» — дип сорар булсагыз, «Без аларны Аллаһының Коръәненә карап, укып, аңлап һәм Аның Илчесе Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм кылган һәм әмер иткән эшләренә, аның аңлатмаларына карап белдек», — дип әйтәбез.

Без бу дөньяга Аллаһыга гыйбадәт кылып яшәр өчен яратылганбыз. Раббыбыз Аллаһы «Әз-Зарият» сүрәсенең 56 нчы аятендә болай ди:

وَمَا خَلَقْتُ الْجِنَّ وَالْإِنسَ إِلَّا لِيَعْبُدُونِ ﴿٥٦﴾

**«Мин җеннәрне һәм кешеләрне Миңа гыйбадәт кылсыннар дип яраттым».**

«Әз-Зарият / Таратучылар», 51:56

Әмма гамәл-гыйбадәтләребез кабул булсын өчен, ике шартны үтәү зарур икәнен дә исебездән чыгармаска кирәк.

Беренче шарт — ихласлылык. Һәрбер эш-гамәлебезне, кылган гыйбадәтебезне ихластан, Аллаһы ризалыгы өчен генә, әҗер-савапны бары Аннан гына өмет итеп кылырга тиешбез. Бернинди рия гамәлләрен кертмичә, кешеләр гамәлеңне күреп мактасыннар, күтәрсеннәр өчен түгел, киресенчә, «Раббым миннән шушы гамәлем белән риза булып калсын» дип башкарырга кирәк. Моңа Аллаһы Тәгаләнең ошбу сүзләре дәлил:

وَمَا أُمِرُوا إِلَّا لِيَعْبُدُوا اللَّهَ مُخْلِصِينَ لَهُ الدِّينَ حُنَفَاءَ وَيُقِيمُوا الصَّلَاةَ وَيُؤْتُوا الزَّكَاةَ ۚ وَذَٰلِكَ دِينُ الْقَيِّمَةِ ﴿٥﴾

> **«Аларга бит** [үзләренең китапларында] **диндә Аңа гына ихлас булып,** [ялгыш ышанулардан ераклашып, бөтен пәйгамбәрләргә инанган] **хәниф кешеләр буларак Аллаһыга гына гыйбадәт кылырга,** [фарыз] **намаз укырга һәм зәкят бирергә әмер ителгән иде. Хак дин — менә шушы».**

«Әл-Бәййинә / Ачык дәлил», 98:5

Икенче шарт — динебезгә туры килү, Сөннәткә муафыйк булу. Ягъни кылган гамәл-гыйбадәтебезнең Сөннәткә туры килүе. Әгәр без, ихлас булып та, диндә булмаган гамәл кылабыз икән, Аллаһы Тәгалә аны кабул итмәс. Чөнки гамәлнең Аллаһы ризалыгы өчен булуы гына җитми, ә ул гамәл-гыйбадәтнең Сөннәттә булуы да мөһим. Диндә, Сөннәттә булмаган гамәл-гыйбадәт бидгать була. Раббыбыз Аллаһы бидгать, ягъни уйлап чыгарылган эш-гыйбадәтләрне кабул итми. Моңа дәлил шул: Аллаһының Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Безнең эшебезгә яңа һәм аңа бәйләнеше булмаган нәрсә кертүченең шул эше кире кагылачак»[1].

«Күңелем изгелектә бит минем, динебездә булмаса да, бу гамәлне кылыйм әле», — дисәк, шуны белик: ул гамәл кабул булмаячак. Шуны онытмаска кирәк: Аллаһы Тәгалә кабул итсен өчен, ул гыйбадәтнең динебездә булуы шарт.

Гыйбадәт ул — кешенең эчке һәм тышкы гамәлләре. «Тышкы» гыйбадәтләр күзгә күренеп торалар. Мисал өчен, көненә 5 вакыт намаз уку, Рамазан аенда ураза тоту, бай кешеләрнең фәкыйрьләргә зәкятләрен бирүләре һәм хаҗ гамәлен үтәүләре, корбан чалу, дога кылу һәм башка шундыйлар.

Ә нинди эчке гамәлләребез гыйбадәт булып санала икән? Бөтен гыйбадәтләрне мөэмин-мөселманнар Аллаһы Тәгалә кушканга, әмер иткәнгә күрә һәм Аның газабыннан курыкканга үти. Эчке гамәл-гыйбадәтләр хакында да аңлатма биреп китик. Эчке гамәл-гыйбадәтләр турында да без Коръән

[1] Имам әл-Бохари һәм имам Мөслим риваятьләре.

беләм хәдисләрдән беләбез. Эчке гамәл-гыйбадәтләр дә, тышкылары шикелле, бер генә төрле түгел, алар да күп төрле:

## 1. Тәвәккәллек.

Тәвәккәл ул — Аллаһының ярдәменә таяну, ягъни бөтен файдаларны бирүче дә һәм безгә бернинди зарарларны җибәрмәүче дә — Аллаһы Тәгалә Үзе генә дип танып, Аның ярдәменә таяну. Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәл кылу олы гыйбадәтләрдән санала. Моңа дәлил — Аллаһының сүзе:

وَعَلَى اللَّهِ فَتَوَكَّلُوا إِن كُنتُم مُّؤْمِنِينَ ﴿٢٣﴾

«... **Әгәр** [Аллаһының сүзенә] **ышанган кешеләр булсагыз, Аллаһыга гына тәвәккәл итегез».**

«Әл-Маидә / Табын», 5:23

## 2. Сабырлык.

Сабырлык та эчке гыйбадәтләрнең бер төре булып санала. Аллаһы Тәгалә сабыр итүче кешеләргә әҗерләрне хисапсыз бирермен, дип вәгъдә кыла. Әгәр дә сабыр иткән өчен әҗер бирелүе аңлашылса, ул чагында аның гыйбадәт икәнлеге дә аңлашыла. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримнең бик күп аятьләрендә мөселманнарга сабыр булырга, сабырлык күрсәтергә әмер итә. Шуларның берсе:

وَاصْبِرْ فَإِنَّ اللَّهَ لَا يُضِيعُ أَجْرَ الْمُحْسِنِينَ ﴿١١٥﴾

«[Расүлем! Кяферләрнең җәфалауларына түз, намаз кебек гыйбадәтләрне дәвам иттереп, гөнаһлардан саклануда] **Сабыр ит. Һичшиксез, Аллаһы игелек ияләренең әҗерләрен юк итми».**

«Һуд», 11:115

## 3. Курку.

Аллаһыдан курку да эчке гыйбадәтләрдән булып санала. Аллаһы Тәгалә моның хакында болай ди:

فَلَا تَخْشَوْهُمْ وَاخْشَوْنِي وَلِأُتِمَّ نِعْمَتِي عَلَيْكُمْ

**«… Сезгә нигъмәтемне камил кылуым өчен алардан курыкмагыз, Миннән куркыгыз».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:150

Ошбу аятьтән Аллаһының Үзеннән генә куркырга тиешле булуы аңлашыла. Әгәр дә Аллаһы Тәгалә куркырга әмер иткән икән, димәк, Аның әмере безнең өчен гыйбадәт булып санала.

## 4. Өмет.

Аллаһыдан өмет итү дә гыйбадәт булып санала. Бу хакта Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

فَمَن كَانَ يَرْجُو لِقَاءَ رَبِّهِ فَلْيَعْمَلْ عَمَلًا صَالِحًا وَلَا يُشْرِكْ بِعِبَادَةِ رَبِّهِ أَحَدًا ﴿١١٠﴾

**«… Моннан соң кем дә кем Раббысы белән очрашуга өмет итә,** [Аның ризалыгына ирешерлек] **игелек кылсын һәм Раббысына гыйбадәттә бернәрсәне дә тиң итмәсен».**

«Әл-Кәһф / Мәгарә», 18:110

Җәннәтне бөтен мөселманнар да өмет итәләр. «Өметсез — шайтан гына» диләр халыкта. Аллаһыдан өмет итү дә гыйбадәтләрдән булып санала.

Гыйбадәт мәсьәләсенә килгәндә, тагын да нечкә бер мәсьәләгә игътибар итү кирәктер — ул мөэминнең гыйбадәт кылганда чыккан күз яшьләре. Нәкъ

менә шул энҗе бөртекләре Аллаһы Тәгалә каршында кыйммәтле. Кыямәт көнендә алар өчен коллар чиксез нигъмәтләргә ия булачак.

Бер хәдистә «Өч кеше иблистән һәм аның гаскәреннән котылачак: тәүлек буена Аллаһыга зикер әйтүчеләр, төннең икенче яртысында Аллаһыдан куркып елаучылар һәм кылган гөнаһлары өчен чын күңелдән тәүбә итүчеләр», — диелә.

Бу кешеләр бер төркемгә бүленеп, төнен һәм көнен «Ләә иләһә илләллаһ» дип Аллаһыны искә алалар. Төнлә торып: «Әстәгъфируллаһ әл-газыйм, әстәгъфируллаһ әл-газыйм», — дигәндә, аларның күз яшьләре чыга.

Әгәр дә күзләр Аллаһыдан куркып яшьләнә икән, шул чакта җәһәннәм уты башка әгъзаларга да кагылмас. Әгәр дә күз яше яңакка тама икән, бу кешенең битенә кара төшмәс. Өммәт эчендә бер генә кеше Аллаһыдан куркып елый икән, бу өммәтне Аллаһы Тәгалә төрле бәлаләрдән саклар. Бөтен нәрсәнең дә үз үлчәме бар. Бу күз яше бернәрсәгә дә охшамаган. «Бер күз яше белән диңгез зурлыгындагы ут учагын да сүндереп була», — дигән әйтем бар[1].

Ибне Хиббан «Сахих»ендә шундый риваять китерелә: «Мин, Гобәйдуллаһ бине Гомәйир, Гайшә радыяллаһу ганһә янына кердем һәм болай дип сорадым: «Сез Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм кылган иң күркәм гамәл турында әйтегез әле». Гайшә анабыз елап: «Бервакыт ул төнлә намаз укырга торды һәм миңа: «Гайшә, мине гыйбадәт кылырга ялгызымны гына калдыр әле», — диде. Мин: «Аллаһы белән ант итәм, мин синең янәшәңдә булырга яратам. Сине бәхетле кылган гамәлләр мине дә шатландыра», — дидем. Ул тәһарәт алып, намаз укырга җыена башлады. Гадәттә намаз укыганда аның тезләре, хәтта әйләнә-тирәсендәге җир дә (күз яшьләреннән) дымлана иде. Шул вакытта азан әйтергә теләп, Билал радыяллаһу ганһе керде һәм Пәйгамбәр галәйһиссәламнең күз яшьләрен күреп: «Ий Расүлуллаһ, син ник елыйсың, Аллаһы Тәгалә синең булган һәм булачак хата-кимчелекләреңне инде кичерде бит?» — дип сорады. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм:

---

[1] «Рамуз әл-әхәдис», № 4587.

«Мин рәхмәтле кол булырга тиеш түгелме? Бу төндә миңа берничә аять иңдерелде. Кем дә кем намаздагы аятьләрнең мәгънәсен белмичә укый икән, шуның хәле бик тә аяныч», — дип әйтте».

Безгә сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормышы үрнәк булып торырга тиеш. Кызганыч, хәзерге заманда безнең күпләребез аның елый-елый намаз укыганын истә тотмый, бик азларыбыз ихластан гыйбадәт кыла.

Тагын бер мөһим мәсьәлә — ул да булса төннәребезне файдалы, нәтиҗәле итеп үткәрү. Чөнки кыш айларында төннәр бик озын, бигрәк тә бу безнең җирлек өчен хас күренеш. Бу форсатны файдага үткәрү тиешледер.

Кардәшләрем, уйланыйк, без шул форсаттан файдаланып, төннәребезне гыйбадәтләр кылып, Аллаһы каршында дәрәҗәләребезне күтәрә торган игелекләр кылып үткәрәбезме-юкмы? Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Файда китерә торган гамәлләрдә тырыш бул»[1], — дигән васыятен истә тотабызмы?

Әгәр дә алтыннан да кадерлерәк булган вакытны дөрес кулланырга өйрәнсәк, бу гамәлебез тормышта зур уңышларга ирешергә ярдәм итәчәк. Кызганыч, без моны буш вакытыбыз күп булган чакта аңлап бетермибез, ә менә эшкә күмелгәч, «их, төннәрен, вакыт булганда эшлисе калган икән», дигән үкенү хисе биләп ала. Гомумән, адәм баласы нәрсәнең дә булса кадерен аны югалткач кына аңлый шул. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә болай дигән бит: «Күп кеше ике нигъмәтнең кадерен белми: сәламәтлекнең һәм буш вакытның»[2].

Безгә, төннең кадерен белүчеләрдән булыр өчен, күп тырышлык куярга кирәк: төне буе телефонда, компьютерда уйнап утырмыйча, күпсанлы интернет челтәрләрдә кеше тормышын тикшермичә, Коръәннән яңа сүрәләр ятласак, көн дә кирәкле догаларны өйрәнсәк, файдалы китаплар укысак,

[1] Имам Мөслим.

[2] Имам әл-Бохари.

аң-белемебезне арттыруда вакытны кулланcак, Аллаһы дәрәҗәләребезне күтәрер. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

يَرْفَعِ اللَّهُ الَّذِينَ آمَنُوا مِنكُمْ وَالَّذِينَ أُوتُوا الْعِلْمَ دَرَجَاتٍ ۚ

**«...Аллаһы да арагыздан иман китергәннәрне һәм гыйлем бирелгән кешеләрне дәрәҗә ягыннан күтәрер».**

«Әл-Мүҗәдәлә / Бәхәсләшү», 58:11

Кыш айларында тагын бер күркәм эш булып Коръәни Кәримне күбрәк ятлау тора. Һәр мәселманның иң изге хыялы, әлбәттә, Коръәнне ятлау буладыр. Коръән укуның, аны яттан белүнең фазыйләтләре, саваплары санап бетергесез. Әлеге эштә мәшһүр хафиз Мишәри Рәшид мондый киңәшләрен биргән булган:

1. Аллаһы ризалыгы өчен ятлау. Кайвакыт кардәшләребезнең гамәлләрен башкаларга күрсәтер өчен башкарганнарын күрәбез. Динебездә исә ихласлылык, эшне Аллаһы ризалыгы өчен башкару беренче урында тора. Шул исәптән имам Мөслим һәм имам әл-Бохари да үзләренең хәдис җыентыкларын ният хакындагы хәдисләр белән башлаганнар.

2. Максат билгеләү. Мәсәлән: «Мин тәҗвид кагыйдәләрен өйрәнгәч, Коръәннән бер җүз ятлаячакмын һәм моңа бар тырышлыгымны куячакмын».

3. Һәрдаим Коръән ятлауга вакыт билгеләү һәм әлеге графиктан тайпылмау. «Иң хәерле эш — дәвамлы эш» дигән гыйбарәне истән чыгармау мөһим.

4. Шөгыльләнергә иң кулай булган вакытны һәм урынны сайлау. Әгәр дә сезгә өйдә укырга балалар комачаулый икән, димәк, сезгә мәчеткә барып өйрәнергә кулайрак булыр.

5. Ятлау өчен билгеле бер Коръән мосхафын сайлау. Галимнәребезнең бу киңәше очраклы түгел, чөнки кешенең күз хәтере бар, димәк, Коръәннең билгеле бер төр шрифтына күнеккәч, аны алыштыру киңәш ителми.

6. Авырлыклардан курыкмау. Гадәттә башлап җибәрүчеләр начар хәтер яисә хәрефләрнең авыр әйтелеше белән бәйле булган мәсьәләләргә

юлыгалар. Әлбәттә, бу вакытлыча күренеш. Ләкин кайбер мөселманнар шайтан вәсвәсәсенә бирелеп, дәресләрен ташлыйлар. Алардан төрле сәбәпләр ишетергә туры килә: «Мин мәктәптә дә начар укыдым, миннән булмас инде» яисә «Мин картайдым, зиһенем дә юк».

7. Коръәнне үзлектән үзләштерәсез икән, дөреслеген белүче кешедән тикшертегез.

8. Коръәнне укыганда кычкырып укырга тырышыгыз. Башта бер аятьне өйрәнегез, аннан икенчесен ятлагыз, аннан соң икесен бергә кушыгыз. Шул рәвешле дәвам итегез. Тәһарәтле булыгыз. Укыган вакытта төз утырыгыз, сезнең утырышыгыз җитди укуга ишарә итсен — бу әдәп мәсьәләсенә кагыла.

9. Ятлаган аятьләрегезне туганнар, дусларыгыз каршында укып күрсәтегез — булган кимчелекләр ачыкланыр, үз-үзегезгә ышанычыгыз артыр, вакытыгызны саваплы гамәл белән үткәрерсез.

10. Өйрәнгән сүрәләрегезне кабатлап торырга, бигрәк тә аларны намаз кылганда укырга тырышыгыз.

11. Аллаһы Тәгалә белемнәрегезне дәвамлы, зиһенегезне зирәк кылсын өчен, гөнаһлардан сакланыгыз, гайбәтне калдырыгыз.

12. Мөмкин кадәр күбрәк Коръән уку түгәрәкләренә йөрегез. Җәмәгать намазларыннан соң да бергәләп мәчеттә калып, Коръән уку бик файдалы булыр.

13. Гыйлем эстәүче үзенең ашавына да игътибар итәргә тиеш: чамадан артык ашау зиһенне чуалта һәм шәһвәткә тарта.

14. Инде ниһаять беренче нәтиҗәләргә ирешкәннән соң, тәкәбберлек чиренә бирешә күрмәгез. Үзегез белән горурланмагыз.

15. Аллаһыдан гыйлем сорап, һәрдаим дога кылыгыз.

Шулай ук кыш айларында без калган уразаларыбызны каза кылырга, өстәмә уразалар тотарга тырышыйк. Бигрәк тә дүшәмбе, пәнҗешәмбе көн уразаларына игътибар итәргә кирәк. Гайшә анабыз радыяллаһу ганһә һәм хәзрәти Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи

вә сәлләмнең мондый сүзләрен риваять иткәннәр: «Гамәлләр [хисабы] ике көндә: дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә [фәрештәләр тарафыннан] күрсәтелә, ә мин гамәлләремнең ураза кылган вакытта күрсәтелүен телим»[1].

Киләсе мөһим гыйбадәт ул — нәфел намазлар. Һичшиксез, кышның озын төннәрен намазлар белән бизәү, бигрәк тә тәһәҗҗүд намазларын укып үткәрү отышлы булыр. «Тәһәҗҗүд намазы» дип төнлә йокыдан уянып, өстәмә намаз кылуга әйтәләр. Бу намаз ике рәкәгатьтән алып, унике рәкәгатькә кадәр укыла ала.

«Әл-Исра» сүрәсенең 79 нчы аятендә болай диелә:

وَمِنَ اللَّيْلِ فَتَهَجَّدْ بِهِ نَافِلَةً لَّكَ عَسَىٰ أَن يَبْعَثَكَ رَبُّكَ مَقَامًا مَّحْمُودًا ﴿٧٩﴾

**«Төннең бер өлешен исә синең өчен генә** [биш вакыт намазга] **өстәлгән** [фарыз] **буларак, уяу килеш уздыр** [һәм бу вакытта Коръән укып, тәһәҗҗүд намазы укы]**. Раббыңның сине** [Кыямәт көнендә терелтеп] **мактаулы урынга урнаштыруы каттый билгеләнде».**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:79

Тәһәҗҗүд намазы Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә бу аять белән әмер ителгән. Шул ук аятьтә Аллаһы Тәгалә Илчесен югары дәрәҗәгә күтәрәчәген тәһәҗҗүд намазын әмер иткәннән соң белдергән. Бу югары дәрәҗә белән тәһәҗҗүд намазы арасында бер бәйләнеш барлыгын күрсәтә. Әгәр шулай булса, тәһәҗҗүд намазының әһәмияте зур икәнлеге ачыклана.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең төнлә тәһәҗҗүд намазын укуын белгәч, сәхабәләр дә аның кебек төнлә намаз укый башлаганнар. Бу намазны, Пәйгамбәребездән башлап, аңа инанган кешеләр бүгенгә кадәр кылып килгәннәр. Һәм бу намаз Кыямәт көненә кадәр кылыначактыр, чөнки

[1] Имам әт-Тирмизи, № 747; имам Ибне Мәҗә, № 1740; имам Әхмәд, № 8343.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм мөэминнәргә: «Төнге намазны дәвам итегез», — дип боерган.

Димәк, газиз дин кардәшләрем, кыш айларында без гыйбадәтләрнең барысына да игътибарыбызны арттырырга тиешбез. Кыш — мөэминнең языдыр. Һәм язларын бар табигать, бар тереклек ничек уянып, җанланып китсә, мөселманнар да бу кыш айларында тормышын гамәл-гыйбадәт белән җанландырырга тиешле. Чөнки бу ел фасылында аларны үтәргә безгә җиңеллек бирелеп, тагын да зуррак мөмкинлекләр ачыла.

Әлбәттә, әлеге гыйбадәтләрне үтәгәндә дә, кешеләргә ярдәм иткәндә дә, садака биргәндә дә — нинди генә изгелек булмасын, гамәлебездән чын файда, әҗер аласыбыз килсә, кешеләрдән бернәрсә дә өмет итмичә, Аллаһыдан гына савап теләп, гамәл кылырга кирәк, нәкъ Коръәндә әйтелгәнчә:

وَيُطْعِمُونَ الطَّعَامَ عَلَىٰ حُبِّهِ مِسْكِينًا وَيَتِيمًا وَأَسِيرًا ﴿٨﴾ إِنَّمَا نُطْعِمُكُمْ لِوَجْهِ اللَّهِ لَا نُرِيدُ مِنكُمْ جَزَاءً وَلَا شُكُورًا ﴿٩﴾ إِنَّا نَخَافُ مِن رَّبِّنَا يَوْمًا عَبُوسًا قَمْطَرِيرًا ﴿١٠﴾ فَوَقَاهُمُ اللَّهُ شَرَّ ذَٰلِكَ الْيَوْمِ وَلَقَّاهُمْ نَضْرَةً وَسُرُورًا ﴿١١﴾

**«**[Кытлык аркасында ашауга ихтыяҗлары булуга һәм] **Аны яратуларына карамастан, мескенне, ятимне һәм әсирне ашаталар.** [Һәм әйтәләр] **«Без сезне Аллаһының Үзе өчен генә ашатабыз. Без сездән бер әҗер дә, бер рәхмәт тә көтмибез. Без бит читен һәм бәлале бер көндә Раббыбыздан куркабыз». Аллаһы аларны ул көннең явызлыгыннан саклар һәм аларга балку һәм** [күңелләренә] **шатлык бирер».**

«Әл-Инсан / Кеше», 76:8–11

Кардәшләрем, менә бу аять турында уйланыйк, фикерлик. Нинди генә гамәл булмасын — гади бер эшме яки олуг изгелекме — һәрвакыт үзебезгә

ошбу сорауны бирик: «Кем өчен эшлим, кешеләр өченме яки Аллаһы ризалыгын алыйм дипме?»

Үзебезгә хисап кылып, уй-фикерләребезне тәртипкә салып, ниятләребезне төзәтеп, ахирәттә кылган гамәлләребезнең әҗерләрен күреп, Аллаһының рәхмәтенә ирешеп, Үзенең җәннәтләренә керергә насыйп әйләсә иде, әмин!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә Рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Габдрахман хәзрәт Хәбибуллин,*
*Мамадыш мәдрәсәсе директоры*

*13 нче декабрь вәгазе,*

*җөмәдәл-ахыр аеның 12 нче көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Өлешеңә тигән көмешең…

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Аллаһы Тәгаләгә барча мактау һәм хәмде-сәналәребез булсын, сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның әһле бәйтенә, сәхабәләргә, табигыйннәргә сәламнәребез һәм салават-шәрифләребез ирешсен.

Аллаһы Тәгалә безне, ягъни адәм балаларын, яратты һәм тикмәгә генә яратмады, ә Үзенең тугры коллары булсын өчен бар кылды. Коръәни Кәримнең «Әз-Зарият» сүрәсендә галәмнәрнең Раббысы болай ди:

وَمَا خَلَقْتُ الْجِنَّ وَالْإِنسَ إِلَّا لِيَعْبُدُونِ ﴿٥٦﴾

**«Мин җеннәрне һәм кешеләрне Миңа гыйбадәт кылсыннар дип яраттым».**

«Әз-Зарият / Таратучылар», 51:56

Димәк, шушы аяте кәримәдән без Раббыбыз безне бу дөньяга ни өчен бар кылганын беләалабыз. Һәр кешенең бу дөньядагы төп максаты — Аллаһы Тәгаләгә колчылык күрсәтү. Раббыбыз Үзенең сөекле Расүле Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә өйрәткән кебек гамәл-гыйбадәттә тормыш алып бару, Раббыбыз кушканнарны үтәп, тыйганнарыннан тыелып, бердәм булып тормыш алып бару — мөселманнарның төп максаты. Шуның белән Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына ирешәбез.

Гамәл-гыйбадәтләр, Ислам диненең 5 нигезе Раббыбыз билгеләгән рәвештә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм күрсәтеп калдырганча кылыныр, ә тормыш алып бару турында уйлансак? Анысы ничек булырга тиеш? Кеше кайдан үз ризыгын табарга тиеш? Ничек көн күрергә? Ничек кәсеп кылырга? Гаиләсе булса, аны ничек тәэмин итәргә? Әлбәттә, мондый сораулар һәрбер акыллы кешенең башында туа. Эш һәм кәсеп, мәгыйшәт, ягъни тормыш алып бару, ничегрәк булырга тиеш? Бу сорауларга да динебез бик тә аңлаешлы һәм матур җаваплар кайтарачак.

Беренче булып эш, кәсеп турында уйланыйк. Аллаһы Тәгалә кешегә тормыш алып барганда үз ризыгын үзенә табарга кирәклеген белдерде, аның өчен адәм баласына эш дигән төшенчәне тиешле кылды. Һәрбер кеше эшләп, үзенең тормышын алып барырлык дәрәҗәдә кәсеп кылырга, үзен, гаиләсен тәэмин итәргә тиеш. Үз тырышлыгың белән кәсеп кылу — барлык пәйгамбәрләрнең сөннәте, алар күрсәтеп калдырган юл ул. Адәм галәйһиссәламнән алып, пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә хәтле җир йөзенә килеп киткән барлык пәйгамбәрләр дә пәйгамбәрлек вазифасыннан тыш бер һөнәр ияләре дә булганнар. Ә инде пәйгамбәрләр — үз өммәтләренә һәм гомум халык өчен дә иң хәерле үрнәк булдылар. Шул үрнәкләргә иярү, безнең очракта бигрәк тә Расүли Әкрам салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә иярү, аны үзебезгә үрнәк итеп алу, аңа охшарга тырышу — ул да булса Аллаһы Раббыбызның ризалыгына илтә торган юл.

Атабыз Адәм галәйһиссәламне Аллаһы Тәгалә Җәбраил фәрештә аша игенчелеккә өйрәтте; Идрис галәйһиссәлам беренчеләрдән булып кием текте, дәресләр бирде; Нух галәйһиссәлам балта остасы булды; Ибраһим, Муса, Давыд һәм Сөләйман галәйһимуссәламнәр дә бер һөнәр иясе булып, һәммәсе дә үз кәсебе белән тормыш алып барды. Һәм калган пәйгамбәрләргә карасак, шулай ук аларның төрле һөнәр иясе булганын күрә алабыз. Расүли Әкрам салләллаһу галәйһи вә сәлләм алардан аерылмады, ул да хәләл кәсеп, үз тырышлыгы белән тормыш алып барды.

Шулай ук Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Хәләл ризык эстәү һәр мөселман өчен вәҗиб», — дип әйткән. Бу мәсьәләдә Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә безгә шулай итеп мөрәҗәгать итә:

وَكُلُوا مِمَّا رَزَقَكُمُ اللَّهُ حَلَالًا طَيِّبًا ۚ وَاتَّقُوا اللَّهَ الَّذِي أَنتُم بِهِ مُؤْمِنُونَ ﴿٨٨﴾

**«Аллаһының сезне ризыкландырган нәрсәләреннән хәләл һәм хуш булганын ашагыз һәм Аллаһыдан куркыгыз, сез бит — Аңа иман китерүчеләр».**

«Әл-Маидә / Табын», 5:88

Ягъни мөселманның бер эше, кәсебе булудан тыш, бу кәсеп әле хәләл ризык та китерергә тиеш. Бу Аллаһы Тәгаләнең әмере һәм Аның Расүленең юлы, Сөннәте.

Хәләл ризык мөселманның тормышына, гыйбадәтенә һәм гаиләсенә дә тәэсир итә. Харам ризык нәрсәгә китерергә мөмкин? Хәләл ризыктан аерылган кешенең тормышы да, хәләлдән аерылып, гөнаһларга юнәлергә мөмкин, ул гамәл-гыйбадәтенең тәмен югалтып, аннан аерылырга мөмкин, гаиләсенә һәм балаларына шулай ук начар яктан тәэсир итүе мөмкин. Атабыз Адәм галәйһиссәлам тыелган җимешне татып караган өчен, җәннәттән куылды, озак еллар михнәт чикте, улы Кабил икенче улы Һабилне үтерде.

Шуңа күрә дә без, мөэмин-мөселманнар, ризыгыбызның хәләл булуын кайгыртырга тиешбез. Ризыгыбызның өстәлгә кайдан килгәнен, кайсы юллар белән килгәнен белергә тиешбез. Эшебез, кәсебебез нинди икәнен чамаларга тиешбез, ягъни хәләл ризыктан әүвәл әле хәләл кәсеп кылырга да тиешбез. Анысы ничек була соң? Аллаһы Тәгалә биргән мөмкинлекләрне кулланып тормыш алып бару, ләкин шул ук вакытта кеше хакына кермичә, беркемне дә рәнҗетмичә хезмәт кую.

Мәсәлән, эшең ялланып эшли торган булса, куелган максатларга ирешер өчен, тырыш, үзеңне жәлләмә һәм шул ук вакытта Аллаһы Тәгалә тыйганга керешмә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм безгә бу турыда шулай дип әйтеп калдырган: «Аллаһы Тәгалә сезнең гамәлләрегезне җиренә җиткереп эшләвегезне сөя». Шуңа күрә дә эшебезне җиренә җиткереп эшләргә тырышу ул да булса — Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Сөннәте.

Үзең эш бирә алырлык дәрәҗәдә икәнсең, бизнесмен, эшмәкәр булсаң, ул вакытта да өстеңдә олы җаваплылык барлыгын онытма. Дөрес итеп эшне аңлат, эшли алырлык максатлар куй һәм тиешле хезмәт хакы куеп, вакытында түләргә тырыш. Бу хакта Расүли Әкрам салләллаһу галәйһи вә сәлләм шулай дигән: «Яллап эшләткән кешегә хакын (акчасын) аның тәнендәге тире кипкәнче үк бирегез». Ягъни килешенгән хезмәт хакын килешенгән вакытта бир. Димәк, бу сүзләрдән нәрсә аңлап була: нинди генә эштә эшләсәң дә, нинди генә һөнәр иясе булсаң да, эшеңне җиренә җиткереп эшлә, кемнедер эшкә яллагансың икән, килешү төзегәнсең икән, килешүеңне сакла, сүзеңдә тор.

Тагын бер мәсьәләне дә истә тотарга кирәк, ул да булса — ризалык. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә безгә мөрәҗәгать итеп шулай ди:

أَهُمْ يَقْسِمُونَ رَحْمَتَ رَبِّكَ ۚ نَحْنُ قَسَمْنَا بَيْنَهُم مَّعِيشَتَهُمْ فِي الْحَيَاةِ
الدُّنْيَا ۚ وَرَفَعْنَا بَعْضَهُمْ فَوْقَ بَعْضٍ دَرَجَاتٍ لِّيَتَّخِذَ بَعْضُهُم بَعْضًا سُخْرِيًّا ۗ
وَرَحْمَتُ رَبِّكَ خَيْرٌ مِّمَّا يَجْمَعُونَ ﴿٣٢﴾

**«Раббыңның рәхмәтен әллә алар бүләләрме? Дөнья тормышында ризыкларын араларында Без бүлгәләдек һәм берәүләре икенчеләрен хезмәтче итеп алсыннар дип, Без аларның кайберләрен** [байлык ягыннан] **кайберләреннән дәрәҗәләрдә**

**күтәрдек. Раббыңның** [пәйгамбәрлек, һидаять, иман һәм җәннәт кебек] **рәхмәте исә аларның җыйган нәрсәләреннән яхшырак».**

«Әз-Зүхруф / Зиннәтләнү», 43:32

Ягъни дәрәҗә, эш, ризык кебек төшенчәләрне Аллаһы Тәгалә Үзе безгә билгеләп куя. Мөэмин-мөселман бу вакытта нишләргә тиеш? Аллаһы Тәгалә биргән эшкә, дәрәҗәгә, ризыкка, тормышка риза булырга һәм шөкрана кылырга. Кайвакытта без онытылып китеп, кеше акчасына, малына, эшенә, дәрәҗәсенә кызыгабыз, күршенеке безгә гел яхшырак булып күренә, ләкин Аллаһы Тәгалә безгә канәгать булырга куша, шөкрана кылып тормыш алып барырга киңәш итә.

Әйткән сүзләрне яхшырак аңлар өчен, Гайсә галәйһиссәлам белән булган бер вакыйганы искә алыйк. Бервакыт Гайсә галәйһиссәлам бер бай кеше янына килә. Шуннан соң аны бер фәкыйрь кеше янына алып бара да, шулай ди: «Менә бу фәкыйрь кеше — синең дин кардәшең. Аллаһы Тәгалә сине аңа караганда баерак кылган, шуңа күрә дә син Аллаһы Тәгаләгә шөкрана кыл, разый бул».

Шуннан соң Гайсә галәйһиссәлам бу фәкыйрь кешене бер авыру кеше янына алып бара да, аңа шулай дип мөрәҗәгать итә: «Син фәкыйрь, ләкин авыру түгел. Фәкыйрь дә, авыру да булсаң, ни булыр иде? Аллаһы Тәгаләгә шөкрана кыл, разый бул».

Аннан соң Гайсә галәйһиссәлам бу авыру кешене бер имансыз кеше янына алып бара да, шулай ди: «Бу кешегә кара! Фәкыйрь дә, авыру да һәм шуның өстәвенә имансыз да булсаң, ни булыр иде? Аллаһы Тәгаләгә шөкрана кыл, разый бул».

Шуңа күрә дә без, Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын табарга телибез икән, Ул биргәнгә риза булырга тиеш. Эш булсынмы, дәрәҗә булсынмы, мал булсынмы, барысына да риза булып, шөкрана кылырга, Аллаһы Тәгалә биргән мөмкинлектән кулланырга, күбрәк изгелек кылып, яманнан ерак торырга тиеш булабыз. Шул вакытта гына ризыгыбыз да, кәсеп тә хәләл булыр, дип өметләнәбез.

Бу сүзләрне йомгаклап, Расүли Әкрам салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең шундый сүзләрен искә төшерәсе килә: «Берегезгә Аллаһы Тәгалә бирәр төрле сәбәп белән ризык биреп, килгәнендә зарарлы үзгәреш булмый торып, шул сәбәпне ташламасын». Бу сүзләр белән Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм безгә нәрсәне аңлата: Аллаһы Тәгалә биргән эш белән тормыш алып барырлык мөмкинлек булган чакта, канәгать булырга кирәк, буш вәгъдәләргә, шөбһәле эшкә алданып, хәләл кәсепне калдырмаска кирәк.

Аллаһы Тәгалә барчабызга да хәерле тормышлар бирсен, хәләл кәсеп белән тормыш алып барып, Үзенең ризалыгына ирешергә насыйп итсен!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә Рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Илназ хәзрәт Габдуллин,*

*Казанның «Болгар» мәчетенең икенче имамы*

*20 нче декабрь вәгазе,*

*җөмәдәл-ахыр аеның 19 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Сәламәтлегеңне сакла

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Җомга көннәребез мөбарәк булсын, Аллаһы Тәгалә барчабызга иминлек-тынычлык бирсен! Ошбу җомга вәгазебез белән вәгазьләнеп, үземә дә, сезгә дә файда вә нәсыйхәт алырга насыйп булсын, иншәАллаһ.

Газиз дин кардәшләрем, бүгенге көндә сәламәтлек мәсьәләсе бик әһәмиятле мәсьәләләрдән санала. Аллаһының рәхмәте, сәламәтлек динебез Исламда бик кайгыртыла. Хәтта сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сәламәтлек турында бик күп хәдисләре китерелә, Аллаһы Тәгалә тарафыннан күп аятьләр иңдерелгән.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә әйтә: «Адәм баласының күбесе Аллаһы Тәгаләдән бирелгән ике нигъмәткә игътибар бирми, кыйммәтен аңламый, алдана», — ди. Шушы ике нигъмәтнең берсе ул — сәламәтлек, ә икенчесе — эш, хезмәт, дип килә хәдистә. Икенче бер хәдис-шәрифтә нәкъ шушындый ук сүзләр китерелә, әмма нигъмәтләрнең берсе — сәламәтлек, адәм баласы сәламәтлегенә игътибар бирми, диелә, ә икенче нигъмәт ул — вакыт, диелә.

Ягъни, дин кардәшләрем, бүгенге көндә, игътибар итсәк, сәламәтлеккә без бик саксыз карыйбыз, тиешле игътибар бирмибез, авырып киткәч кенә, авыру килсә генә, без үзебезнең сәламәтлегебезне кайгырта башлыйбыз, табибларга йөреп карыйбыз, анысын эшләп карыйбыз, монысын эшләп карыйбыз... Ләкин, газиз дин кардәшләрем, шунда гына сәламәтлекнең кадерен

аңлыйбыз. Кайвакыт, сәламәтлегебезнең кыйммәтен тешебез сызлый башлагач аңлыйбыз, кайвакыт — башыбыз авырта башласа яки инде сузып йөреп, табибларга күренмичә йөреп, берәр хастага эләксәк, шушы мәсьәләне аңлый башлыйбыз. Әгәр искә алган шушы хәдискә игътибар итсәк, икенче мөһим мәсьәлә — Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм вакытыбызга да игътибарлы булырга кушты. Вакытыгызны бушка уздырмагыз, ул — Аллаһы Тәгаләдән бирелгән нигъмәт бит, ди. Шуңа күрә дә вакытка да игътибарлырак булсак иде. Вакытыбызны, тормышыбызны кайчак гел кирәк булмаган эшләр белән, хезмәтләр белән, бер бәһасез булган әйберләр белән үткәрәбез бит.

Инде динебездә сәламәтлеккә игътибар бирелү нәрсәдән күренә соң? Хәтта бер вак кына мәсьәләдә дә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәхабәләренә үрнәк күрсәткән иде, бу — хөрмә ашаганда. Мөхәммәд пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бармаклары белән хөрмәне алып каба иде дә, ләкин аның төшен кире бармаклары белән тотмый, учына төкерми, ә ике бармак арасына куя иде. Ягъни кулын йодрык итеп тотып, төшне шулай кулның тышкы ягына, ике бармак арасына куя иде. Шулай ул бармак очлары чиста булып калсын, селәгәйгә пычранмасын өчен эшли иде. Бу да сәламәтлеккә кагыла торган мәсьәлә. Ягъни, берничә кеше бер тәлинкәдән хөрмә (яки башка бер җиләк-җимеш) ашаган вакытта, бүтән кеше, беренчедән, җирәнмәсен, икенчедән, чиста бармаклар белән чиста хөрмә җимешен алсын, дип, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам шундый үрнәк күрсәткән безгә.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Сөннәтендә сәламәтлеккә файда китерә торган төрле-төрле җимешләр, шөгыльләр дә бар иде. Бу шул ук тәһарәт мәсьәләсе булсын, шул ук госел мәсьәләсе булсын, хәтта ураза мәсьәләсе булсын — болар барысы да безнең сәламәтлегебезне ныгытуга бер сәбәп булып тора, дин кардәшләрем.

Бүгенге көндә күп кенә кеше, хәтта 30–40 яшькә җиткән яшьләр дә, зарланабыз, авырыйбыз, хасталанабыз, дибез. Бу кайдан килеп чыга? Яшьлектән

сәламәтлеккә игътибар бирмәүдән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең шундый матур хәдис-шәрифен китерәсем килә. Ул болай дип әйтә: «Биш төрле әйбер килгәнче, биш төрле әйбернең кадерен белегез сез. Беренчесе — картлык килгәнче, яшьлегеңнең кадерен бел. Икенчесе — эш, шөгыль килеп чыкканчы, буш вакытыңның кадерен бел. Өченчесе — ярлылык килгәнче, бай булуыңның кадерен бел. Дүртенчесе — чир килгәнче, сәламәтлегеңнең кадерен бел. Һәм бишенчесе — үлемең килгәнче, яшәвеңнең кадерен бел». Бу хәдистән күренгәнчә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм безгә аңлатты: сәламәт булганда рәхәт, күңелле, без гап-гади мәсьәләләргә игътибар да бирмибез. Сәламәт булганда тәһарәт алуы да, мәчеткә намазга барып кайтуы да шуның кадәр җиңел, күңелле. Ләкин чир, хаста килсә, хәтта гади генә тәһарәт алуы да бик авыр булырга мөмкин.

Башка бер хәдистә сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай ди: «Ий адәм балалары! Хасталарыгызны дәвалагыз, Аллаһы Тәгалә авыруны яратты исә, аның шифасын да яратты. Мәгәр бер генә авыруга дәва юктыр, ул да булса — картлыктыр». Димәк, авырган кешегә дәваланмый ятарга да ярамый. Без төрле-төрле сәбәпләр, төрле рөхсәт ителгән юллар белән үзебезгә килгән хастадан дәвалану, сәламәтләнү юлларын эзләргә тиешбез. Сәламәт булырга омтылырга тиешбез. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер авыру бар икән, димәк, аның шифасы да бар, шуны эзләгез, дәваланыгыз, дип җиткерде бит. Шундый кешеләрне дә очратырга мөмкин: дәваланмыйча, чир өстенә чир эзләп йөриләр.

Бүген, күреп торабыз, кайбер кешеләр, бигрәк тә яшьләр, баһадир кебек егетләребез, халык әйткәндәй «типсә, тимер өзәрдәй» егет-кызларыбыз үзләренең сәламәтлеген юкка чыгаралар, төрле-төрле харам юллар белән: харам ризыклар, харам эчемлекләр, харам матдәләр белән Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән шушы сәламәтлекләрен югалталар. Гади генә бер мисал. Бер өлкән яшьтәге бер абзый белән аралашып торырга туры килде. Ул борчылып килгән: «Хәзрәт, минә кызым сохранениеда ята (ягъни бәби көткән

кызына бала төшү куркынычы янаган һәм дә инде ул табиблар күзәтүендә ята икән), дога кылып булмасмы икән, берәр догалар белән ярдәм итә алмассызмы?» — дип мөрәҗәгать иткән иде. Һәм дә шул абый сөйләде: «Менә, хәзрәт, балам яшь вакытыннан кендеген күрсәтеп йөрде», — ди. «Кендек күрсәтеп, эссе вакытта да, салкын көннәрдә дә йөрде, ул вакытта шул бер мода иде инде ул. Менә хәзер сохранениеда, ул гына да түгел, әле бөерләре дә эшләми башларга мөмкин, отказ бирүе куркынычы бар», — дип сөйләде бу кеше. Менә бу абзый шушы ике күренешне үзенчә бәйләгән: шулай йөргәнгә күрә, бүген кызым сохранениеда ята да инде, дип уйлаган. Газиз дин кардәшләрем, әлбәттә, саклану, дөрес киенү ул — бик мөһим мәсьәлә. Балаларыбызга моны кечкенәдән өйрәтергә кирәк. Әгәр карасак, хәтта элек-электән килгән татар халкының киеменә дә, татар хатын-кызларының күкрәкчә дигән әйбере, башка төрле кием өлешләре булган. Бу да бит үзенчә гаурәтне каплау да, сәламәтлек өчен дә кирәкле әйбер булган.

Аллаһы Тәгалә барчаларыбызга сәламәтлек-саулык бирсә иде. Бар булганына шөкер итеп яшәргә насыйп булсын. Раббыбыз биргән сәламәтлекне дөрес юлда кулланып, изгелекләр кылып яшәргә насыйп булса иде!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә Рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Нурислам хәзрәт Газизов,*

*Мамадыш шәһәренең Әхмәт Ясәви мәчете имам-хатыйбы*

*27 нче декабрь вәгазе,*

*җөмәдәл-ахыр аеның 26 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Иң хәерле көн

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Аллаһы Тәгалә Үзенең кайбер мәхлукларының берләрен икенчеләреннән өстен кылды. Кешеләрдән — пәйгамбәрләрне, галимнәрне, урыннардан — мәчетләрне, Мәккә, Мәдинә җирләрен, вакытлардан — Рамазан аен, Кадер кичәсен, Гарәфә көнен һәм атна эчендә — җомга көнен.

Сүзебез шушы җомга көне хакында булыр. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Кояш чыккан иң хәерле көн ул — җомга көне. Бу көндә Адәм бар кылынды, бу көндә ул җәннәткә кертелде, бу көндә ул җәннәттән чыгарылды, һәм Кыямәт көне дә җомга көнендә булачак». Шулай ук җомга көнендә яки төнендә үлгән мөселман кабер газабыннан имин булыр, диде Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм.

Аллаһы Тәгалә безгә, мөселманнарга, җомга көнен өстенлекләргә ия булуыбыз өчен һәм бер бәйрәм буларак бирде. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу хакта: «Аллаһы бу көнне мөселманнарга бәйрәм итеп бирде. Әгәр дә берәү җомга намазына килә икән, госел коенып килсен», — диде.

Һәрбер дин әһелләренең үз көннәре бар: яһүдиләрнеке шимбә булса, насараларныкы (христианнарныкы) — якшәмбе көне. Әмма Аллаһы Раббыбыз безгә җомга көнен бирде, һәм бу көнгә безне күндерде. Пәйгабәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бер хәдисендә әйтелә: «Без ахыргы өммәт, әмма Кыямәт көнендә без беренче булачакбыз, гәрчә алар (яһүдиләр) Китапны безгә кадәр алсалар да. Аллаһы аларга бу көнне биргән иде, әмма

алар карыштылар, ә безне Аллаһы бу көнгә күндерде. Башкаларның көннәре бездән соң килә: яһүдиләрнеке — иртәгә, ә насараларныкы — берсекөнгә».

Аллаһы Тәгалә яһүдиләргә җомга көнен аерып биргән була, әмма алар каршы килеп, шимбә көнен теләгәннәр. Сәбәбе шулай аңлатыла: Аллаһы Тәгалә җирне алты көндә бар кылды, ә җомга көн — атнаның алтынчы көне, ягъни Аллаһының әле җирне бар кылган көненнән. Ә шимбә көн — җиденче көн, Аллаһы эшен тәмам кылган көне. Шуңа яһүдиләр, без дә эшләребезне калдырып, шимбә көнне ял итәргә телибез, дигәннәр. Сорагач, Аллаһы Тәгалә аларга шимбә көнен аерып биргән, әмма карышканнары өчен, шимбә көнне дөнья эшләре белән шөгыльләнүне тыйган. Бу көндә яһүдиләргә транспортта йөрү, лифтта менү, ут яндыру, ризык пешерү һәм башка эшләр белән шөгыльләнү тыела. Беренче насаралар әүвәл шимбәне үтәсәләр дә, соңрак бу көнне калдырып, үзләренә якшәмбе көнне сайлаганнар.

Без җомга көнен бәйрәм көне дип әйтсәк тә, бу ял көне түгел, ә өстенлекләргә ия була торган көн, ул — хезмәт көне. Аллаһы Раббыбыз Коръәндә болай ди:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا إِذَا نُودِيَ لِلصَّلَاةِ مِن يَوْمِ الْجُمُعَةِ فَاسْعَوْا إِلَىٰ ذِكْرِ اللَّهِ وَذَرُوا الْبَيْعَ ۚ ذَٰلِكُمْ خَيْرٌ لَّكُمْ إِن كُنتُمْ تَعْلَمُونَ ﴿٩﴾

> **«Ий иман китерүчеләр! Җомга көнне намаз өчен** [азан әйтелеп] **чакырылгач, Аллаһыны искә алырга ашыгыгыз һәм сәүдәне ташлагыз. Бу —** [сәүдәнең вакытлы файдасыннан] **сезнең өчен яхшырак. Әгәр дә белсәгез иде** [мәңгелек алыш-бирешне сайлар идегез]**».**
>
> «Җомга», 62:9

Шушы аятьтән без кешеләрнең җомга намазына кадәр эштә булганнарын аңлыйбыз. Аллаһы Тәгалә аларга эшләрен калдырып, җомга намазына ашыгырга кушты. Ә инде намаз беткәч, Раббыбыз аларны яңадан эшләренә кайтырга өнде.

Җомга көн — ул өстенлекләргә ия көн, һәм бу көннең өстенлеге мөселманның кыяфәтендә, үз-үзен тотышында күренергә тиеш, дип чакырды безне Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм. Ул бу хакта: «Кем җомга көнне госел коенып, матур киемнәрен киеп, исле май сөртеп мәчеткә килсә, һәм анда кешеләрне төрткәләмичә (берәр урынга килеп утырса), һәм имамның сөйләгән хотбәсен игътибар белән тыңласа, һәм имам артына басып намаз укыса — аның ике җомга арасындагы гөнаһлары ярлыканыр», — диде.

Җомга намазы укылыр алдыннан, иң элек имам минбәргә менеп, халыкка хотбә һәм вәгазь сөйли. Һәр кешегә имамның хотбәсен тыңлап утыру тиешле. Кем хотбә барышында берәр сүз әйтсә яки берәр эш эшләсә (мәсәлән, телефон белән яки киеме, бармаклары белән уйнап утырса), ул кеше җомгасын югалтыр, диде Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм. Шулай ук хотбә сөйләнгәндә Коръән уку, дога кылу, намаз уку кебек гыйбадәтләр дә тыеладыр. Мондый очракта кешеләр әҗер-саваплар белән түгел, ә буш килеш, бер савапка да ия булмыйча кайтып китәрләр.

Коръәни Кәримнең соңгы булып иңдерелгән аятьләрнең берсе җомга көнне иңде. Бу аять:

الْيَوْمَ أَكْمَلْتُ لَكُمْ دِينَكُمْ وَأَتْمَمْتُ عَلَيْكُمْ نِعْمَتِي وَرَضِيتُ لَكُمُ الْإِسْلَامَ دِينًا ۚ

> «**Бүген сезнең өчен динегезне камил иттем,** [Мәккәне алуны насыйп итү белән динегезне бөтен ялган диннәрдән өстен кылып] **сезгә нигъмәтемне тәмамладым һәм сезнең өчен, дин буларак, Исламнан канәгатьмен».**

«Әл-Маидә / Табын», 5:3

Тугры хәлифә Гомәр әл-Хаттаб радыяллаһу ганһе янына бер яһүди килеп: «Әгәр дә бу аять безнең Тәүратта иңгән булса, без бу көнне үзебезгә

бәйрәм итеп алыр идек», — дигәч, хәзрәти Гомәр аңа: «Мин бу аятьнең кайчан иңгәнен беләм. Ул җомга көнгә туры килгән Гарәфә көнендә иңде», — диде. Әлеге аять Исламның дин буларак инде формалашып беткәнен белдерә.

Җомга көнне Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм безгә кайбер эшләрне киңәш итте, шулардан:

— «Әл-Кәһф» сүрәсен уку. Хәдистә: «Кем җомга көнне «Әл-Кәһф» сүрәсен укыса, ике җомга арасында ул нур эчендә булыр», — диелә.

— Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салаватлар әйтү. Хәдистә: «Җомга көнне миңа күбрәк салаватлар әйтегез, чөнки сезнең әйткән салаватларыгыз миңа ирешәдер», — дип килә.

— Дога кылу. Хәдистә әйтелә: «Җомга көнендә бер вакыт бардыр, әгәр дога кылучы бу вакытка туры килсә, Аллаһы аңа сораганын бирер». Икенче бер хәдистә: «Җомга көнендә шундый бер вакыт бар, ул вакытка игътибар итегез. Ул икендедән алып, кояш баеган вакыт эчендәдер», — диелә.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисләрендә җәннәттәге җомга көне дә тасвирлана. Аларда хәбәр ителгәнчә, җомга көнне кешеләр җәннәтнең бер үзәнлегенә җыелачаклар. Пәйгамбәрләр — нурдан булган, дин өчен шәһит китүчеләр алтынан булган минбәрләргә утырачаклар. Кайберәүләр якут, энҗе, көмеш минбәрләргә утырачаклар, ә кайбер җәннәт әһелләре мисктән булган калкулыкларга урнашырлар. Халык җыелып беткәч, Аллаһы аларга мөрәҗәгать итәр: «Ни телисез, шуны сорагыз Миннән», — дияр. Алар: «Йә Раббыбыз, Синең бездән риза булуыңны сорыйбыз», — диярләр. Аллаһы Тәгалә: «Сезне Үземнең Йортыма кертүем инде Минем сездән риза булуымны белдерәдер. Ни телисез, шуны сорагыз», — дияр. Һәм җәннәт әһелләренең һәрберсе теләгәннәрен сорый башларлар. Шуннан соң Аллаһы аларга: «Мин сезгә тагы да арттырып бирергә телим», — дияр. Алар: «Йә Раббыбыз! Син безнең гөнаһларыбызны гафу кылдың, үлчәүдә изгелекләребезне авыр китердең һәм безне җәннәтеңә керттең, тагы нинди арттыру булырга мөмкин соң?» — дип гаҗәпләнеп сорарлар. Шуннан соң

Ул Үзенең пәрдәсен ачар, һәм җәннәт әһелләре, күктәге айны яки кояшны күргән кебек, Бөек Раббыларын күрерләр. Алар барлык җәннәт нигъмәтләрен онытып, күзләрен дә ала алмыйча, Аллаһының Үзенә карап торырлар. Бераздан Аллаһы янә капланыр, әмма капланса да, Аның нуры алар белән калыр. Бу җыен һәр җомга саен кабатланыр.

Шуннан соң шушы җомга көнне җәннәт әһелләре базарга китәрләр. Анда беркем дә сатмас һәм сатып алмас. Кешеләр ни теләсәләр, аларга анда шулар бирелер. Һәм аларга анда өстәп, моңарчы күзләре күрмәгән, колаклары ишетмәгән, күңелләренә дә килмәгән нигъмәтләр бирелер. Икенче төрле әйткәндә, һәр җомга саен аларга бер «сюрприз» булыр. Шуннан соң төнъяктан бер җил исәр, һәм аларга бу җил тию белән, аларның йөзләре, өс-кыяфәтләре тагы да күркәмләнер. Өйләренә кайткач, йорт әһелләре аларга: «Валлаһи, сез тагы да матураеп, күркәмләнеп кайткансыз», — диярләр. Алар да йорт әһелләренә: «Валлаһи, сез дә без булмаганда тагы да күркәмрәк, чибәррәк булгансыз», — диярләр. Бу базар да һәр җомга саен булыр.

Газиз дин кардәшләрем! Җомга көне — бөек көн, без бу көнне гади бер көн дип кенә санамасак иде. Менә бүген, шундый ыгы-зыгылы вакытта да без әлеге елның соңгы җомгасына җыелдык, әлхәмдүлилләһ. Инде шушы елыбызга һәрберебез үзенә бер хисап ясап, нәтиҗә чыгарып куйса иде. Без җомга намазларына йөрдекме, намазларыбызны җәмәгать белән кылырга тырыштыкмы, нинди гыйлем өйрәнеп, нинди изгелекләр эшләдек? Киләчәккә үзебезгә нинди планнар куярбыз? Кардәшләрем, алда безне ял көннәре көтә. Шушы мөмкинлекне дөрес файдалансак иде. Аллаһы насыйп итсә, киләсе җомгабыз да ял көненә туры килер. Әйдәгез, туганнарыбызны, якыннарыбызны, алар бәлки биш вакыт намаз укымаса да, ураза тотмаса да, киләсе җомгаларга чакырыйк. Алар мәчетләребезгә килергә оялмасын, читенсенмәсен. Бергә догалар кылып, вәгазьләр тыңлап кайтырбыз, дип, җайлап мәчет тәртипләрен дә аңлатып китегез. Театрларга, концертларга барырга акчасын, вакытын табалар, Аллаһы йортына килергә берни комачауламый. Үзебез дә, әлбәттә,

яллар дип, намазларыбызга килми калмыйк. Шушы кыска гына каникул, ял көннәрен дөрес үткәрик: җәмәгать намазларына килик, күбрәк Коръән укыйк, гаиләбез, туганнарыбыз белән араларыбызны ныгытыйк, сәламәтлегебез өчен дә файдалы итәргә тырышыйк.

Газиз дин кардәшләрем, Аллаһы Раббыбыз бездән разый булып, барчабызга җәннәттәге җомга җыеннарында катнашырга һәм базарларында йөрергә насыйп кылсын! Әмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә Рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Марат хәзрәт Сәйфетдинов,*
*Балтачның Үзәк мәчетенең имам-хатыйбы*

*3 нче гыйнвар вәгазе,*

*раҗәб аеның 3 нче көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Рәгаиб кичәсе. Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең гаилә әһелләре

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Галәмнәрне юктан бар кылып, безне тәрбия кылып, чиксез нигъмәтләрен яудырып торган Раббыбыз Аллаһы Тәгаләгә хәмед-сәналәребез, мактауларыбыз булса иде. Күңел түрләребездән чыккан салават һәм догаларабыз сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның гаиләсенә, сәхабәләренә барып ирешсә иде.

Аллаһы Тәгалә җомга көнебезне һәм барча көннәребезне бәрәкәтле, файдалы кылып, Аллаһы ризалыгы өчен кылынган гамәлләребезне кабул итеп, Үзенең рәхмәте белән гөнаһларыбызны гафу әйләсә иде.

Еллык календарьне карасак, кызыл төскә буялган «кызыл көннәрне» күрәбез. Ул — бәйрәмнәр һәм мөбарәк көннәр. Ләкин бәйрәм дисәк тә, Ислам күзлегеннән бәйрәм ул — ял итү булса да, әмма гыйбадәт кылу белән бәйле. Гает көннәрен без гает намазын уку белән башлыйбыз. Мәзһәбебез галимнәре гает кичәләрән гыйбадәттә үткәрүне хуплаганнар. Башка мөбарәк көннәр һәм төннәрнең бәрәкәте дә гыйбадәт кылуга, Аллаһыга табынып, Аңа якынаюга бәйле.

Шундый мөбарәк көннәрнең берсе — Рәгаиб кичәсе. «Рәгаиб» сүзе гарәп телендә «рагаба» фигылленнән ясалган. Аның мәгънәсе — «нәрсәнедер теләү». Рәгаиб кичәсе шәригать кылырга кызыктырган, өндәгән һәрбер

гамәл-гыйбадәтне үз эченә ала. Һәм бу көнне сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең ата-анасы өйләнгәннәр, дип искә алына.

Гарәпләрдә өйләнү, никах укыту элек-электән булган. Бу тарих китапларында да искә алына, шулай ук, мәсәлән, Гайшә анабыз радыяллаһу ганһә Ислам килгәнче гарәп җәмгыятендәге өйләнү юлларын искә ала һәм шулар арасында иң таралганын, Исламдагы никахка туры килгәнен аерып әйтә. Бу өйләнешү мәһәрне килешкәннән соң, егетнең шаһитләр каршында кызны әтисеннән (вәлиеннән) сорап һәм вәлинең хатын-кызны кияүгә бирүеннән гыйбарәт булган.

Шушында без динебездә никах уку тәртибенә тукталып китик. Мәзһәбебездә никахның төп нигезе (рөкене) булып «иҗәб вә кабул» санала. Иҗәб ул — беренче булып башлаган кешенең сүзләре. Егет башласа, бу сорау була, ә вәли башласа, тәкъдим итү була. Кабул ул — кабул итү, ягъни җавап бирү, раслау.

Фикһ китапларында әйтелә: егет (кияү димәк) кызның вәлиеннән (вәли ул — кызны кияүгә бирүче кеше: әтисе, абый-энеләре, улы, әти ягыннан бабасы, әтисенең ир туганнары): «Кызың фәләнне миңа кияүгә бирдеңме?» — дип сорый, ә вәли: «Кызымны сиңа кияүгә бирдем», — дип әйтә. Шушы сүзләргә кыз риза булса, һәм бу сүзләр кимендә ике шаһит каршында әйтелсә, никах барлыкка килә. Димәк, никахка җыелгач, ике як та инде барыбер риза дип, сорамыйча калырга ярамый, ул вакытта никах дөрес булмаячак.

Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең ата-анасы да — Габдуллаһ белән Әминә — шулай өйләнешкән. Сира китапларында шул искә алына: Габдуллаһны атасы Габделмотталиб Вәһеб Габдеманаф янына алып бара һәм аның кызы Әминәгә өйләндерә. Әминә ул вакытта Корәеш кабиләсендә иң дәрәҗәле һәм чиста нәселле хатын-кызлардан була. Әлбәттә, бу вакыйга мәһәрне килешкәннән соң, шаһитләр алдында уза.

Бу вакыйга Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм пәйгамбәр булганчы, хәтта ул туганчы булганга күрә, ул безнең өчен шәригать чыганагы була алмый. Ләкин без Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормыш юлын белергә тиешбез. Һәм аның ата-анасының өйләнүендә динебезгә туры килмәгән бер нәрсә дә юк. Аның ата-анасы хәләл никах кылып, шул хәләл никахта сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәлам туа.

Бу тарихи вакыйга безгә улларыбызны өйләндергәндә, кызларыбызны кияүгә биргәндә, аларның кем белән никахлашуын белеп, тикшереп, сайлап бирергә тиешлеген күрсәтә. Бездә исә күпчелек яшьләр үзләре танышып, үзләре йөрешеп, ата-анасына өйләнү ниятләре хакында аннары гына хәбәр бирәләр. Әле берничә ел «гражданский брак»та яшәп, ата-аналары, әби-бабайлары мәҗбүр иткәч кенә мәчеткә никах укытырга киләләр. Чисталык, гыйффәтлек юкка чыгып бара.

Һәм бу вакыйга никахлы тормышның әһәмиятен күрсәтә. Ислам биш нәрсәне саклар өчен килгән:

1. Дин — кешегә җәннәткә алып бара торган эшләрне кылырга куша, тәмугка алып бара торган эшләрне кылудан тыя.

2. Җан — хаксызга кешенең канын кою, аны үтерү тыела.

3. Мал — кешенең малын харам, тыелган юллар белән үзләштерү тыела.

4. Абруй — кешене сүгү, мыскыллау, гайбәтен сөйләү тыела.

5. Нәсел-нәсәп — динебездә, нәселләр буталмасын дип, бала үз атасына бәйле булсын дип, никах белән генә яшәү, якынлык кылу һәм бала табу таләп ителә. Никахсыз зина кылу тыелган, зур гөнаһ булып санала.

Никах укыганнан соң, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әтисе Габдуллаһ белән әнисе Әминә бергә озак тормыйлар. Габдуллаһ сәүдә кәрваны белән сәфәргә чыга һәм кире Мәккәгә кайтмый. Ясрибтә (хәзерге Мәдинә) вафат була, бердәнбер улын Мөхәммәдне күрми дә. Сира китапларында төрле риваятьләр искә алына. Кайбер галимнәр атасы улы туганчы

вафат була, дип әйтәләр, ә кайберләре туганнан соң вафат була, дип әйтәләр. Ничек кенә булмасын, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм ятим булып үсә, ата тәрбиясен алмый.

Һәм без монда күрәбез: гаиләне тәэмин итәм дип, ир акча эшләргә чыгып китә, хатыны өйдә кала. Чөнки ул вакытларда гаиләне тәэмин итүче ир-ат, ата иде. Динебез дә хатынын, балаларын тәэмин итүне ир кешегә йөкләгән. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

الرِّجَالُ قَوَّامُونَ عَلَى النِّسَاءِ بِمَا فَضَّلَ اللَّهُ بَعْضَهُمْ عَلَىٰ بَعْضٍ وَبِمَا أَنفَقُوا مِنْ أَمْوَالِهِمْ ۚ فَالصَّالِحَاتُ قَانِتَاتٌ حَافِظَاتٌ لِّلْغَيْبِ بِمَا حَفِظَ اللَّهُ ۚ

**«Аллаһының** [тирән акыл, оста җитәкчелек, көч, ныклык кебек сыйфатлар белән] **берәүләрне икенчеләрдән өстен кылганы өчен һәм малларыннан сарыф иткәннәре сәбәпле, ирләр** [гаилә эчендә әмер бирү һәм тыюлар мәсьәләсендә] **хатыннардан өстен торалар. Игелекле хатыннар —** [Аллаһы Тәгаләгә] **итагатьле** [һәм ир хакына тугры калган] **һәм гаибне** [ирнең милкен һәм серләрен] **Аллаһының** [да аларны] **саклавы сәбәпле, саклаганнар».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:34

Моңа икенче мисал итеп без Хәдичә радыяллаһу ганһәнең, сәүдә эшләрен алып барсын, кәрваны белән сәүдә сәфәренә чыксын өчен, махсус кешеләр, шулай ук Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне яллавын күрәбез. Хәдичә анабыз аны үзе кыла алмаган, чөнки ул вакытта хатын-кыз базарда сәүдә кылмаган.

Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең әнисе Әминә бинте Вәһеб баласын тапкач, аны сөт анасына, имезүчегә бирергә теләгән. Ул вакытта гарәпләрдә шундый гадәт кабул ителгән була: сабыйлар сәламәт булып, әдәби гарәп телен сеңдереп үссен өчен, аларны шәһәрдә калдырмаганнар, шәһәрдән читтә яшәүче кабиләләрдән сөт аналары табып, күпмедер вакытка шулар-

га тапшырып торганнар. Әмма кечкенә Мөхәммәд галәйһиссәлам атасыз булганга, ятим бала өчен түләүче булмас дип, бер имезүче хатын да аны алырга теләмәгән. Ләкин Аллаһы язган эш булмыйча калмый. Аны Хәлимә исемле хатын үзенә ала. Бүгенге көндә бу гадәт безгә сәер тоела, ләкин алар өчен, дистә гасырлар элек яшәгән кешеләр өчен, безнең бүгенге гадәтләребез сәер тоелырлар иде.

Хәлимә Әбү Зүвәйб кызы бәнү Сәгъд кабиләсеннән була. Аллаһының рәхмәте белән, башка балалар калмагач, буш кайтмыйм дип, Хәлимә Мөхәммәд галәйһиссәламне ала. Һәм һич үкенми, чөнки шул мизгелдән башлап, аның гаиләсенә бәрәкәт килә. Адәм баласы үзенә нәрсәнең файдалы, ә нәрсәнең зарарлы икәнен белми, фаразлый гына ала.

Коръәндә Аллаһы Тәгалә балаларны ике елга хәтле имезүне хуплый. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

وَالْوَالِدَاتُ يُرْضِعْنَ أَوْلَادَهُنَّ حَوْلَيْنِ كَامِلَيْنِ ۖ لِمَنْ أَرَادَ أَن يُتِمَّ الرَّضَاعَةَ ۚ

«[Бала] **Тудырган хатыннар балаларын тулы ике ел имезергә тиеш, әгәр алар** [аталар] **имезүне** [тулысынча] **тәмамларга теләсәләр».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:233

Хәлимәдә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм дүрт яше тулганчы тәрбияләнә. Хәлимәнең гаиләсе Пәйгамбәрне бик якын итеп, яратып, аның күбрәк калуын да теләр иде, ләкин фәрештәләр аның күкрәген ачып, йөрәген югач, Хәлимә балага зыян килгән дип куркып, баланы әнисенә кайтара.

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә алты яшь булганда, әнисе Әминә Ясриб шәһәренә (бүгенге көндә Мәдинә шәһәре) иренең каберенә бара һәм кайтканда Әл-Әбва дип аталган авылда вафат була. Һәм шунда җирләнә. Инде пәйгамбәр булгач, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Аллаһыдан рөхсәт сорап, әнисенең каберен зиярәт кылып кайта. Әнисе дә вафат булгач, аны тәрбияләү бабасы Габделмотталибка күчә.

Мөхәммәд галәйһиссәламгә сигез яшь тулгач, бабасы Габделмотталиб та вафат була, һәм ул әтисенең абыйсы булган Әбү Талиб тәрбиясенә күчә. Һәм Әбү Талиб пәйгамбәребез Мөхәммәдне гомере буе яклый. Әбү Талиб исән вакытта, Корәеш кабиләсе аны бик хөрмәт иткәнгә күрә, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә дә артык золым кыла алмыйлар. Тарих китапларыннан шулай ук Әбү Талибның хатыны Фатыйма бинте Әсәд радыяллаһу ганһәнең Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне үз баласыдай яратуы билгеле. Бу мөслимә кардәшебез — беренчеләрдән Ислам динен кабул итүче хатын-кыз. Әбү Талиб белән аларның үз 7 баласы була, барчасы да әниләре кебек үк Ислам динен кабул итә, шулар арасында мәшһүр Җәгъфәр әт-Таййәр һәм Гали радыяллаһу ганһүмә. Фатыйма бинте Әсәд радыяллаһу ганһә ятимлек ачысын аңлап, Мөхәммәд галәйһиссәламгә аерым игътибар биргән, ә Пәйгамбәребез аны якын итеп «икенче әнием» дип атаган.

Күрәбез, гаилә, туганнарның яратуы, якын итүе, ярдәм күрсәтүе һәр кешенең тормышында искиткеч зур урын алып тора. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең балачагындагы бу вакыйгалар безнең өчен зур дәрес булып тора. Әтисез калган баланы һәм яшь киленен беренче чиратта әти ягыннан дәү әти булган Габделмотталиб үз канаты астына ала. Уйланыйк, дин кардәшләрем, бүген күпме бала, әтиләре исән-сау була торып, ата тәрбиясен күрми, аның туганнарын белеп-аралашып үсми. Никах таркалган очракта да, ата-ана баланы туганнарыннан аерырга тиеш түгел. Габделмотталибтан соң Пәйгамбәребез галәйһиссәламне әтисенең абыйсы тәрбиягә ала, дидек. Аның да гаиләсе ишле булган, алар артык бай булмаганнар, әмма карагыз, бу гаиләдә 7 сәхабә һәм Расүлебез тәрбия, ярату, наз күреп үскән.

Әмма иң күркәм, бөек кешенең гаиләсендә дә Исламга каршы көрәшкән кеше булган. Бу — барчабызга билгеле Әбү Ләһәб. Коръәни Кәримдә аның турында аерым сүрә бар. Кеше ата-анасын да, балаларын да, туганнарын да сайламый, аларның барысын да Аллаһы Тәгалә

бирә. Туганнар арасында яхшылары да, яманнары да булырга мөмкин, бу Раббыбызның бер хикмәте.

Шул ук вакытта Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм янында аңа туган булмаса да, шулай ук әнисе кебек якын тәрбияче хатын-кыз булган. Бу Өмме Әйман буларак билгеле Бәракә бинте Сәгъләбә радыяллаһу ганһә. Бәракә кечкенә чагында коллыкка эләгеп, Габдуллаһ бине Габделмотталибның гаиләсендә ярдәмче кыз булып үсә. Соңрак Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм аны коллыктан азат итә. Ул Пәйгамбәребез галәйһиссәлам туган көннән башлап, вафатына кадәр аның янәшәсендә булган, гомерен аны тәрбияләүгә багышлаган, дия алабыз. Кайчандыр коллыкка эләккән бу бөек мөслимә хакында Аллаһының Илчесе галәйһиссәлам: «Бәракә — мине тудырган әниемнән соң әнием. Ул гаиләбезнең сөенече», — дип әйткән. Ә башка бер хәдисендә аны «җәннәт әһелләреннән булган хатын-кыз» дип тә атаган.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сирасыннан һәр күренештә, аның янәшәсендә булган кешеләрнең тормышларында фикерли белүчеләр өчен бик күп дәресләр бардыр. Газиз дин кардәшләрем, аларны үзебез өчен үрнәк итеп алырга, шуларга охшарга тырышыйк. Һәм мөбарәк Рәгаиб кичәсе безгә кабат никахның әһәмиятен, баланың шәхесен тәрбияләүдә гаиләнең урынын, туганлыкның нинди зур хәзинә булуын искәртә.

Аллаһы Раббыбыз ошбу вәгазьләрдән файда алып, үзебезне төзәтергә, гаилә әһелләребез, туганнарыбыз белән араларны ныгытырга насыйп итсен! Якыннарыбызга, мәрхүм туганнарыбызга, үзебездән соң киләчәк барлык буыннарга җәннәтләргә керергә әйләсен!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә Рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рәйхан хәзрәт Нәзметдинов,*

*Түбән Кама шәһәренең «Ак каен» мәчетенең имамы,*

*БИА докторанты*

# «Нәрсә? Кайда? Кайчан?»

# ИЮНЬ-СЕНТЯБРЬ

## «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә көндезге һәм кичке бүлекләрне тәмамлаучы 135 кеше диплом алды

Зөлхиҗҗә аеның 1 нче көнендә (7 июньдә) «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә көндезге һәм кичке бүлекләрдә белем алган чыгарылыш шәкертләренә диплом тапшыру тантанасы узды. Көндезге бүлекне тәмамлаган егетләргә – «Имам-хатыйб, ислам фәннәре һәм гарәп теле мөгаллиме. Гарәп теле тәрҗемәчесе», кызларга «Ислам фәннәре һәм гарәп теле мөгаллиме. Гарәп теле тәрҗемәчесе» квалификациясе бирелде. Быел «Мөхәммәдия»нең көндезге бүлеген 55 шәкерт тәмамлады. Кичке бүлектә исә урта дини һөнәри белем турындагы документны 80 кеше алды, аларга «Имам-хатыйб. Ислам нигезләре мөгаллиме» квалификациясе бирелде.

## Мөхтәсибәтләр Корбан гаете уңаеннан бәйрәм чаралары оештырды

Мөхтәсибәтләр Корбан гаете уңаеннан гомумшәһәр балалар һәм гаилә бәйрәмнәре оештырды. Быел алар Россиядә Гаилә елы һәм Татарстан мөфтияте тарафыннан игълан ителгән Гаилә һәм хәләл яшәү рәвеше елына йөз тотып уздырылды – балаларга аерым игътибар бирелде. Паркларда һәм мәчет яннарындагы бәйрәмнәрдә кызыклы мәдәни программа тәкъдим ителде, викториналар, эстафеталар, милли уеннар, спорт ярышлары үтте. Кунакларны кайнар пылау, коймак, тәм-том белән сыйладылар һәм чәй эчерттеләр.

## Әлмәтнең яңартылган Җәмигъ мәчетендә Татарстан Рәисе катнашында Корбан гаете узды

Зөлхиҗҗә аеның 10 нчы көнендә (16 июньдә) бөтен дөнья мөселманнары бөек бәйрәм – Корбан гаетен – билгеләп үтте. Бу уңайдан Татарстан Республикасының барлык мәчетләрендә иртәдән үк бәйрәм чаралары башланды. Татарстандагы төп бәйрәм тантанасы Әлмәтнең Ризаэтдин Фәхреддин исемендәге яңартылган Җәмигъ мәчетендә узды. Гаеткә килгән мөселманнар, бәйрәм вәгазен тыңлап, Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллинның беренче урынбасары Илфар хәзрәт Хәсәнов җитәкчелегендә намаз укыды. Ул бәйрәм вәгазен Исламда гаилә кыйммәтләренә багышлады: ир һәм хатынның бурычлары, вазифалары, бер-берсенә булган хаклары уңаеннан үгет-нәсыйхәтләр бирде. Әлмәт мәчетендәге гает намазын «ТНВ Татарстан» һәм «ТНВ Планета» телеканалы аша туры эфирда карарга мөмкин булды.

Мәчетне яңарту «Татнефть» ААҖ ярдәме белән башкарылды. Мәчет комплексының гомуми мәйданы – 4,9 мең м$^2$. Төзекләндерүдән соң намаз залы үзгәрешсез калды – ул 1200 кешегә исәпләнгән. Мәчетнең фасады заманча итеп ясалды, ул төнлә урамны яктыртып тора. Гөмбәзе 2 метр биеклектә эшләнгән. Мәчетнең тирә-ягы җәяүлеләр юлы һәм парк белән тоташкан.

## Нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фонды Корбан бәйрәме көннәрендә мохтаҗларга матди ярдәм күрсәтте

Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды Татарстанда Корбан бәйрәме көннәрендә, гадәттәгечә, мохтаҗлар өчен бик күп хәйрия башлангычларын тормышка ашырды. Аларга, дине һәм милләтенә карамастан, ярдәм күрсәтелды. Әлеге ярдәмне аз керемлеләр һәм күпбалалы гаиләләр, авырулар, балаларын ялгызы тәрбияләүче әниләр, өлкән яшьтәгеләр һәм социаль яктан якланмаган башка кешеләр алды.

Быел Корбан бәйрәменә ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды тарафыннан мохтаҗлар өчен 5 тоннадан артык корбан ите әзерләнде. Аның 2,5 тоннасы 700 дән артык аз керемле гаиләгә таратылды һәм Татарстандагы 6 социаль учреждениегә: «Мамы Казани» һәм «Победим диабет» хәйрия фондларына, Инвалид балалар ата-аналарының бөтенроссия оешмасына, Татарстандагы инвалид балалар ата-аналарының «Забота» төбәк иҗтимагый оешмасына, Яшел Үзәндәге психоневрология диспансерына, Анжела Вавилова фондының Казан хосписына җибәрелде. Калган яртысы, туңдырылып, ел дәвамында социаль проектларга тоту өчен әзерләп куелды.

Моннан тыш, «Зәкят» фонды Корбан бәйрәме хөрмәтенә 5 авыру балага һәм 3 мохтаҗ өлкән кешегә акчалата ярдәм күрсәтте. Шулай ук Корбан гаете көннәрендә 6 авыру бала һәм өлкәннәргә булышу өчен акча җыю дәвам итте.

## Азнакай мөхтәсибәтендә яңа мәчет ачылды

Зөлхиҗҗә аеның 11 нче көнендә (17 июньдә) Азнакай районының Ирекле авылында яңа мәчеткә ярымай урнаштырылды һәм ачылыш тантанасы булды. Рәсми тантанадан соң мәчеттә намаз укылды, ә аннары Корбан бәйрәме хөрмәтенә хәйрия мәҗлесе узды. Мәчетнең гомуми мәйданы – 85,1 $м^2$. Мәчет төзелеше 2017 елда башланган, ә манара 2023 елда күтәрелгән.

Бер катлы мәчеттә дини йолаларны үтәү өчен барлык шартлар тудырылган: ир-атлар өчен 50 кешелек намаз залы, имам бүлмәсе, уку сыйныфы бар (ул хатын-кызлар өчен намаз уку бүлмәсе буларак та кулланыла ала), котельная һәм тәһарәтханә ясалган.

## Россия ислам институтында чыгарылыш курс шәкертләренә дипломнар тапшырылды

Россия ислам институтында һәм Казан ислам университетында дипломнар тапшырылды. Россия ислам институтын – 146, ә Казан ислам университетын 86 кеше тәмамлады.

## Татарстан Мөфтиенә Т-Банкның «Ислам картасы» тәкъдим ителде

Зөлхиҗҗә аеның 22 нче көнендә (28 июньдә) Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Т-Банкның ислам банкингы юнәлеше җитәкчесе Әсхәт Гыйниятов белән эшлекле очрашу үткәрде. Очрашуда шулай ук Татарстан мөфтиятенең Голәмәләр шурасы гыйльми сәркатибе, шәригать фәннәре докторы Рөстәм хәзрәт Нургалиев һәм шәригать мәсьәләләре бүлеге җитәкчесе Булат хәзрәт Мөбарәков катнашты. Әсхәт Мидхәт улы хәзрәтләргә Т-Банкның тиздән федераль продукт – ислам дебет картасын эшләп чыгарачагы турында мәгълүмат җиткерде. Ул бу продуктның Россия өчен зур әһәмияткә ия булуын әйтте. Очрашуда әлеге продуктка Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтендә шәригать аккредитациясен үткәрү һәм эшләтеп җибәрү белән бәйле мөһим мәсьәләләр тикшерелде.

## Мөфти Камил хәзрәт махсус хәрби операциядә катнашучы Хәйдәр Нуриев белән очрашты

Зөлхиҗҗә аеның 26 нчы көнендә (2 июльдә) Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин махсус хәрби операциядә катнашучы Хәйдәр Нуриев белән очрашты. Чаллыдан килгән хөрмәтле кунак хәзрәткә үзенең хәрби тәҗрибәсе һәм яралануы турында сөйләде, шулай ук махсус хәрби операция зонасында хезмәт итү өчен имамнар әзерләү һәм сугышчыларның дини белемнәрен арттыру үтенече белән мөрәҗәгать итте. Моннан тыш, ул Мөфтигә Ислам нигезләре буенча башлангыч дини белем алу теләген җиткерде һәм әлеге мәсьәлә буенча киңәшләр сорады. Камил хәзрәт кунакка Татарстандагы мөмкинлекләр турында сөйләп, ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең онлайн-мәдрәсәсе белән таныштырды, мәчет каршындагы курсларда һәм мәдрәсәдә читтән торып уку мөмкинлеге хакында сөйләде, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга керергә чакырды.

## Камил хәзрәт Троицкида Рәсүлев укуларында катнашты

Зөлхиҗҗә аеның 29 нчы көнендә (5 июльдә) Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Чиләбе өлкәсенең Троицк шәһәрендә Рәсүлев укуларында катнашты. Фәнни җыен быел «Илнең иминлеге нигезендә гаилә һәм дини традицияләр» дигән темага узды.

Мөфти Камил хәзрәт Самигуллин фәнни җыелышта катнашучыларны Татарстан мөселманнары исеменнән сәламләп, илебезнең бай мөселман дини мирасына ия булуын ассызыклады һәм шәех Зәйнулла Рәсүлевнең зур казанышларын билгеләп, аның биографиясеннән аз кешегә билгеле булган фактлар белән таныштырды. Шулай ук ишанның хезмәтләрен, аерым алганда, «Рисалә Хыдыйрия» («Хозыр галәйһиссәламнең тормыш юлы һәм Ибне Тәймия вә аның тарафдарларын кире кагу хакындагы рисалә») хезмәтен Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтендә нәшер итү һәм өйрәнү, шулай ук аның күренекле шәкерте, танылган мөселман дин эшлеклесе, галим-теолог Нургали Хәсәнов (1852–1919) турында сөйләде.

## Нәзарәттә Казыйлар шурасы утырышы узды

Мөхәррам аеның 2 нче көнендә (8 июльдә) Татарстан мөфтиятендә Казыйлар шурасы утырышы узды. Киңәшмәдә гаилә мөнәсәбәтләре буенча сораулар һәм халыктан килеп ирешкән башка мәсьәләләр каралды. Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев гаилә кыйммәтләрен һәм татар-мөселман традицияләрен саклау өлкәсендәге эшчәнлекне киңәйтү зарурлыгын белдерде. Гаилә институтын ныгыту өчен мөхтәсибәтләрдә рухи-тәрбия эшен көчәйтергә тәкъдим итте.

Диния нәзарәте Голәмәләр шурасының гыйльми сәркатибе, шәригать фәннәре докторы Рөстәм хәзрәт Нургалиев Россиянең дүрт төбәгендә, шул исәптән Татарстанда партнёрлык (ислам) финансларын кертү буенча экспе-

римент үткәрү кысаларында ислам икътисады буенча дәрес үткәрде. Ул ТР мөселманнары Диния нәзарәтендә һәм Россия ислам институтында 14 финанс оешмасы өчен эшләнгән 15 уникаль банк продукты белән таныштырды.

## Мөфти Камил хәзрәт һәм Казан епархиясе хезмәткәре махсус хәрби операция зонасындагы кайнар нокталарга катлаулы сәфәр кылды

Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин махсус хәрби операция зонасына чираттагы эшлекле сәфәрен кылды. Шулай итеп, быел Камил хәзрәт МХО зонасында өченче тапкыр булды. Бу юлы Татарстан дин әһелләре делегациясенә Ютазы районы имам-мөхтәсибе, казый Марат хәзрәт Мәрданшин һәм Казан епархиясе хезмәткәре протоиерей Андрей Зиньков керде.

Дин әһелләре МХО зонасына генерал-майор Кирилл Кулаков чакыруы буенча барды һәм, Луганскига гына түгел, Донецкига һәм кайнар нокталарга – гаскәрләр һәм хәрби техника күпләп тупланган урыннарда хезмәт итүче Россиянең хәрби подразделениеләренә кадәр барып җитте. Татарстан делегациясе бөтен сәфәр буена Украина снарядлары һәм беспилотниклары һөҗүменә, атышка дучар булуга карамастан, Камил хәзрәт, Марат хәзрәт һәм отец Андрей бергә өч хәрби частька барып җитте. Алар анда Татарстан һәм Россиянең башка төбәкләреннән килгән солдатлар белән очрашулар үткәрде, вәгазьләр укыды, җылы һәм куәтләү сүзләре белән рухи яктан ярдәм итте, яшәү һәм хезмәт шартлары белән танышты, блиндажларын һәм гыйбадәт кылу урыннарын күрде.

Сәфәр барышында хәзрәтләр шулай ук Донецкидагы һәм Луганскидагы мәчетләргә керде, имамнар белән очрашты.

ТР мөселманнары Диния нәзарәте 2022 елдан бирле МХО зонасына эшлекле сәфәрләр кыла һәм Татарстан солдатларына ярдәм күрсәтә.

## Балтач районында XVII Россиякүләм мөселман балалар Сабан туе үтте

Мөхәррам аеның 8 нче көнендә (14 июльдә) Балтач районы Бөрбаш авылында зурлап XVII Россиякүләм мөселман балалар Сабан туе узды. Быел әлеге чара Россиядә Гаилә елы һәм Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан игълан ителгән Гаилә һәм хәләл яшәү рәвеше елы уңаеннан үсеп килүче яшь буында татар халык традицияләренә мәхәббәт ояту максатыннан оештырылды һәм шәрәфле кунаклар, дин һәм җәмәгать эшлеклеләре, татар зыялылары катнашында үтте. Чарада, Татарстан районнарыннан тыш, Ульяновский, Оренбург һәм Киров өлкәләреннән, Башкортстан, Марий Эл республикаларыннан балалар катнашты.

Сабан туе балаларның Коръәннән аятьләр һәм догалар укуы, мөнәҗәтләр, төрле иҗади чыгышлар белән ачылды. Рәсми чыгышлардан соң Гаилә елы уңаеннан күпбалалы 9 гаиләгә һәм махсус хәрби операциядә катнашучы егетләрнең әти-әниләренә бүләкләр тапшырылды. Программага утыздан артык ярыш, Гаилә елы хөрмәтенә яңа уеннар кертелгән иде. Балалар Коръәннән аятьләр һәм догалар укыды; йөгерү, кул көрәше, чүлмәк вату, таяк һәм бау тарту, әтәч тоту, стаканга су ташу, йомырка кабып йөгерү, капчык сугышы, күз бәйләп әйбер кисү, капчык киеп йөгерү, туры баганага менү, утын кисү һ. б. уеннарда көч сынашты.

## Чүпрәле районы Яңа Ишле авылында Вәлиулла Хәсәнов укулары узды

Мөхәррам аеның 7 нче көнендә (13 июльдә) Чүпрәле районы Яңа Ишле авылында «Вәлиулла Хәсәнов укулары» фәнни-гамәли конференциясе узды. Әлеге чарада татар зыялылары, дин һәм җәмәгать эшлеклеләре, туган як тарихын өйрәнүчеләр, дин әһелләре катнашты. 13 июльдә Вәлиулла Хәсәновның тууына 141 ел тулды. Конференция Россиядә Гаилә елы һәм

Татарстан мөфтияте тарафыннан игълан ителгән Гаилә һәм хәләл яшәү рәвеше елы кысаларында үткәрелде. Фәнни конференция исә Яңа Ишле авылы һәм Тау ягы (Татарстанның көньяк-көнбатыш өлеше) тарихын өйрәнү белән беррәттән, дини мирасны өйрәнү һәм саклау белән бәйле актуаль мәсьәләләрне колачлады. Кунаклар Яңа Ишле авылы зиратында танылган шәхесләрнең каберләрен зиярәт итте, «Вәлиулла чишмәсе»ндә булды.

## Мөфти Менделеевск шәһәрендәге 10 нчы төзәтү колониясендә булды

Мөхәррам аеның 10 нчы көнендә (16 июльдә) Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Менделеевск районына эшлекле сәфәр кылды. Биредә ул 10 нчы төзәтү колониясендә булды һәм колония җитәкчесе Илдар Минәхмәтов белән очрашу үткәрде. Анда шулай ук Мөфтинең социаль мәсьәләләр буенча киңәшчесе Илдар хәзрәт Баязитов, Россия Җәзаларны үтәү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең дин тотучылар белән эшне оештыру буенча җитәкче ярдәмчесе Альберт Шәмсунов, Менделеевск районы имам-мөхтәсибе Ирек хәзрәт Нуриев һәм башкалар катнашты. Җитәкчеләр агымдагы мәсьәләләр буенча фикер алышты.

Соңыннан Камил хәзрәт 10 нчы төзәтү колониясенең «Тәүбә» мәчетендә тоткыннар белән аралашты. Ул аларга вәгазь сөйләде, үгет-нәсыйхәтләрен ирештерде һәм җәзага тартылган мөселманнарның күпсанлы сорауларына җавап бирде. Иректән мәхрүм ителүчеләрне аеруча гыйбадәт тәртипләре һәм тәүбә кылу белән бәйле мәсьәләләр кызыксындырды.

Колония мәчетенә даими рәвештә 25 ләп мөселман йөри. Биредә алар намаз һәм Коръән укый. Район имам-мөхтәсибе Ирек хәзрәт Нуриев атнасына ике тапкыр колониядәге тоткыннар белән очраша, аларга вәгазьләр сөйли һәм рухи әңгәмәләр алып бара.

## Дин әһелләре һәм татар җәмәгатьчелеге Вәлиулла хәзрәт Якуповны искә алды

Мөхәррам аеның 13 нче көнендә (19 июльдә), танылган татар дин һәм җәмәгать эшлеклесе, тарихчы, Апанай мәчетенең имам-хатыйбы Вәлиулла хәзрәт Якупов (1963–2012) вафат булган көнне, Казанда күренекле хәзрәтне искә алу чаралары үткәрелде.

Иртән Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Вәлиулла хәзрәтнең якын дуслары, фикердәшләре Казанның Самосыровода урнашкан мөселман зиратында аның кабере янына җыелып, Коръән укыды, дога кылды. Аннан соң Апанай мәдрәсәсе бинасында Россиядә Гаилә елы, Татарстан мөфтияте тарафыннан игълан ителгән Гаилә һәм хәләл яшәү рәвеше елы кысаларында «Хәзерге гаилә проблемалары һәм аларны чишү юллары» дигән темага түгәрәк өстәл утырышы узды. Әлеге чарада дин әһелләре, остазлар, мөгаллимнәр, төрле иҗтимагый оешмалар һәм ЗАГС идарәсе вәкиле катнашты. Көн тәртибендәге мәсьәләләр гаилә кыйммәтләрен һәм татар-мөселман традицияләрен саклау өлкәсендәге проблемалар буенча фикер алышуга һәм хәл итү юлларын эзләүгә юнәлтелгән иде. Анда хәнәфи мәзһәбенең танылган галиме Әбү Хәфс ән-Нәсәфинең «Иман» нәшриятында татар телендә дөнья күргән «Гакыйдә ән-Нәсәфия» китабы да тәкъдим ителде.

## Татарстанда Бөтенроссия мөселман яшьләре форумы узды

20–27 июльдә Шәһре Болгарда XVIII Бөтенроссия мөселман яшьләре форумы узды. Әлеге чара Россиядә Гаилә елы һәм Татарстан мөфтияте игълан иткән Гаилә һәм хәләл яшәү рәвеше елы кысаларында Ислам мәдәниятенә, фәненә һәм мәгарифенә ярдәм күрсәтү фонды белән берлектә ТР МДН тарафыннан оештырылды.

Форумда Берләшкән Гарәп Әмирлекләреннән, Төркиядән, Кыргызстаннан, Белоруссиядән, Таҗикстаннан һәм Россиянең төрле төбәкләреннән: Татарстан, Башкортстан, Марий Эл, Алтай, Кырым, Удмуртия, Чувашиядән; Волгоград, Кемерово, Мәскәү, Түбән Новгород, Оренбург, Самара, Свердловск, Тверь, Төмән, Ульяновский өлкәләреннән; Ханты-Манси автономияле округыннан 18-30 яшьтәге 100 егет һәм кыз катнашты. Аларның барысы да – сайлап алу турын узган һәм Россия өммәте өчен иң өметле һәм файдалы дип танылган социаль стартаплар авторлары.

Форумда катнашучылар экспертлар игътибарына сайлап алу турын узган һәм Россия өммәте өчен социаль, белем бирү һәм мәдәни юнәлештәге иң өметле һәм файдалы булган 17 проектны тәкъдим итте: интернет-, кино- һәм видеопроектлар, мәгърифәтчелек һәм хәйрия башлангычлары, шулай ук мөмкинлекләре чикле кешеләр, өлкәннәр, хатын-кызлар, балалар һәм яшьләр өчен булган, шәхси үсешкә юнәлдерелгән проектлар. Барлык башлангычлар Россия мөселман өммәтенең актуаль проблемаларын хәл итү максатыннан чыгып эшләнгән. Форум нәтиҗәләре буенча, «Син ялгыз түгел» дигән проект Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең 50 мең сумлык грантына лаек булды. Әлеге проектның максаты Чистай балалар йортында тәрбияләнеп чыгучыларның социальләшү дәрәҗәсен арттыруга корылган. Казаннан «Әс-сәлам» заманча сәнгать күргәзмәсен оештыру проекты Форум командасыннан 30 мең сумлык грант алды: ул ислам мәдәнияте турында хәбәрдарлыкны арттыруны максат итеп куя.

Форумда мәшһүр мөселман дин галимнәре – шәех Хәмдәллаһ әс-Сафти һәм фикһ, фикһ ысулы, гакыйдә белгече, Болгар ислам академиясе мөгаллиме шәех Сәиф бине Гали әл-Гасри гаилә мөнәсәбәтләренә багышланган лекцияләр укыды.

## Казанда БРИКС илләренең Кәлам Шәриф Премиясенә Коръән укучыларның халыкара бәйгесе узды

24–26 июльдә Казанда БРИКС илләренең Кәлам Шәриф Премиясенә Коръән укучылар халыкара бәйгесе тантаналы рәвештә ачылды. Чара Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте, Россия мөфтиләре шурасы һәм Мөхәммәд бине Зәйд исемендәге Гуманитар фәннәр университеты (Берләшкән Гарәп Әмирлекләре) тарафыннан Татарстан Республикасы теләктәшлегендә оештырылды.

БРИКС илләренең Кәлам Шәриф Премиясе изге Коръән текстларын оста итеп уку буенча «Тиләвәт» номинациясендә узды. Бәйгедә 20 дән артык илдән, аерым алганда, БРИКС, гарәп-мөселман дөньясы, Африка һәм БДБ илләреннән иң көчле Коръән укучылар катнашты. Россиядән Коръән хафиз Ясир Додарбеков катнашты.

Жюри составында Казан казые, ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең шәригать мәсьәләләре буенча бүлек җитәкчесе Булат хәзрәт Мөбәрәков булды.

## Татарстан Диния нәзарәтендә Катар Дәүләте делегациясе булды

Мөхәррам аеның 18 нче көнендә (24 июль) Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенә Катар Дәүләтеннән делегация килеп китте. Анда Дин эшләре буенча министр киңәшчесе Хәлиф Җәсем Кувари, Ислам идарәсе җитәкчесе Мөхәммәд Җәбар әл-Маннаи һ. б. керде.

Делегация әгъзалары Казанга «Рухи Ефәк юлы: Зур Евразия киңлегендә дини кыйммәтләрнең әһәмияте» дип аталган V Халыкара фәнни-дини конференциясендә катнашу өчен килде. Камил хәзрәт Сәмигуллин кунакларны Нәзарәтнең төп эш юнәлешләре, аерым алганда, Корънне өйрәнү һәм та-

тар халкының бай дини мирасын мәңгеләштерү барышы белән таныштырды. Мөфти хәзрәт кунакларга рәхмәт тә белдерде: 2023 елда ТР мөселманнары Диния нәзарәте, Катар ярдәме белән заманча халыкара стандартларга туры китереп, «Казан басмасы» мосхафын бастырып чыгарды.

Кунакларны шулай ук кулъязма Коръәнне әзерләү проекты кызыксындырды. Ул Казанда үсеш алган тагын бер кызыклы юнәлеш булып тора. Бу эш – тулысынча ТР мөселманнары Диния нәзарәте белгечләре, хаттатлар, Коръән-хафизлар һәм кыйраәт белгечләре казанышы. Проект Россиядә Коръән белеме һәм илебездәге ислам дини фикере өчен югары фәнни кыйммәткә ия. Кулъязма Коръән әзерләү комиссиясе әгъзасы шәех Мәэмүн әр-Рави Казан кулъязма Коръәне үрнәк мосхаф булыр һәм аңа таянып башка мосхафлар да язылачак, дип саный.

## Мөфти Камил хәзрәт «Рухи Ефәк юлы» V Халыкара фәнни-дини конференциясендә чыгыш ясады

Мөхәррам аеның 19 нчы көнендә (25 июльдә) Казанда «Рухи Ефәк юлы» V Халыкара фәнни-дини конференциясе узды. Чара Татарстан Республикасы ярдәме белән Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте, Россия Мөфтиләр шурасы һәм Мөхәммәд бине Зәйд исемендәге Гуманитар фәннәр университеты (БГӘ) тарафыннан оештырылды.

Конференциядә РФ Президентының Эчке сәясәт идарәсенең дини оешмалар белән хезмәттәшлек департаменты җитәкчесе, Ислам мәдәнияте, фәне һәм мәгарифенә ярдәм фонды советы рәисе Евгений Еремин Татарстан Диния нәзарәтенә, даими ярдәм күрсәтүе һәм еш кына бик күп яхшы идеяләр башлангычы белән чыкканы өчен, аерым рәхмәт сүзләрен ирештерде.

Мисыр Гарәп Республикасы Вакыфлар министры доктор Үсәмә әл-Әзһари шулай ук Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллинга, ТР мөселманнары Диния нәзарәтендә Коръәнне өйрәнү һәм Коръән бастыру белән шөгыльләнүләре өчен, рәхмәтен белдерде.

Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, үз чиратында, форумда катнашучылар алдында чыгыш ясап, аларны Татарстан белән икътисади, мәдәни, дини өлкәләрдә хезмәттәшлек итәргә чакырды. Шул уңайдан ул кунакларга хәзерге татар өммәте үсешенең төп юнәлешләре турында сөйләде, Татарстанда гамәлгә ашырыла торган дин гыйлеме өлкәсендәге мөһим юнәлешләр белән таныштырды. Ул Нәзарәтнең ислам финанслары буенча экспериментны тормышка ашырудагы эшчәнлеге, Коръәнне өйрәнү һәм заманча стандартларга туры китереп, мосхафлар бастырып чыгару, кульязма Коръән проекты турында тәфсилләп сөйләде. Камил хәзрәт, мөфтиятнең нәшрият эшчәнлегенә йомгак ясап, гомум тиражы 1 млн данәдән күбрәкне тәшкил иткән 350 дән артык исемдәге китапны колачлавын билгеләп үтте, аларның күбесе – татар дини мирасы хезмәтләре.

## Татарстан мөфтиятендә Мисырның вакыфлар эшләре буенча министры булып китте

Мөхәррам аеның 20 нче көнендә (26 июль),Татарстан мөфтиятендә Мисырның вакыфлар эшләре буенча министры шәех Үсәмә Сәид Мәхмүд Мөхәммәд әл-Әзһари җитәкчелегендәге делегация булып китте. Мөхтәрәм кунакны Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин каршы алды. Кунакны сәламләргә дип, фәннәр докторы, БИА мөгаллиме, шәех әл-Гасри да килде.

Министр Татарстан башкаласына «Рухи Ефәк юлы: Зур Евразия киңлегендә дини кыйммәтләрнең әһәмияте» V Халыкара фәнни-дини конференциясендә катнашу өчен килде.

Татарстан Мөфтие очрашу вакытында шәехне Нәзарәтнең Коръән өйрәнү һәм Коръән бастыру өлкәсендәге проектлары, татар халкының гореф-гадәтләре белән таныштырды. Аерым алганда, сүз кульязма Коръәнне язу эшен тәмамлау һәм аны басмага әзерләү турында барды. Кунаклар, үз чиратында, Мисырда Коръәнне өйрәнү тарихы турында сөйләде.

## Татарстан Мөфтие Берләшкән Гарәп Әмирлекләреннән килгән дәрәҗәле кунаклар белән очрашты

Мөхәррам аеның 20 нче көнендә (26 июль) Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Берләшкән Гарәп Әмирлекләренең вакыфлар һәм Ислам эшләре идарәсе рәисе Гомәр әд-Диргый һәм Мөхәммәд бине Зәйд исемендәге Гуманитар фәннәр университеты ректоры Хәлифә әз-Заһири белән очрашты. Очрашуда шулай ук Мөфтинең мәгариф буенча урынбасары, РИИ һәм КИУ ректоры Рәфикъ хәзрәт Мөхәммәтшин катнашты.

Берләшкән Гарәп Әмирлекләре кунаклары Казанга «Рухи Ефәк юлы: Зур Евразия киңлегендә дини кыйммәтләрнең әһәмияте» V Халыкара фәнни-дини конференциясендә катнашу өчен килде. Мәгълүм булганча, Мөхәммәд бине Зәйд исемендәге Гуманитар фәннәр университеты Кәлам Шәриф Премиясенә Коръән укучыларның халыкара бәйгесен оештыруда катнашты.

Очрашу барышында Татарстан Мөфтие шәехләрне ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Коръәнне өйрәнү өлкәсендәге проектлары белән таныштырды. Кунакларны шулай ук Татарстан мөфтиятенең «Хозур» Нәшрият йортының медиа- һәм белем бирү проектлары кызыксындырды. Җитәкчеләр мөфтиятнең өммәтне агарту өлкәсендәге эшчәнлеген уңай бәяләде.

## Мөфти Камил хәзрәт БРИКС илләренең мөселман дини җитәкчеләре очрашуында катнашты

Мөхәррам аеның 20 нче көнендә (26 июль), Казанда БРИКС илләренең мөселман дини җитәкчеләре очрашуы узды. Очрашу нәтиҗәләре буенча, катнашучылар дөньяның күпполярлыгы, рухи-әхлакый кыйммәтләрне саклау, популярлаштыру һәм яклау, Исламның радикализм һәм экстремизм идеяләрен кабул итмәве турында резолюция кабул итте. БРИКС дәүләтләренең мөселман дини оешмалары алга таба да берләшмә кысаларында элемтәләрне ныгытырга, анда кергән илләр һәм аларның халыклары

өчен уртак мәнфәгатьләр хакына алга таба да мәдәни-гуманитар өлкәдә хезмәттәшлек итәргә ниятли.

БРИКС илләре мөселманнарының дини җитәкчеләре БРИКСта рәислек итүче Россия Федерациясе җитәкчелегенә, шулай ук чараны оештыручыларга – РФ мөселманнары Диния нәзарәтенә, Мөхәммәд бине Зәйд исемендәге Гуманитар фәннәр университетына, Татарстан Республикасы Хөкүмәтенә һәм Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенә – рәхмәт белдерде.

## Әлки мөхтәсибәтендә яңа мәчет ачылды

Мөхәррам аеның 27 нче көнендә (2 август) Әлки районының Базарлы Матак авылында яңа «Өмет» мәчетен ачу тантанасы булды. Әлеге мәчет биш ел эчендә район халкы һәм иганәчеләрнең уртак көче белән күтәрелгән. Нигез ташы 2019 елның июлендә салынган. Мәчет өч катлы, 130 кеше сыйдырышлы; Ислам нигезләрен өйрәтү өчен җиһазландырылган, электр энергиясе һәм җылыту системаларына тоташтырылган. Ир-атлар һәм хатын-кызлар өчен аерым тәһарәтханәләр ясалган. Мәчет тирәсе матурланган. «Өмет» мәчете имамы итеп Рәмис хәзрәт Вафин билгеләнде. Хәзерге вакытта Әлки мөхтәсибәтендә 32 мәчет эшли.

## Арча һәм Балык Бистәсе хәзрәтләре Татарстаннан мобилизацияләнгән солдатларга ярдәмгә «Урал» мотоцикллары сатып алды

Арча һәм Балык Бистәсе хәзрәтләре Татарстаннан махсус хәрби операция зонасына мобилизацияләнгән солдатларга ярдәмгә «Урал» мотоцикллары сатып алды. Мөхтәсибләр Әмир хәзрәт Миннемуллин һәм Рамазан хәзрәт Хисаметдинов мотоциклларны Мөфти ярдәмчесе Рамил хәзрәт Мингәрәевкә алып килеп тапшырды.

Мотоцикллар мөселманнар акчасына сатып алынган. Алар яралы солдатларны кырдан алып чыгу һәм госпитальгә озату, азык-төлек, су, медикаментлар илтү өчен файдаланылыр, дип көтелә.

## Әгерже мөхтәсибәтендә Саклау җыены үтте

Сафәр аеның 3 нче көнендә (7 августта) Әгерже районы Саклау авылында мөселманнар җыены үтте. Җыенны үткәрүнең төп максаты – бабаларыбыздан әманәт итеп тапшырылган динебезгә һәм борынгы мәчетләребезгә сакчыл караш тәрбияләү, Ислам динен куәтләү өчен мөселманнарга очрашу, күрешү мөмкинлеге булдыру.

Әлеге җыен елдагыча дәүләт саклавына алынган, тарих-архитектура истәлеге булган, районда хәзергәчә сакланып калган элекке таш мәчетләрнең бердәнбере булган Саклау мәчете янында үткәрелде.

## Кукмара мөхтәсибәтендә VII Мәчкәрә укулары узды

Сафәр аеның 11 нче көнендә (15 августта) Кукмара мөхтәсибәтендә «VII Мәчкәрә укулары» төбәкара фәнни-гамәли конференциясе үтте. «Гореф-гадәтләрдән тайпылмыйча яшәү – татар гаиләсенең нигезе» дип аталган чарада татар шәҗәрәләрен өйрәнү, Мәчкәрә мәчете һәм авыл тарихы, борынгы Мәчкәрә зиратындагы кабер ташларын өйрәнүгә кагылышлы мәсьәләләр күтәрелде.

Конференция Россиядә Гаилә елы һәм Татарстан мөфтияте тарафыннан игълан ителгән Гаилә һәм хәләл яшәү рәвеше елы кысаларында үткәрелде. Анда катнашучылар фәнни җыен алдыннан Мәчкәрә авылының борынгы зиратында булды, тарихи Мәчкәрә мәчетен төзекләндерү барышы белән танышты. Тарихи зиратта гомерен дингә һәм милләткә хезмәт итүгә багышлаган танылган дин әһелләре, галимнәр, остазлар һ. б. җирләнгән.

## Чаллы мөхтәсибәтендә «Сөембикә» мәчете ачылды

Сафәр аеның 13 нче көнендә (17 августта) Яр Чаллыда «Сөембикә» мәчете ачылды. Мәчет 130 кешегә исәпләнгән, беренче катта ир-атлар өчен зур намаз залы, имам бүлмәсе урнашкан. Икенче катта 70–80 хатын-кыз намаз укый алырлык балкон бар. Мәчеттә Ислам дине нигезләре буенча хатын-кызлар өчен дәресләр алып барыла, ике төркемдә берьюлы 50 хатын-кыз белем ала.

«Сөембикә» мәчете имам-хатыйбы итеп Яр Чаллы шәһәренең «Ак мәчет» мәдрәсәсен тәмамлаган Рәис хәзрәт Әхмәтов билгеләнде.

## Алабугада җәядән ук ату буенча «Туган батыр» III Бөтенроссия турниры узды

Сафәр аеның 13 нче көнендә (17 августта) Алабугада җәядән ук ату буенча «Туган батыр» III Бөтенроссия турниры узды. Ярышлар тарихи урында – федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объекты булган Алабуга шәһәрчегендә оештырылды.

Турнирның рәсми ачылышында Удмуртия, Башкортстан республикаларыннан, Пермь крае, Үзбәкстан, Казахстан, Татарстан шәһәрләре һәм районнарыннан 90 га якын укчы һәм кунак катнашты.

## Чүпрәле мөхтәсибәтендә Мунчәли укулары узды

Сафәр аеның 13 нче көнендә (17 августта) Чүпрәле мөхтәсибәтендә XVII фәнни-гамәли конференция – Мунчәли укулары – үтте. Чара Россиядә Гаилә елы, Татарстан мөфтияте тарафыннан игълан ителгән Гаилә һәм хәләл яшәү рәвеше елы кысаларында оештырылды. Унҗиде ел дәвамында Мунчәли укулары төбәкара чарага әйләнде, бирегә Татарстанның төрле районнарыннан, Ульяновский, Чувашстан, Мордовия, Пенза һәм Россиянең башка төбәкләреннән дин әһелләре, җәмәгать эшлеклеләре, галимнәр җыелды.

Укуларда гаилә һәм хәләл тормыш рәвеше алып бару белән бәйле мәсьәләләр турында сөйләштеләр.

## Казанда татар абыстайлары форумы үтте

Сафәр аеның 16 нчы көнендә (20 августта) Казанда II Татар абыстайлары форумы узды. Чарада Татарстанның барлык мөхтәсибәтләреннән мөслимәләр берлеге җитәкчеләре, Казан мәчетләрендәге абыстайлар – барлыгы 100 мөслимә катнашты. Шулай ук Ульяновский өлкәсеннән, Башкортстан һәм Марий Эл республикаларыннан кунак булып килгән абыстайлар да бар иде. Форумда мөселман гаиләсенең тотрыклылыгын һәм асылын саклау, яшьләрне гаилә коруга һәм балалар алып кайтырга өндәү, аерылышучылар санын киметү турында сөйләштеләр.

## Казан шәһәренең сугыш ветераннары госпиталендә намаз уку бүлмәсе ачылды

Сафәр аеның 18 нче көнендә (22 августта) Казан шәһәренең сугыш ветераннары госпиталендә намаз бүлмәсен рәсми ачу тантанасы булды. Консультатив поликлиниканың беренче катында урнашкан намаз уку бүлмәсе РФ Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе башлангычы һәм авырулар үтенече белән оештырылган. Ун квадрат метрлы бүлмәдә берьюлы 5 кеше намаз укый ала. Рәсми ачылыш көнендә биредә беренче намаз укылды.

РФ Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе җәмәгать урыннарында һәм хастаханәләрдә намаз уку бүлмәләрен 2020 елдан бирле ачып килә.

## Нәзарәттә шәех Мәэмүн әр-Рави катнашында Коръәннең кулъязма мосхафын әзерләү комиссиясенең чираттагы утырышы узды

Сафәр аеның 18 нче көнендә (22 августта) Татарстан мөфтияте бинасында Коръәннең кулъязма мосхафын әзерләү комиссиясенең чираттагы утырышы үткәрелде. Җыелышта Казанның Коръән белгечләре белән берлектә Дубайдан килгән дөньякүләм танылган мөселман галиме, Изге Коръән Дубай халыкара премиясе (DIHQA) Коръән әзерләү комиссиясе башлыгы, хафизлыкның иң югары дәрәҗәсенә ия булган, пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламнең нәсел дәвамчысы шәех Мәэмүн әр-Рави катнашты. Шәех Комиссия составында проектны тормышка ашыра башлаганнан бирле эшли. Комиссияне Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкли.

Галимнәр аерым сораулар буенча фикер алышты һәм кулъязма мосхафны әзерләү эшен дәвам итү буенча карарлар кабул итте.

## Нәзарәттә 100 дән артык укучыга букчалар һәм мәктәп кирәк-яраклары тапшырылды

Сафәр аеның 22 нче көнендә (26 августта), Белем көне алдыннан Татарстан Мөфтиятендә аз керемле һәм күпбалалы, тулы булмаган гаиләләрдәге мәктәп укучыларына портфельләр һәм мәктәп кирәк-яраклары тапшырылды. Чара «Мәктәпкә җыенырга ярдәм ит!» республика акциясе кысаларында узды. Тутырылган букчалар һәм мәктәп кирәк-яраклары салынган пакетларны хәзрәт кулыннан 100 дән артык бала алды, аларның 20 се – беренче сыйныфка баручылар.

Акцияне Нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фонды оештырды. Аның максаты – балалары булган аз керемле гаиләләргә яңа уку елына әзерләнергә, мәктәп өчен кирәкле әйберләр тупларга ярдәм итү. Мәктәп портфеле комплекты үзгәрмәде: канцелярия товарлары, дәфтәрләр, хезмәт, рәсем сәнгате

дәресләре өчен җыелмалар һ. б. Портфельләр һәм канцелярия товарлары битараф булмаган кешеләрнең иганәсенә сатып алынды.

## Аксубай мөхтәсибәтендә яңа «Әниләр» мәчете ачылды

Сафәр аеның 24 нче көнендә (28 августта) Аксубай районы үзәгендә «Әниләр» мәчетен ачу тантанасы булып узды.

150–200 кешегә исәпләнгән мәчеттә тәһарәтханә, Ислам нигезләрен өйрәнү өчен уку сыйныфы, ашханә-кухня бар. Дини йолаларны башкару өчен барлык кирәкле шартлар тудырылган. Мәчет су, газ, электр белән тәэмин ителгән. Намаз уку залларындагы идәннәр җылытылган. Киләчәктә мәчет тирәсен матурлау, ял урыннары һәм заманча балалар мәйданчыгы булдыру көтелә. Бүгенге көндә Аксубай районында, яңа ачылган мәчетне дә кертеп, 29 мәчет эшли.

## Татарстан Диния нәзарәте Газзә Секторына 9 тоннадан артык гуманитар йөк җибәрде

ТР мөселманнары Диния нәзарәте һәм РФ мөселманнары Диния нәзарәте Газзә Секторында оккупантлар чолганышында калган халык өчен гуманитар йөк җибәрде. Мисырга юл тоткан очкыч бортына гомум авырлыгы 30 тонна булган хәләл тушенка төялде, шуның 9 тоннадан артыгы – ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фондыннан. ТР мөселманнары Диния нәзарәте һәм РФ мөселманнары Диния нәзарәте вәкилләре азык-төлекне Мисырның «Әл-Гариш» аэродромында Мисырның Кызыл Ярымай җәмгыятенә тапшырды. Алар аны Газзә халкына тапшырачак.

## Рөстәм Миңнеханов һәм Камил хәзрәт Сәмигуллин төзекләндерелгән Мәрҗани мәчетен карады

Сафәр аеның 25 нче көнендә (29 августта) Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев һәм Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин төзекләндерү үткәрелгән Мәрҗани мәчетен карады, Мәрҗани мәчете тарихына һәм күренекле имамнарга багышланган музейда булды.

Мәрҗани мәчетендә ремонт эшләре ике этапта алып барылды. Бинаны саклау чаралары кысаларында мәчетнең гөмбәзләре һәм бинаның тышкы ягындагы ярыклар ямалды, манара һәм түбә төзекләндерелде, барлык конструкцияләр дә ныгытылды. Җилләтү, җылыту, һава алмаштыру, суүткәргеч һәм электр белән тәэмин итү челтәрләре яңартылды.

Реставраторлар бинаның тышкы ягын тарихи барокко стилендә матурлады, тышкы бизәкләрне, тәрәзәләрне һәм декоратив-нәфис металл эшләнмәләрен торгызды.

## Республика балалар клиник хастаханәсе янында «Әбүгалисина» мәчете ачылды

Сафәр аеның 26 нчы көнендә (30 августта), изге җомга көнендә, Казан шәһәрендә Республика балалар клиник хастаханәсе җирлегендә тантаналы рәвештә «Әбүгалисина» мәчете ачылды.

250 $м^2$ мәйданлы мәчет төзелеше Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов теләктәшлегендә РФ Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе акчасына төзелде. Генераль подрядчы – «ГК Металл Сервис» компаниясе. Йөз кеше сыйдырышлы «Әбүгалисина» мәчете бер катлы; бинада балкон, барлык уңайлыклары булган тәһарәтханә һәм имам бүлмәсе бар. Биредә ир-атлар һәм хатын-кызларга намаз уку өчен барлык мөмкинлекләр тудырылган.

Республика балалар клиник хастаханәсе янындагы мәчеттә беренче азан яңгырады, беренче җомга намазы укылды. Җомга намазында имам булып Мөфти хәзрәт Камил Сәмигуллин торды.

## Тукай мөхтәсибәтендә зур төзекләндерү эшләреннән соң мәчет ачылды

Сафәр аеның 27 нче көнендә (31 августта) Тукай районы Югары Суыксу авылында төзекләндерү эшләреннән соң мәчет ачылды. Бер катлы мәчетнең мәйданы – 160 $м^2$, анда ир-атларга һәм хатын-кызларга гыйбадәт кылу өчен барлык шартлар булдырылган. Моннан тыш, мәчет каршындагы курслар һәм ифтарлар үткәрү өчен, 50–60 кеше сыйдырышлы янкорма корылган, барлык уңайлыклар тудырылган тәһарәтханә бар. Мәчет су, газ, электр белән тәэмин итү буенча инженерлык челтәрләренә тоташтырылган, әйләнә-тирәсе матурлап тәртипкә китерелгән. Бүгенге көндә Тукай районында, төзекләндерүдән соң ачылган мәчетне дә кертеп, 58 мәчет эшли.

## Июль–август айларында Нәзарәт 5 яңа ислам финанс продуктын хуплады

Май–июнь айларында Нәзарәт 5 яңа ислам финанс продуктын хуплады. Тәкъдим ителгән документларны өйрәнеп, әлеге продуктларны ислам хокукы кануннары нигезендә рөхсәт ителгән, дип тапты. Шулай итеп, хәләл финанс хезмәтләре базарында Ак Барс Банкыннан – сәүдә эквайрингы/СБП һәм лизинг оешмаларын финанслау, «Ислам лизингы»; Halal Card тан – «Хәләл кешбэк», Зенит банкыннан – private-сегменттагы ислам дебет картасы кебек яңа продуктлар барлыкка килде. Барлыгы Нәзарәттә 14 финанс оешмасы өчен 15 ислам финанс продукты, шул исәптән физик һәм юридик затлар өчен: коммерция ипотекасы, банк картасы, рассрочка, инвестицияләр, лизинг, факторинг һ. б. эшләнеп расланды.

## Татарстан Мөфтие республикабызның хөрмәтле абыстае Сәйдә Аппакова белән очрашты

Рабигыль-әүвәл аеның 1 нче көнендә (4 сентябрьдә) Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин республикабызның танылган хөрмәтле абыстае, күп еллар дәвамында дин сабаклары укыткан мөгаллимә, «Тәртип» радиосында «Тузмый торган бүләк» тапшыруы авторы һәм алып баручысы, хөрмәтле дин әһелләренең нәсел дәвамчысы, күп хезмәтләр авторы Сәйдә Аппакова белән очрашты.

Камил хәзрәт, Сәйдә абыстайның дин юлындагы тырышлыкларын югары бәяләп, рәхмәт әйтте. Мөфти, дәгъват эшенең мөһимлеген билгеләп үтеп, аңа әдәп-әхлак тәрбиясенә багышланган вәгазьләрен Нәзарәтнең «Хозур-ТВ» телеканалында яздырып, халыкка күрсәтергә тәкъдим итте.

2021 елда Сәйдә абыстай Нәзарәтнең «Бердәмлек» медале белән бүләкләнде, 2023 елда «Хозур» нәшрият йортында аның «Тузмас бүләк» китабы нәшер ителде.

## 1801–1805 елларда төзелгән тарихи Яңа бистә мәчетенең («Ак мәчет») торгызылган манарасына ярымай куелды

Рабигыль-әүвәл аеның 2 нче көнендә (5 сентябрьдә) Казанда 1801–1805 елларда төзелгән тарихи Яңа бистә мәчетенең («Ак мәчет») торгызылган манарасына ярымай кую тантанасы үтте. «Ак мәчет» – Республика әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты. Ул урта гасыр болгар, татар халык архитектурасын үз эченә алып, классицизм архитектурасы элементларын кулланып төзелгән.

## Танылган Коръән хафизә Гөлсем Арслан 75 көндә Коръән ятлау буенча үзенчәлекле программасын тәкъдим итте

Сентябрь башында Казанда Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин чакыруы белән Төркиядән Истанбулның Сабахаттин Заим исемендәге университетының Коръән мөгаллимәсе, 75 көн эчендә Коръәнне ятлау буенча үзенчәлекле программа авторы, хафизә Гөлсем Арслан булып китте. Ул РИИ һәм КИУ, Татарстан мәдрәсәләре һәм мәчетләрендә эшләүче Коръән мөгаллимнәренә; Коръән хафизларны әзерләү үзәге һәм «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкертләренә дәресләр бирде. Үз методикасы буенча остазлык дәресләрен үткәрде. Әлеге методиканың асылы Коръәнне укытучы артыннан күмәкләшеп ятлауга корылган, шул ук вакытта аятьләрнең мәгънәсен аңлау да мөһим.

Гөлсем Арслан шулай ук ТР мөселманнары Диния нәзарәтендә дә булды. Монда хөрмәтле кунакны һәм аның юлдашларын Камил хәзрәт кабул итте. Ул хөрмәтле остазга Казанга килүе өчен рәхмәт белдерде. Мөфтиятнең Коръән белеме һәм Коръән бастыру өлкәсендәге эшчәнлеге турында сөйләде. Хәзрәт кунакка очрашу истәлеге итеп репринт «Казан басмасы»н бүләк итте.

## Мөфти ТР Рәисенең Согуд Гарәбстаны Хаҗ һәм гомрә эшләре буенча министры белән очрашуында катнашты

Рабигыль-әүвәл аеның 3 нче көнендә (6 сентябрьдә) Татарстан Республикасы Хөкүмәте йортында Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Согуд Гарәбстанының Хаҗ һәм гомрә эшләре буенча министры Тәүфыйк бине Фәүзан әр-Рабига белән очрашты. Чарада Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, «ДУМ РТ ХАДЖ» хаҗ операторы генераль директоры Ранис хәзрәт Вахитов та катнашты. Нигездә сүз Россия, шул исәптән Татарстан һәм

Согуд Гарәбстаны арасындагы ислам банкингы, хәләл индустрияне үстерү һәм башка өлкәләрдә хезмәттәшлекне үстерү турында барды.

## Татарстанда гошер җыю кампаниясе башланды

Татарстан Республикасында Диния Нәзарәте башлангычы белән гадәттәгечә гошер садакасын җыю һәм халыкның мохтаҗ катламнарын азык-төлек белән тәэмин итү кампаниясе башланды. Шуңа бәйле рәвештә, мөфтият 2024 елның 21 сентябрен Татарстанда Гошер көне дип игълан итте.

Гошер көне Татарстанда барлык мөхтәсибәтләрдә үзәкләштерелгән рәвештә 2017 елдан бирле үткәрелә. Һәр елдагыча, мөхтәсибәтләрдәге мәчетләр гошер садакасы итеп җиләк-җимеш һәм яшелчәләр кабул итә: бәрәңге, кәбестә, аш чөгендере, кишер, кабак, суган, алма, слива һ. б. Аннары азык-төлек җыелмаларын аз керемле, мохтаҗ кешеләргә тапшыру оештырылачак.

Казанда гошерне Нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фонды кабул итә һәм тарата. Фондта меңнән артык мохтаҗ гаилә исәптә тора, аларның барысына да – күпбалалы, тулы булмаган, аз керемле, авыру балалар тәрбияләүче гаиләләргә – гошер тапшырылачак. Гошер мохтаҗларның үзләренә, шулай ук хәйрия оешмаларына, социаль учреждениеләргә, мөселман уку йортларына (мәдрәсәләргә, Коръән хафизлар әзерләү үзәгенә һ. б.) тапшырылачак.

## «Ярдәм» хәйрия фондында сукырларга Брайль шрифты буенча басылган 29 комплект «Кәлам Шәриф» тапшырдылар

Рабигыль-әүвәл аеның 8 нче көнендә (11 сентябрьдә) «Ярдәм» хәйрия фондында Татарстан мөфтиятенең «Калям Шариф. Перевод смыслов» хезмәтен Брайль системасы буенча бастырып, сукырларга тапшырдылар. Ун томлык 29 комплектны хәйрия фондының Чечня, Башкортстан, Ингушетия,

Дагстан республикалары, Мәскәү, Самара һәм Әстерхан өлкәләре, Алтай крае һәм Ижевскта яшәүче тәрбияләнүчеләр алды.

Коръән тәфсире комплектлары «Ярдәм» фонды типографиясендә Татарстан мөфтияте үткәргән Бөтенроссия мөселман яшьләре форумы әгъзалары җыеп тапшырган хәйрия акчасына бастырылды. Форум узган көннәрдә, хәйрия аукционы оештырылып, яшьләр «Ярдәм» фондына 483 101 сум җыеп тапшырды. Барлык акчалар да Нәзарәтнең Коръән тәфсирен Брайль системасы буенча бастыруга җибәрелде.

«Ярдәм» фонды типографиясе БДБ илләрендә Луи Брайль системасында мөселман китапларын бастыру белән шөгыльләнүче бердәнбер типография булып тора.

## Мөфти Махачкалада «Йортыбызга бәрәкәт иңсен» динара форумында катнашты

11–13 сентябрь көнне Махачкалада «Йортыбызга бәрәкәт иңсен» динара форумы эшләде. Аның эшендә Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин катнашты.

Форумның эше «Бердәмлек һәм иминлек», «Үсештәге төбәк», «Ныклы гаилә – сәламәт җәмгыять нигезе», «Социаль теләктәшлек һәм гуманитар ярдәм» һәм «Исламда ватанпәрвәрлек, Ватанга мәхәббәт» дип аталган биш секциягә корылган иде. Секцияләрдә катнашучылар экстремизмга һәм радикализмга каршы тору, Исламда көчләүгә һәм түземсезлеккә каршы булган хакыйкый кыйммәтләргә иярү, яшьләр проблемалары, Исламда гаиләнең роле, хәйрия фондларының гуманитар ярдәмдә катнашуы, Ватанны яратуның мөһимлеген исбатлаучы тарихи фактлар, махсус хәрби операциядә катнашуның җаваплылыгы турында фикер алышты. Камил хәзрәт «Ныклы гаилә – сәламәт җәмгыять нигезе» секциясендә чыгыш ясады.

## Татарстанда Мәүлид кичәләре узды

3 сентябрьдә, кояш баеганнан соң, һиҗри календарь буенча мәртәбәле айларның берсе – пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам туган рабигыль-әүвәл ае башланды. Татарстан мөселманнары өчен мәчетләрдә Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең дөньяга килүенә ихлас күңелдән шатлануны белдереп, ай дәвамында төрле чаралар үткәрелде. Алар Аллаһы Расүле галәйһиссәламнең тормышын өйрәнүне, аңа күпләп салаватлар әйтүне, Коръән аятьләрен уку, догалар кылу, вәгазьләр сөйләүне үз эченә алды Мәүлид мәҗлесләре Пәйгамбәребез галәйһиссәлам узган юлны һәм аның сөннәт гамәлләрен искә төшерүне, аның күркәм әхлакый үрнәген өлге итеп алуны, рухыбызны тәрбияләү һәм ныгытуны максат итеп куйды.

Аерым алганда, 14–15 сентябрьдә Казан шәһәренең Галиев мәчетендә, Иске татар бистәсендә һәм Болгарда Мәүлид ән-Нәби үткәрелде. Чараларның аерылгысыз өлеше буларак Татарстанның танылган артистлары башкаруында «Мәүлид» касыйдәсе яңгырады.